Казан утлары

2

ФЕВРАЛЬ

1967



КАЗАН утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

Бу санда:

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Г. Ибраһимов. Автобиография 4

ПОЭМА, ПОВЕСТЬЛАР, ШИГЫРЬЛӘР

Н. Арсланов. Моңсар. Поэма. 27

ИБРАҺИМ ГАЗИГА 60 ЯШЬ

И. Нуруллин. Юк, тургай картаймый... . . . 32
И. Гази. Малайлыкта кунакта. Автобиографик повесть 33
М. Садри. Булган икән көч тә үзеңдә. Шигырь. 62
Р. Гәрәй. Уйланган минутларда. Шигырьләр. . 63
Ә. Баянов. Яшьлегемне эзлим. Лирик повесть. Дәвамы. 67
Р. Төхфәтуллин. Пыяла ватыгы һәм асылташ. Ике көймә. Яшьлек сере. Парчалар. . . 97
Ш. Галиев. Балалар өчен шигырьләр. 99

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Л. Гомәров. Ул зур җәмәгать эшлеклесе иде. Истәлек. 103

МЕМУАР

Г. Сафиуллин. Днепрны кичү. 105
Х. Туфан, С. Хәким. Безнең сафка 114

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Т. Хаҗиәхмәтов. «Безнең көннәр» романына иллюстрацияләр 116

2

ФЕВРАЛЬ
1967

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

М. Маннурова. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романында рус образлары 119

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

З. Саликова. Галия Гафиятуллина җырлый. . 122

ТЕАТР

Б. Гыйззәтуллин. Сәнгатьтә яңа үрләргә. . 126

УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА

Ф. Вәлиев. Борынгы бабаларыбыз кемнәр!. . 133

ЧИТ ИЛ ЯЗУЧЫЛАРЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА

Л. Небенцаль. Шагыйрь-көрәшче. 138
Ж. Камалетдин. Җәлил турында сүз. . . . 139

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

С. Алишев. Яңа сәхифәләр ачылганда. . . . 142

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Г. Шамуков. Мәсәлләр. 146
Г. Мөхәммәтшин. Тәмәкенә ничек ташларга! Хикәя. 148
Укучылар сүзе. 151
Ин-иң 153
Яңа китаплар. 154
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары 156

Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: жаваплы редактор — 2-68-21, жаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Г.Ибраһимовның тууына 80 ел

Татарстанның төрле почмакларында — шәһәрләрдә, авылларда, район үзәкләрендә, шулай ук тугандаш республикаларда татар әдәбияты классигы, күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның 80 еллыгын, совет культурасының бәйрәме итеп, тантаналы рәвештә үткәрергә зур әзерлекләр бара. Китапханәләрдә, мәктәпләрдә, клубларда аның әсәрләреннән күргәзмәләр оештырыла, аңа багышланган кичәләрдә, җыелышларда докладчылар әдипнең тормыш юлы, әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге турында сөйлиләр, бу зур иҗатның татар әдәбияты тарихында гына түгел, гомумән, бөтен совет әдәбияты тарихында нинди әһәмиятле урын тотканлыгын мең-нәрчә-меңнәрчә кешеләргә аңлатып бирәләр. Әдәбият сөючеләр бу көннәрдә аның әсәрләрен китапханәләрдән, китап магазиннарыннан аеруча ешрак сорыйлар, укыйлар, язучының иҗатын, биографиясен өйрәнәләр. Шул уңай белән, редакциягә һәм нәшриятка, Галимҗан Ибраһимовның тулырак биографиясен сорап, дистәләрчә хатлар килә. Укучыларның үтенечләрен искә алып, журналыбызның бу санында әдипнең үз кулы белән язылган, моңа чаклы әле матбугатка чыкмаган биографиясен урнаштырабыз.

Автобиографиянең оригиналы КПССның Татарстан Өлкә Комитеты партия архивында саклана. Әдип аны 1929 елда, Ялтада, рус телендә язган һәм, үзенең тормышына, әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенә бәйләнешле булган күп кенә материаллар белән бергә, Казанга, шул вакытта Өлкә Комитетының партия тарихы бүлеге мөдире булып эшләгән карт большевик Сибгат Гафуровка җибәргән.

Текст тулы килеш басыла. Әдипнең автобиографиягә теркәп биргән өстәмә материаллары, документлары журналыбызда басылмаганлыктан, текстта, җәяләр эченә алынып, «карагыз...» дип, аларга ишарә ителгән җөмләләр һәм кайбер очракларда аерым сүзләр генә сызылды һәм андый урыннар күп ноктала белән күрсәтелде. Тулысынча язылмаган яки төшеп калган исемнәр, сүз кисәкләре, тулыландырылып, текст эчендә квадрат җәяләргә алынды. Оригиналда ялгыш күрсәтелгән даталар, сызык астына төшерелеп, дөресләп язылды. Әдипнең 1929 елдан соңгы биографиясе аның үз заманында төрле кешеләргә язган хатларыннан алынган өзекләр белән тулыландырылды.

Автобиографияне рус теленнән язучы Афзал Шамов тәрҗемә итте һәм барлык искәрмәләр, өстәмәләр аның тарафыннан бирелде.

Галимҗан Ибраһимов

АВТОБИОГРАФИЯ

I

ЧЫГЫШЫМ

Мин 1887 елның 28 февралендә [1] элеккеге Уфа губернасы (хәзер Башкортстан республикасы), Стәрлетамак өязе, Уршакмин волосте, Солтанморат авылында туганмын. Әтием авыл мулласы иде. Ләкин гомеренең соңгы елларында, муллалыгын ташлап, бары игенчелек белән генә шөгыльләнде. Крестьян малайларының күпчелеге кебек үк, мин дә кече яшьтән үк авыл хуҗалыгындагы бөтен эшне эшләп үстем. Укыган чагымда — егерме-егерме ике яшемә кадәр — һәр елны диярлек авылга, җәйге кыр эшләренә кайта идем.

Империалистик сугыш елларында, абыем белән энем герман фронтына озатылгач, җәйге бөтен эш минем җилкәгә төште. Ул елларда инде әтием исән түгел иде. 1913 елда үлде.

Хәзер абыем да, энем дә авылда яши, игенчелек белән шөгыльләнәләр, икесе дә актив работниклар: берсе укытучы, икенчесе кооперациядә эшли.

II

УКУ ЕЛЛАРЫ

Укыдым:

1. Авылда — татар мәктәбендә;

2. Авылдагы башлангыч рус мәктәбендә;

3. 11 дән 18 яшемә чаклы Оренбургтагы иске схоластик типтагы мәдрәсәдә; аннан, яңа фикерле булуым һәм уку-укыту эшендәге көнчыгыш-схоластик нигезләргә каршы көрәшкән өчен, куылдым.

4. Оренбургтан Уфага килеп, җәдит мәдрәсәсенә кердем; биредә өч елга якын укыдым, ләкин аннан да куылдым: беренчедән, укыту программасын һәм системасын тәнкыйтьләгән өчен; икенчедән, еш кына мәдрәсә идарәсенә каршы чыгып сөйләүләрем өчен һәм, өченчедән, мәдрәсә шәкерте була торып, «Коръән алладанмы, түгелме?» дигән китап язган өчен. Шәкерт чагымда язган бу хезмәтем (120 бит), билгеле, бастырып чыгарырлык түгел иде. Китапның кулъязмасы — оригиналы әле дә архивымда саклана.

5. Казанга күчеп килеп, университетка яисә педагогия институтына керер өчен әзерләнә башладым (1909—1910). Ләкин моңа ике каршылык туды. Беренчедән, махсус программа буенча системалы рәвештә укыр өчен минем бер төрле дә материаль мөмкинлегем юк иде; икенчедән, бусы иң әһәмиятлесе, мин политик ышанычсыз кеше булып санала идем. Мондый кешеләргә, бигрәк тә рус — христиан булмаганнарга югары мәктәп ишекләре ябык иде.

Шуның аркасында, мин югары мәктәпкә керү фикереннән кайтырга мәҗбүр булдым һәм, бөтен көчемне биреп, үзлегемнән белememне арттыру эшенә керештем. Яшәрлек акча табу өчен дәресләр бирдем, газеталарда, журналларда әдәби темаларга язган мәкаләләремне бастырдым. Мәкаләләрем өчен миңа бик аз түлиләр иде (бигрәк тә баштарак, оригинал мәкаләләремнең юлына 1,5 тиен генә бирәләр иде).

Миңа озак еллар зур мохтаҗлык кичерергә, ачлы-туклы яшәргә, ялангачлыкны татырга, шул ук вакытта бик тырышып, системалы рәвештә үзлегемнән белememне күтәрүне дәвам иттерергә туры килде.

Бүгенге туберкулезымның башлануы нәкъ менә шул шәкерт чагымда һәм яшь, башлап язучы вакыт кичергән авыр, ач, ялангач елларда булды.

---

[1] Яңа стиль белән 12 мартта.

III

ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕН, ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН ТУДЫРУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ ӨСТЕНДӘ ЭШЛӘҮ ЧОРЫ

1. 1907 елда «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле беренче әсәрем басылып чыкты (Казан, «Әльислах», 1907 ел, октябрь) [1]. Шуннан соң бер-бер артлы башка хикәяләрем, повестьларым, романнарым басылды. Мәсәлән, «Татар хатыны ниләр күрми», «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909), «Йөз ел элек», «Дингездә», «Карак мулла» (1911), «Сөю—сәгадәт», «Табигать балалары» (1914), «Яшь йөрәкләр» (роман), «Көтүчеләр», «Карт ялчы» (1912), «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914) һәм башкалар.

Матур әдәбиятка, беллетристикага хас алымнар, формалар белән фикер йөртелгән бу әсәрләрнең төп мотивы һәм эчтәлеге башлыча түбәндәгеләрдән гыйбарәт: мәсәлән, яшьләрнең — шәкертләрнең иске көнчыгыш-мөселман схоластикасына каршы көрәше; гаилә тормышындагы, уку йортларындагы, җәмгыятьтәге искелеккә каршы көрәш һәм, нихаять, патша, самодержавие, капиталистик җәмгыятьнең изүләренә каршы социаль революцион көрәш («Безнең көннәр» романы, 456 бит; ул 1914 елның сентябрендә Казанда басыла башлаган иде, ләкин патша цензурасы тарафыннан туктатылды; шуңа күрә бары революциядән соң гына матбугатка чыкты). Романда 1905 елгы революцион, социаль көрәш чагыла һәм бу көрәш артта калган, әзерлекләре җитәрлек булмаган татарлар арасындагы специфик һәм үзенчәлекле формаларда бирелә (...).

2. Әдәби әсәрләр иҗат итү — эшчәнлегемнең бер тармагы гына. Татар әдәбиятын тудыру һәм үстерү өлкәсендәге хезмәтләрем белән берәттән, мин, моннан егерме еллар элек, телебезнең һәм әдәбиятыбызның теориясе буенча, конкрет алганда, түбәндәге юнәлештә гыйльми тикшеренү эше башлап җибәрдем: а) татар әдәби теле теориясе һәм аны куллану; б) татар теле методикасы; в) татар әдәбияты теориясе һәм принциплары.

Шул заманда чыгып килгән газеталарда һәм журналларда бу мәсьәләләргә багышланган күп кенә мәкаләләр, очерклар бастырдым. Зур хезмәтләрем аерым китап булып чыктылар. Мәсәлән, «Татар сарыфы» (беренче басма, Казан, 1911; бишенче басмасы 1918 елда); «Татар нәхүе»; «Татар имлясы»; «Әдәбият кануннары» (беренче басмасы 1916; өченче басмасы 1919 елда); «Татар телен ничек укытырга» һәм башкалар.

Югарыда күрсәтелгән мәкаләләрнең һәм очеркларның кечкенә бер өлеше (1911—1924), бергә тупланып, «Имля, тел һәм әдәбият мәсьәләләре» исеме белән Татарстан дәүләт нәшрияты тарафыннан чыгарылды (беренче басмасы 1924; икенче басмасы 1927 елда, 143 бит (...).

3. Бу мәсьәләләрне теоретик яктан эшкәртү һәм хезмәтләремне бастырып чыгару белән бергә, мин урта һәм югары татар мәктәпләрендә тел һәм әдәбият укыттым (1915—1916 елларда [2] Уфада «Галия» мәдрәсәсендә һәм ике еллык педагогия курсларында).

Аңа чаклы мин Төньяк Кавказда кара нугайлар арасында (1907), Казагыстанда (1909) һәм Киевтә (1912—1913) укыткан идем.

Искәрмә рәвешендә шуны әйтергә кирәк: «Галия» мәдрәсәсендә укыган чакта мин, тарихтан «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән китап язып, 1909 елда аны Оренбургта бастырган идем. Ләкин бу китапның темасы минем өчен очраклы иде. Шуңа күрә, 1911 елда наширләр аны яңадан бастырып чыгарырга рөхсәт сорагач, бастырудан катгый баш тарттым, чөнки аның темасы минем специальностем өчен ят, э методологиясе хәтта шул замандагы карашымны да һич канәгатьләндерми иде.

Гомумән алганда, февраль революциясенә (1917) кадәрге еллар минем өчен, башлыча, татар әдәби телен һәм татар әдәбиятын тудыру, үстерү өстендә эшләү чоры булды; билгеле, мин ул замандагы тормыш шартлары, шәхси әзерлегем, патша жандармериясе һәм цензурасы мөмкинлек биргән дәрәҗәдә генә эшләдем.

---

[1] «Әльислах» газетасының 1907 һәм 1908 елларда чыккан саннарында басылды.

[2] 1915—1917 елларда.

IV

ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ПРОБЛЕМАЛАР

1917 елга кадәрге хезмәтләремнең төп өлкәсе теоретик һәм практик характердагы гыйльми-әдәби мәсьәләләр булды. Ләкин иҗтимагый-политик мәсьәләләр белән кызыксынуым түбәндәге формаларда күренде:

1. 1906—1908 елларда, мәдрәсәнең яңа карашлы шәкертләре арасында, политик хәрәкәттә катнашуга охшаган ерак бер омтылыш булды. Бу омтылыш «яшерен түгәрәкләр» оештырудан, шәкертләрнең «яшерен» кулъязма газеталарын, журналларын чыгарудан гыйбарәт иде.

2. 1912—1913 елларда Киевтә укытучы булып эшләгәндә, революцион мөселман студентларның яшерен оешмасында актив катнаштым. Квартирамда тентү булды һәм мине, башка 16 студент белән бергә кулга алып, Киев губерна төрмәсенең ялгыз камерасына яптылар. (Заманында бу турыда ул вакыттагы татар һәм кайбер рус газеталарында күп һәм җентекләп яздылар. «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә» исемле аерым брошюрам бар; 1922, Казан, Татобкомол.) Төрмәдән чыгарылганнан соң, февраль революциясенә чаклы патша полициясенең ачык күзәтүе астында яшәдем [1].

Дәүләт учреждениеләрендә һәм рәсми-иҗтимагый оешмаларда: земствода булсын, шәһәр управасында, дәүләт думасында, аның мөселман фракциясендә, җәмгыяте хәйрия дип аталып йөртелгән оешмаларда, шәрык клубларында һәм башка шуның кебек оешмаларда булсын, берсендә дә катнашмадым, эшләмәдем.

Гәрчә мин, профессиональ әдип булып, һәрвакыт зур мохтаҗлык күрсәм дә, наширләреңнең һәм редакторларның күп мәртәбәләр хезмәткә чакыруларына карамастан, аерым бер хәлне исәпкә алмаганда, 1917 елга кадәр аларның берсендә дә штаттагы сотрудник булып эшләмәдем, тел һәм әдәбият мәсьәләләренә багышланган мәкаләләремне аларда бары читтән торып кына бастырдым. «Аерым бер хәл» дигәнем болай булды: 1914 елда [2] мине «Аң» журналына (Казан) секретарь итеп чакырдылар, ләкин эш атмосферасының авырлыгы һәм үзем теләгәнчә эшләргә мөмкин булмау сәбәпле, өч айдан соң (1914 елның [3] декабрендә) секретарьлыкны ташларга мәҗбүр булдым һәм Кавказга киттем.

Ләкин «Аң» журналында өч ай секретарьлык итүем февраль революциясенә кадәрге вакыт эчендә редакциядә, штаттагы даими сотрудник буларак, бердәнбер хезмәтем булды.

V

ФЕВРАЛЬ РЕВОЛЮЦИЯСЕ ЧОРЫ

1. Февраль революциясенең беренче көннәрендә үк, иптәш Ф. Сәйфи-Казанлы белән берлектә, Уфада, киң масса өчен, «Ирек» газетасын оештырырга керештем. Редакторы мин булдым. Гәрчә иптәш Сәйфи, рәсми рәвештә, газетаның нашире булып саналса да, үзеннән-үзе билгеле, бөтен эшне бердәй башкардык, көрәшне бердәй алып бардык. Бер тиен акчабыз юк иде, ләкин без массаның ярдәменә таяндык. Газетаның беренче саны 1917 елның 30 мартында чыкты. Бөтен татар буржуазиясе җәмәгатьчелеге һәм милләтче буржуаз матбугат безгә каршы каты көрәшкә күтәрелде, хәтта кайбер очракларда безгә каршы погром оештырырга чакырдылар. Шуна карамастан, газетабыз шактый уңышлы таралды. Подписчикларның саны җиде меңгә җитте. Безнең «Ирек» исемле народниклык газетабыздан соң, Казанда, иптәш Әхмәдиев редакциясендә, киң масса өчен «Аваз» газетасы, аннары иптәш Мулланур Бахитовның (1918 елда Казанда чехо-словаклар тарафыннан атылды) һәм иптәш Исхак Рәхмәтул-

[1] Шулай ук жандарм идарәсенең яшерен күзәтүе астында да яшн.

[2] 1913 елда.

[3] 1913 елның.

линның турыдан-туры катнашы белән мөселман социалистлары комитеты органы «Кызыл байрак» газетасы чыга башлады. Платформаларыбызда һәм программаларыбызда кайбер фикер башкалыклары булуга карамастан, бу өч газетаның өчесе дә көчле оешкан һәм шактый бай нигезгә корылган татар буржуаз матбугатка һәм бөтен буржуаз милләтчелек хәрәкәтенә каршы бердәм фронт белән көрәш алып бардылар.

2. 1917 елның җәендә, средстволарга һәм әдәби көчләргә экономия ясау теләгеннән чыгып, «Ирек» газетасын революцион мөселман солдатлары оешмасының органы булган «Солдат теләге» исемле газета белән бергә куштык һәм «Безнең юл» дигән яңа гомуми исем белән чыгара башладык. Мин редакторы булдым, иптәш Ф. Сәйфи — секретаре. Бу газетада Газим Касыймов, Әлмөхәммәдов һәм хәзерге коммунистлардан башка күп иптәшләр катнаштылар.

3. Газетабызның төп лозунглары түбәндәгедән гыйбарәт иде: империалистик сугышка каршы көрәш; җирләрне конфискацияләү өчен көрәш; татар буржуаз милләтчелек оешмаларына каршы, татар буржуазиясенең экстерриториаль-автономияле хәрәкәтенә (Милли идарәгә) каршы көрәш һәм территориаль автономия (Тупраклы мохтарият) өчен көрәш.

Контрреволюцион Корнилов фетнәсеннән соң, югарыда күрсәтелгән лозунгларга Керенскийның Вакытлы хөкүмәтен тәнкыйтьләү һәм массаны «Бөтен власть Советларга» дигән лозунгка катгый эзерлек мәсьәләләре өстәлде.

Бу лозунгларның соңгысы масса күләмдә үткәрелгән солдатлар демонстрациясендә аеруча ачык чагылды. Большевикларның җирле оешмалары тарафыннан, сул эсерлар белән берлектә, үткәрелгән бу демонстрациядә без актив катнаштык. Без анда җиде-сигез мең солдатның җитәкчеләре булдык. Демонстрация вакытында мин үзем урамнарда, мәйданда һәм шулай ук мөселман солдатлары оешмасы бюросы урнашкан бинаның балконыннан торып: а) бетсен сугыш; б) җирләрне хәзер үк конфискацияләү; в) долой капиталист министрлар; г) милләтләрнең үзбилгеләнүе; д) бөтен власть Советларга һәм башка шуның кебек лозунглар буенча речьләр сөйләдем.

Бу демонстрация Октябрь революциясенә чаклы булды (иске стиль белән 1917 елның 9 октябренда). Миннән башка анда татар активистларыннан Утяшев (деникинчылар тарафыннан атылды), Баембитов, Галимҗан Әминов, Әлмөхәммәдов һәм башка иптәшләр дә катнаштылар.

4. Безнең февраль революциясе чорында татар буржуаз милләтчеләренә каршы алып барган көрәшебез, шул замандагы татар тормышы таләп иткәнчә, кайбер очракларда үзләренә хас специфик формаларда булды. Татар хезмәт массасы культура ягыннан артта калган, аз эзерлекле, үз сыйнфый оешмаларына бөтенләй берләшмәгән иде. Ул дини сөрем эчендә яши, бик күп төрле милләтчелек җепләре белән бәйләнгән, кирәкмәгән юк-барларга ышана иде.

Сыйнфый аңын уятып, аны буржуазиядән һәм алпавытлардан, кулаклардан һәм руханилардан аерып алу өчен, безгә «Бөтенроссия», «бөтен төрек-татар» күләмендә дип аталган гомуми мөселман җыелышлары, корылтайлар, съездлар, «милләт мәҗлесе» һәм башка шуның кебек урыннарның әле берсендә, әле икенчесендә катнашырга кирәк булды. Гәрчә болар «сыйныфларга бәйләнмәгән» булып аталсалар да, асылда буржуазия-алпавыт җыелышлары, корылтайлары һәм съездлары иде.

Мәсәлән, мин үзем Мәскәүдәге беренче мөселман съездында һәм Казандагы икенче мөселман съездында делегат булып катнаштым. Бу съездларда без, үз социалистик фракциябезне оештырып, милли буржуазиягә һәм руханиларга каршы аерым платформа белән чыктык. Бу фракциядә Шәһит Әхмәдиев, Ф. Сәйфи һәм башка иптәшләр катнаштылар. Съезддан соң без, җәмгыятьтә булсын, шулай ук матбугатта булсын, буржуазиянең йөзен фаш итү өчен зур кампания башлап җибәрә идек. Буржуазиянең, реакцион руханилар — мөфтиләр һәм муллалар белән берләшү максатыннан чыгып, илне федераль формада идарә итүгә каршы кылуен, җирләрне конфискацияләргә һәм социализацияләргә риза булмавын, хатын-кызларга тигез хокук бирергә теләмәвен фаш итә идек (1917 елның июль, август айларында чыккан «Ирек» һәм «Аваз» газеталарын карагыз).

Тышкы яктан «гомуми-милли» булып күренгән, асылда исә буржуаз рухта булган башка җыелышларда һәм съездларда да шулай катнаша идек: мәсәлән, гражданнар

хокукын саклау комитетлары, бюро, мөселман советлары дип аталган оешмаларда һәм башка шуның кебек урыннарда.

Безнең бу эшләребез большевикларның 1912—1914 елларда реакцион дәүләт думасында, контрреволюцион дәүләт киңәшмәсендә (Мәскәү, 1917), парламентка әзерлек алдында һәм Учредительное собраниедә катнашуларына беркадәр охшый төшә. Аларда, асылда, большевиклар уңай иҗади эш өчен түгел, ә бары тик, ул учреждениеләрнең трибуналарыннан файдаланып, киң күләмдә пропаганда һәм фаш итү эше алып бару өчен генә катнаштылар.

Безнең катнашу да шундый характерда булды.

Без һәр урында масса өчен әзерләнгән аерым платформабыз белән, асылда, милли-буржуаз юнәлешкә каршы куелган вак-буржуаз платформа белән, һәм сайлаулар вакытында үзебезнең исемлекләребез белән чыгыш ясамыйча калмый идек. Мондый очракларда көрәш һәрвакыт каты һәм кискен була иде. Бервакыт шундый хәл булды: мөселман Милли советының (Милли шураның) губерна съездында формаль демократик рамкаларда эш алып бару бик авырга туры килгәч, без, үзебезгә ияргән солдат массасына таянып, съездны формаль рәвештә таратмасак та, фактик таратты к.

Бу шундый уңай белән килеп чыкты: съезд җитәкчеләре, үзләренең формаль яктан күпчелек тәшкил итүләреннән файдаланып, миңа платформа турындагы мәсьәлә буенча өстәмә доклад ясарга сүз бирмәделәр. Шуның аркасында каты бәхәс башланды. Солдат иптәшләр миңа сүз бирүне таләп иттеләр. Бирмәгәч, каты шау-шу күтәрелде, бераз түбәләшеп алдылар һәм съездны тараттылар. Шуннан соң бер ай үткәч, бу съезд яңадан җыелды. Ләкин аны Уфада түгел, ә өяз шәһәре булган Бирскида, солдат массасыннан еракта җыйдылар (карагыз: Г. Әминовның «Пролетариат революциясе һәм татар-башкорт солдатлары» исемле китабын, 1929, Казан, Татарстан нәшрияты, 39—40 битләр).

Февраль чорындагы съезд һәм сайлау кампанияләребез һәрвакыт бик шау-шулы уза иде, аларның һәркайсында социалистик платформа белән һәм үз кандидатларыбызның зур исемлеге белән катнаша идек: шәһәр думасына, земствога һәм, ниһаять, Учредительное собраниегә сайлауларда шулай катнаштык.

Учредительное собраниегә сайлаулар вакытында көрәш аеруча каты булды. Без крестьян советы, мөселман советының сул канаты һәм мөселман солдатлары оешмасы белән берләштек. Уфа губернасындагы татарлар арасында ике исемлек көрәште: милли буржуазия тарафыннан куелган 1 нче номерлы исемлек, (бу исемлеккә руханиләр һәм кулаклар да кушылды) һәм 3 нче номерлы безнең исемлек. 3 нче номерлы исемлектә минем кандидатурам башта тора иде. Берничә айга сузылган каты көрәштән соң, без җиңдек. Безнең исемлек буенча Учредительное собраниегә 5 кеше, ә милли буржуазия исемлеге буенча бары бер кеше сайланды.

«Милләт мәҗлесе» дип аталган нәрсәдә дә без нәкъ шундый үк позициядә тордык (1917 ел, Уфа, ноябрь). Мәҗлес членнары ике лагерьга бүленделәр: 1) татарларга ориентация тотучылар: алар территорияле автономия яклы иделәр (Тупраклы мохтарият); 2) пантюркизм яклылар (төрекчеләр); алар экстерриториаль автономия ягында булдылар (Милли идарә).

Без анда нык берләшкән, бердәй фикердә булган сул социалистик фракция оештыра алмадык. Бары төрле юнәлештәге элементлардан торган бик чуар блок кына төзедек. Аның платформасы: а) пантюркизмга каршы, б) экстерриториаль автономиягә каршы көрәштән һәм а) татарларга ориентация тоту өчен, б) территорияле автономия өчен көрәштән гыйбарәт иде. Блок членнары түбәндәгеләр иде: а) татарлардан кайбер фронтовик большевиклар, б) максималистлар (Ш. Әхмәдиев), в) сул эсерлар (мин, Газим Касыймов, Әлмөхәммәдов һ. б.) һәм г) татар буржуа яшьләренең радикаль өлеше; бу чакта әле алар кызыл платформалар белән мавыгалар һәм вак буржуаз массаның кайбер өлеше белән багланышта торалар иде; ләкин бу яшьләр, бигрәк тә 1918 елдан соң, ачыктан-ачык контрреволюционер булып киттеләр. Безгә каршы актив көрәштеләр (мәсәлән, Алкин).

Большевиклар, сул эсерлар һәм максималистлар, кай чакларда бу чуар блоктан аерылып, ачыктан-ачык политик чыгышлар ясыйлар иде.

«Милләт мәҗлесе»ндә булган шундый бер хәлне искә алып үтәргә кирәк: Октябрь

революциясе платформасында торучы бер фикердәге иптәшләрнең кушуы буенча, иптәш Ш. Әхмәдиев Петроградка — Смольныйга, яңа оештырылган, башында иптәш Ленин торган Совет хөкүмәтенә котлау телеграммасы җибәрү турында «мәҗлескә» тәкъдим кертте. Мин, иптәш Әхмәдиевнең тәкъдимен яклап, чыгып сөйләдем. Буржуазия ягыннан ике оратор чыкты.

«Фракциябез» (тупракчылар) үзенең социаль чуарлыгын күрсәтте: Ленинга котлау телеграммасы җибәрү турындагы тәкъдимебезне тавышка куйгач, бары 17 тавыш алдык. Блогыбызның калган членнары Совет властена каршы иде. Тәкъдимебез үтмәде. Ләкин бу «мәҗлеснең» утырыш залында гына шулай булды. Астагы катта исә солдат иптәшләр «Милләт мәҗлесе»н куарга әзер булып көтеп торалар иде. Инде бөтен губернада, бигрәк тә эшче-крестьяннар арасында, урыннарда Совет властен урнаштыру өчен ачыктан-ачык эш алып барыла иде. Без чыгара торган «Безнең юл» газетасы илне советлаштыру линиясен үткәрде, Октябрь платформасында торды.

1917 елның декабрь ахырында мин, Учредительное собрание члены буларак, Петроградка киттем һәм анда Совет Хөкүмәте органнарында эшли башладым.

VI

ОКТЯБРЬ

1. Ленин декреты. 2. Учредилкада. 3. Өченче съездда. 4. ВЦИК члены. 5. Үзәк Мөселман комиссариатын оештыру. 6. Петроградта «Чулпан» исемле беренче зур, татар совет газетасын оештыру. 7. Хөкүмәтнең Мәскәүгә күчүе. Автономия мәсьәләсен эшкәртү. 8. Чехо-словакларга каршы. 9. Чигенгән вакытта Уфада һәм Казанда. 10. Коммунистик матбугатта эшләү. 11. Дошман тылында разведкада. 12. Татарстан республикасында эшләү.

1. Октябрь революциясеннән соң ике ай вакыт үткәч, Совнарком тарафыннан Үзәк Мөселман комиссариаты оештырылды. Мин председатель урынбасары булып билгеләндем. Төгәл булсын өчен, түбәндә Декрет текстын күчереп үтәм.

Халык Комиссарлары Советы Декреты

96. Мөселман эшләре буенча Комиссариат турында.

Милли эшләр буенча Халык Комиссариаты янында Эчке Россия һәм Себер мөселманнары эшләре буенча Комиссариат оештырыла.

Мөселман эшләре Комиссары итеп элекке Учредительное собраниенең Казан губернасыннан сайланган члены Мулланур Вахитов, аның урынбасарлары итеп элеккеге Учредительное собраниенең Уфа губернасыннан сайланган члены Галимҗан Ибраһимов һәм Оренбург губернасыннан сайланган члены Шәриф Манатов билгеләнә.

Халык Комиссарлары Советы Председателе
Вл. Ульянов-Ленин.
Милләтләр эше буенча Халык Комиссары
Джугашвили-Сталин.
Хөкүмәт Эшләре Управляющие
Вл. Бонч-Бруевич.

(«Временное Рабочее и Крестьянское Правительство» газетасы, № 12, 1918 ел, 13 январь; «Собрание Узаконений и Распоряжений Рабочего и Крестьянского Правительства», № 17, 918 ел, 23 январь, 243 бит.)

2. Бу беренче татар һәм башкорт («мөселман») Үзәк Совет учреждениесен оештыруның кечкенә генә тарихы бар.

Мин Уфадан Петроградка 1918 елның 5 январенда Учредительное собраниенең ачылачак көненә барып җиттем: вокзалдан туры Таврический сарайга киттем, һәм мәрхүм иптәш Я. М. Свердловның собраниене нәкъ ачкан һәм председатель сайлаткан моментына өлгердем. Үзеннән-үзе билгеле, мин бу мәсьәлә буенча тавышымны, большевиклар һәм сул эсерлар белән берлектә, Чернов кандидатурасына каршы, ягъни сул канат кандидатурасына бирдем.

Бу вакыт эчендә инде Учредительное собраниедә башында меньшевик Әхмәт-Бәк Салихов торган, элеккеге уң эсерлардан Шакир Мөхәммәтьяровның һәм Туктаровның (хәзер эмигрант) актив катнашулары белән «Мөселман социалистлары фракциясе» дип аталган фракция оешып өлгергән иде. Мин ул фракциягә кермәдем, чөнки сул эсерлар фракциясе члены идем. Мәгълүм булганча, ул вакытта сул эсерлар большевиклар белән тыгыз контактта баралар иде.

Совет Хөкүмәтенең декларациясеннән соң, Учредительное собраниенең күпчелеге бу декларацияне танырга теләмәгәч, большевиклар һәм сул эсерлар фракциясенең рәсми белдерүе булды һәм Учредительное собраниенең бөтен сул канаты шул ук көнне төнге бердә учредилка залын ташлап чыгып китте. Мин шул сул канат составында идем һәм алар белән бергә Учредительное собрание утырышын ташлап чыктым. Мөселман депутатларының башкалары барысы да уң канат белән бергә калдылар һәм учредилка платформасын якладылар.

3—4. Мәгълүм булганча, әлеге әһәмиятле вакыйгалар барган көнне Учредительное собраниенең утырыш залын ташлап чыккан сул канатның барлык членнары, Үзәк Башкарма Комитетының карары белән, Эшче һәм Солдат депутатлары Советларының 3 нче Бөтенроссия съезды составына кертелде. Шул карар нигезендә мин дә, тавыш бирү хокукы белән, съездга мандат алдым. Советларның 3 нче съездында Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты члены булып сайландым. Түбәндә шул документны күчереп үтәм:

ВЦИК члены билеты № 118

Эшче, Крестьян, Солдат һәм Казачи депутатлары Советларының Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты

Бу билетны күрсәтүче ип. Ибраһимов Галимҗан Гыйрфан улы Советларның 3 нче Бөтенроссия съезды тарафыннан, 1918 елның 15 январеннан 18 апрельгә кадәр срок белән, Эшче, Крестьян, Солдат һәм Казачи депутатлары Советларының Үзәк Башкарма Комитетына член булып сайланды.

Председатель *Я. Свердлов.*
Секретарь *Аванесов.*

(ВЦИК печате, Г. Ибраһимовның фото-рәсеме һәм имзасы)

5. Учредилка куылганнан соң, Казаннан М. Вахитов, Оренбургтан Ш. Манатов килде.

Алар килгәнче, мин инде Үзәк Мөселман комиссариаты турында Сталин һәм Песковский иптәшләр белән беседада булган идем.

Алар ризалыгы белән, мин элеккеге учредилкадагы мөселман социалистлары фракциясе дип аталган төркемнең кайбер вәкилләре белән сөйләшү алып бардым, аларны эшкә чакырырга теләдем. Ләкин алар барысы да Совет органнарында һичбер төрле эш эшләргә теләмәделәр, катгый баш тарттылар. Вахитов һәм Манатов иптәшләрнең килүе бик урынлы булды. Берничә көннән соң Комиссариат оештырылды һәм югарыда китерелгән Декрет басылып чыкты.

Иптәш Вахитов председатель булып билгеләнде, мин һәм Манатов аның урынбасарлары булдык. Безнең Комиссариатыбыз шундый бер үзәк булды ки, ул үзәк тирәсенә пролетариат революциясе яклы мөселман хезмәт ияләре тупланды. Аның үрнәге буенча урыннарда: Казанда, Оренбургта, Астраханьда, Архангельскида, Себердә, Донбасста һәм башка урыннарда, җирле Советлар янында, Мөселман комиссариатлары оештырылды, төрек-татар хезмәт халкын советлаштыру эшенә керешелде һәм контрреволюционер төрек-татар буржуазиясенә, аның «Милли шура», «Милли идарә», «Хәрби шура», Болак арты республикасы һәм башка шуның кебек төрле оешмаларына каршы каты көрәш башланды.

Җирле Советлар янында Мөселман Комиссариатлары оештыру турында иптәш Ленин имзасы белән РСФСР Халык Комиссарлары Советының махсус карары чыкты. Ул карарда түбәндәге сүзләр бар:

«Мөселман эшче һәм крестьяннарның ихтыяҗларын планлы рәвештә тәэмин итү һәм аларны Совет власте тирәсенә берләштерү өчен, үз территорияләрендә мөселман халыклары булган барлык өяз һәм губерна Советларына хәзер үк Мөселман комиссариатлары оештырырга һәм, җирле шартларның таләбеннән чыгып, аның кирәкле бүлекләрен булдырырга тәкъдим ителә. Комиссариатларны оештыру эшен коммунистлар яки сул социалист революционерлар платформасында торучы мөселман сул революцион оешмаларына тапшырырга.

Советларның башкарма органнарына Комиссариатларны оештыру эшендә бөтен ярдәмне күрсәтергә тәкъдим ителә.

Үзәк Мөселман комиссариаты тарафыннан расланганнан соң, Комиссариатлар юридик яктан танылган булып исәпләнәчәкләр». (ВЦИК «Известия»се, № 134, 30 июнь, 1918 ел.)

6. Үзәк Мөселман комиссариатында административ һәм оештыру эшләре алып бару белән бергә, мин 1918 елның январь урталарында «Чулпан» газетасын оештыру эшенә керештем. Бу бөтен Россиядәге төрек-татарлар арасында беренче зур, рәсми совет газетасы булды. Ул безнең Комиссариат органы булып чыкты. Мәскәүгә күчкәнче мин аның фактик редакторы булдым. Газетабызда большевиклар катнашкан кебек, сул эсерлар һәм максималистлар да катнаштылар. Шуннан соң урыннарда да татар совет газеталары оештырыла башлады. Татар буржуаз матбугатына каршы мәрхәмәтсез көрәш алып бару белән бергә, алар, башлыча, Совет власте принципларын һәм аның чараларын тормышка ашыру, нигезләү буенча эш алып бардылар, татар эшче-крестьян массасына илне советлаштыру юлларын күрсәттеләр.

7. Германия империалистик хәрби көчләренең Петроградка якынлашу куркынычы һәм башка сәбәпләр аркасында, Үзәк Совет Хөкүмәте органнары, шул исәптән безнең Комиссариат та, Петроградтан Мәскәүгә күчте. Мәскәүдә эш өчен уңайрак шартлар тудырылды. Комиссариат янында түбәндәге бүлекләр оештырылды: Хезмәт бүлеге, Мәгариф бүлеге, Җир бүлеге, Матбугат бүлеге. Соңгы бүлек, полиграфия көченнән һәм башка мөмкинлекләрдән кин рәвештә файдаланып, үзенең эшен җәелдереп җибәрде. Комиссариатыбызның Хәрби бүлеге эшен аеруча басым ясап күрсәтеп үтәргә кирәк. Ипташ Вахитов, Үзәк Мөселман комиссариатның бөтен эшендәге кебек үк, Хәрби бүлек эшендә дә бик зур роль уйнады. Гомумән ипташ Мулланур Вахитов бик оста оештыручы, атаклы оратор, эшчеләр массасы белән тыгыз бәйләнештә торган, революция эшенә җаны-тәне белән бирелгән бик тотнаклы кеше иде (...). Владимир Ильич Ленин аңа бик зур игътибар күрсәтте, аның революцион эшләренә мөмкин кадәр ярдәм һәм җитәкчелек итәргә тырышты. Гомумән ипташ Вахитовта профессиональ революционер (...) өчен кирәкле бик күп сыйфатлар бар иде. Соңыннан, Реввоенсоветның 1918 елның 20 маенда чыгарган № 286 приказы белән, Комиссариатның Хәрби бүлеге аерым Үзәк Мөселман Хәрби коллегиясе булып үзгәртелде. Председателе ипташ Вахитов булды.

Ипташ Вахитов исән вакыттагы кебек үк, ул һәлак булганнан соң да хәрби коллегия аерым татар частьлары оештыруда зур роль уйнады. Роталар, батальоннар, полклар, дивизияләр, аерым бригадалар оештырды. Алар күп кенә фронтларда, мәсәлән, чех-словакларга, Колчакка, шулай ук Урта Азиядә басмачыларга каршы сугыштылар.

7-а. Безгә, Мөселман комиссариаты җитәкчеләренә, төп мәсьәләләрнең берсе итеп татар-башкортлар өчен автономияле республика оештыру мәсьәләсе өстендә эшләргә туры килде.

Ул вакытта бу актуаль мәсьәлә иде: Оренбургта, Уфада, Казанда үткәрелгән съездларда, конференцияләрдә бу турыда бәхәсләр, чыгып сөйләүләр белән генә чикләнмәделәр, ә, кулларына корал тотып, канлы бәрелешләргә һәм сугыш хәрәкәтләренә башлап җибәрүгә кадәр барып җиттеләр. Шул сәбәпле безнең Комиссариатта татарлар өчен дә, шулай ук башкортлар өчен дә милли мәсьәләне конкрет формада хәл итү проблемасы җентекле рәвештә эшләнде. Бу мәсьәлә турында ипташ Сталин, Вахитов, Ибраһимов һәм Манатов (башкортлардан) күп күйган беренче положение 1918 елның 22 мартында рәсми рәвештә игълан ителде. Ләкин ул гына җитәрлек түгел иде. Тәмам тәртипкә салу һәм формалаштыру өчен, 18 нче елның маенда, безнең Комиссариатта, ипташ Сталин җитәкчелегендә, Оренбургтан, Казаннан, Уфадан, Екатеринбург-

тан, Сембердән һәм чувашлардан, марилардан килгән вәкилләр катнашы белән, киңәшмә үткәрелде (карагыз: «Правда» газетасы, май — июнь, 1918 ел; Касыймов. Татар-башкорт шуралар җөмһүрияте. Мәскәү, 1918 ел). Бу киңәшмәдә татар һәм башкортлар өчен Совет Социалистик Республика оештырырга карар чыгарылды. Оештыру съезды 1918 елның сентябрендә булырга тиеш иде. Моны тормышка ашыру өчен большевик Камил Якубов җитәкчелегендә (Казаннан; 1919 елның җәендә татар батальоны восстаниесе вакытында һәлак булды) оештыру Комиссиясе төзелде. Бу мәсьәләләрне эшкәртүдә мин турыдан-туры катнаштым, беренчедән, аның теоретик ягын, икенчедән, оештыру формаларын эшләштем, өченчедән, бу мәсьәләне массага аңлату өчен матбугатта мәкаләләр белән чыктым.

8. Бу мәсьәлә уңае белән мине Уфага һәм Казанга командировкага җибәрделәр. Сәяхәтем чех-словакларның мин командировкага барган районнарга һөҗүм итүләре вакытына туры килде. Милли республика оештыру, аның перспективалары, контрреволюцион «Милли идарә» оешмаларын бетерү (карагыз: «Татар кадетлары милли идарәдә нишләделәр» исемле китап, Мәскәү, 1918), чех-словаклар восстаниесе һәм бу бандага каршы эшче-крестьян массасын оештыру — менә болар барысы да эзерлексез халыкның, хәтта аның интеллигенциясенең дә башында буталышып беткәннәр иде. Миңа, урындагы шартлардан чыгып, югарыда телгә алынган мәсьәләләр буенча төрле формада докладлар ясарга һәм сөйләргә туры килде: а) Уфада — эшчеләр клубында, милли идарәләрне бетерү турында; «Госмания» мәдрәсәсендәге курсларда укучы укытучыларга Совет власте һәм милли мәсьәлә турында; б) Бирскида — Совет властеның чех-словаклар контрреволюциясенә каршы көрәше турында; в) Казанда — элеккеге Юнусов, хәзер Вахитов мәйданындагы гомуми митингта (большевик иптәш Сәетгалиев, максималист Ш. Әхмәдиев һәм башкалар белән бергә) һөҗүм итеп килүче чех-словаклар контрреволюциясенә каршы көрәш оештыру турында. Шул ук елның җәендә Казанда Үзәк Мөселман Комиссариаты бүлеге Бөтенроссия мөселман учительләре һәм мөгаллимнәренең 3 нче съездын (корылтаен) җыйды. Мин, җитәкче булып, Мәскәүдән командировка белән килдем, милли мәсьәлә һәм Совет властен тану, аңа кушылу турында доклад ясадым. Уңай характердагы резолюция кабул ителде. Съезд бик шау-шулы узды. Кайбер буржуаз интеллигентлар оятсыз рәвештә: «Чех-словаклар Самараны алганнар. Совет власте һәлак булырга тора, кәфене муенына уралган», — дигән кебек сүзләр сөйләделәр. Галиулла Касыймов һәм Ш. Әхмәдиев иптәшләр ярдәме белән кайберәүләрне кулга алырга, буржуазия газеталарын яптырырга, репрессив чаралар кулланырга туры килде.

9. Контрреволюция һөҗүм итеп килгән бу көннәрдә мин чын мәгънәсендә куркыныч районнарда булдым, дошманга каршы массаны оештыру өчен, көчемнән һәм мөмкинлегемнән килгән дәрәҗәдә агитатор пропагандист булып та, политработник булып та һәм язучы булып та эшләдем. Совет власте Уфадан чигенгәндә, минем кебек эштәге башка иптәшләр белән бергә, соңгы пароходларның берсендә эвакуацияләндем. Мәскәүгә Казан аркылы кайттым. Иптәш Вахитов, чехларга каршы сугышта катнашу өчен, Үзәк Мөселман комиссариаты отряды белән Казанга киткән иде, анда ул контрреволюция кулына эләкте һәм атылды.

Комиссариатның бөтен эше һәм аңа җитәкчелек итү башлыча минем җилкәдә калды. Бу читен иде, чөнки мин гәрчә һәр эштә, һәр мәсьәләдә, һәрвакыт бертөрле дә фикер аермабыз булмаган хәлдә большевик иптәшләр белән бергә барсам да, рәсми яктан сул эсер идем. Шул вакытларда сул эсерлар үзәк комитеты Совет властена каршы восстание күтәрде (Мирбахны үтерү, Сембердә Муравьев фетнәсе, властьның үзәк аппаратларыннан чыгу). Бу ике төрле хәлдән котылу өчен, мәсьәләне ачыктан-ачык куярга кирәк таптым. Владимир Ильич мине кабул итте, мин аңа үземнең чын мәсләгемне сөйләп бирдем. Ул миңа бу мәсьәлә турында катгый рәвештә әйтте: «Эшләгез», — диде. Шул чакта инде, контрреволюцион булып әверелгән сул эсерлар партиясендә рәсми торуыма карамастан, мин, билгеле, большевик иптәшләр белән бергә Үзәк Мөселман комиссариатының башында торып эшләвемдә дәвам иттем. Урыны туры килүдән файдаланып, фактик характердагы бер кечкенә искәрмәне әйтеп үтим: мин сул эсерлар үзәк комитетының контрреволюцион эшчәнлеген яхшы дип тапкан бер генә татар сул эсерын да хәтерләмим. Мәсәлән, Әхмәтҗан Алмаев, Крымов, Әлмөхәммәдов, Газим Касыймов... Әхмәдиев, Әминов, Утяшев, Рәхимкулов, Ходайбирдин

һәм башка иптәшләрнең барысы да Совет власте аларны кайсы постка куйса, шунда һичбер каршылыксыз, бөтен күнелләрен биреп эшләүләрендә дәвам иттеләр һәм пролетариат революциясенең барлык дошманнарына каршы актив көрәш алып бардылар.

Уралдан һәм Идел буеннан чигенгән күп кенә татар большевиклары һәм сул эсерлар Мәскәүгә, Үзәк Мөселман комиссариатына килделәр һәм шуннан алар я бу эшкә, я теге эшкә җибәрелделәр, фронтларда сугыштылар.

Чехлар Идел буеннан чигенгәннән һәм Казанны контрреволюциядән тазартканнан соң, Үзәк Мөселман комиссариаты, Милләтләр Халык комиссариаты белән берлектә, Казанга Мостафа Собхи, Ш. Әхмәдиев, Гайнуллин һәм башкалар составында бер зур комиссия җибәрде, ана Казанда яшәүче татарлар арасында совет, матбугат, культура эшләрен юлга салу, Совет органнарына ярдәм итү, береиче чиратта, контрреволюциягә каршы көрәш һәм башка шуның кебек эшләрдә булышу бурычы йөкләнде.

10. Минем сәламәтлегем беркайчан да канәгатьләнерлек түгел иде. Февраль чорында артык каты көрәш, шуның өстенә 1918 елны Петроградта ач үткәргән январь — февраль айлары, яз һәм җәй көннәрендә киреике хезмәт, бик начар ашап торып, бер үземә ун кеше өчен эшләргә туры килгән чаклар — болар барысы да сәламәтлегемне бик какшатты һәм мин, организмымны ныгыту өчен, Мәскәудән провинциягә — Казанга күчәргә мәҗбүр булдым. Сәламәтлегем беркадәр рәтләнгәннән соң, мин Казандагы большевиклар партиясе органнарында көчемнән килгән кадәр әдәби эшләр белән шөгыльләнә башладым: мәсәлән, «Эш», «Эшче», «Кызыл Армия» газеталарында һәм «Кызыл Шәрык» журналында (редакторы иптәш Борһан Мансуров). Шулай ук революцион-политик темаларга багышланган аерым китапларымны бастырып чыгарырга әзерли башладым: мәсәлән, «Шәрыкның бөек революционеры Мулланур Вахитов», «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (соңыннан бу китап зур формада, 147 бит булып, Казанда басылды) һәм башка хезмәтләр.

11. Гомумән, мин моиача бүленеп торган гыйльми-әдәби эшләремә бирелгәннән-бирелә бардым. Шулай да 1919 елның язында түзмәдем, фронтка киттем, олаучы ярлы татар булып киенеп, тиешле совет органнары мандаты белән 37 нче укчы полк аша Колчак тылына разведкага юнәлдем. Красноуфимск, Екатеринбург, Камышлов, Төмән, Ишим, Ялуторовск, Петропавловскиларны үтеп, Курган аркылы Н-нче дивизия штабына әйләнеп кайттым. Колчак контрреволюциясе тылында җыйган мәгълүматлар һәм материаллар турында дивизия политотделында, шулай ук ул вакытта Челябинскида торган 5 нче армиянең тиешле бүлегендә докладлар ясадым. Соңыннан бу сәяхәтем турында Уфада клубта киң масса өчен, Казанда татар хәрби-команда курслары курсантлары өчен ачык докладлар ясадым. Дошман тылындагы бу яшерен эшләрем турында «Дошманнар арасында дүрт ай» исемле зур бер мәкалә яздым. Бу мәкаләм башта «Кызыл юл» газетасында басылды (Уфа, 7 сентябрь, 1919 ел, № 29), соңыннан шул замандагы барлык татар газеталарында һәм «Кызыл Армия сафында татар-башкортлар» исемле бер җыентыкта (төзүчесе Кави Нәҗми, Казан, Дәүләт нәшрияты, 88—93 битләр) яңадан басылды.

Казанга кайтканнан соң, яңадан гыйльми-әдәби эшләргә бирелдем. Татарлар арасындагы революцион хәрәкәтне, партия тарихын өйрәнү, В. И. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итүне оештыру һәм тәрҗемәләрне редакцияләү төп эшем булды.

Бер үк вакытта педагогик эшчәнлегемне дә яңадан башлап җибәрдем: хәрби-команда курсларында һәм партия мәктәбендә политик белем укыттым, Казанда Татар Коммунистлар университеты ачылган көннән алып, ике мәсьәлә буенча лекцияләр укыдым: татар әдәбиятында марксизм методын куллану һәм ВКП(б) тарихы. Коммунистлар университетындагы лекцияләрем 1925 елга кадәр, ягъни Гыйльми үзәк председателе булып билгеләнүемә кадәр дәвам итте.

12. Октябрь революциясенең беренче елында миңа Үзәк Мөселман комиссариаты аппаратында администратор булып эшләргә туры килде. Шул вакыттан башлап, мин бернчә ел буенча партия-совет аппаратлары белән булган багланышымны даими саклап, башлыча коммунистлар партиясенең матбугат органнарында эшләдем һәм педагогик хезмәтләремне дәвам иттердем, команда курсларында, совет партия мәктәбендә, Татар Коммунистлар университетында түбәндәге фәннәрне укыттым: политик белем, татар әдәбиятында марксизм методын куллану, татарлар арасында революцион хәрәкәт, ВКП(б) тарихы.

Шуның белән бергә, көчемнән һәм мөмкинлегемнән килгән дәрәҗәдә, мин партия-совет эшләрендә дә катнаштым. Советлар съездларына һәм партия конференцияләренә сайландым.

Шулардан кайберләрен күрсәтеп үтәм:

а) Татарстан республикасы советларының IV съезды члены;

б) 1923 елда [Татарстан] Үзәк Башкарма Комитеты члены булып сайландым;

в) Казан Шәһәр советы члены булып тордым;

г) шулай ук [Татарстан] Советларының V съездында да тавыш бирү хокукы белән катнаштым;

д) бу съездда Үзәк Башкарма Комитеты члены булып сайландым. Аның документын күчереп үтәм:

Членлык билеты № 41

Бу билетны күрсәтүче иптәш Галимҗан Ибраһимов ТССР Советлары съездының V нче чакырылышы тарафыннан Советларның VI съездына кадәрге срок белән Эшче, Крестьян һәм Кызылармеецлар депутатлары Советларының Үзәк Башкарма Комитетына член булып сайланды.

ТССР ҮБК председателе *Шаһимәрдәнов*,
ТССР ҮБК секретаре *Петров*.

Казан, Кремль, 14 январь, 1925 ел.

е) 1925 елның 7 январенда Татарстан Мәгариф Халык комиссариаты коллегиясе члены, Гыйльми үзәк председателе, «Безнең юл» журналы редколлегиясе председателе һәм «Мәгариф» журналы редколлегиясе члены булып билгеләндем. Бу урыннарда 1927 елның мартына чаклы, ягъни авыру сәбәпле (туберкулезның III стадиясе, каверналарым бар, күп кан килә) Кырымга озатылганчы эшләдем (...).

VII

ПАРТИЯДӘ

(Сул народниклыктан революцион марксизм-ленинизмга)

Татарстан Социалистик Совет Республикасы төзелгән көннән башлап, авырып киткәнче (1927) җиде ел Казанда эшләдем. Түбәндәге ячейкаларда член булып тордым: 1) Болак арты-Плятән районында, Камил Якубов исемендәге типография эшчеләренең 8 нче номерлы ячейкасында; анда мин ВКП(б) сафына алындым; 2) Татарстан Коммунистлар университетының лекторы, укытучысы булып эшләгәндә, университет янындагы ячейкада; 3) Гыйльми үзәк председателе һәм Татарстан Мәгариф Халык комиссариаты члены булып торганда Татарстан Мәгариф Халык комиссариаты янындагы, шәһәрнең Югары районына кергән 11 нче номерлы ячейкада. Бу ячейкада мин партия регистрациясен дә үттем, 1927 елда 0979217 нче номерлы яңа партия билеты алдым.

Татарстан республикасының партия оешмасы мине партия-совет эшенең ниндиенә яхшырак әзерлекле итеп тапса, шуна җибәрде, ягъни гыйльми-әдәби эш өлкәсенә җибәрде.

Шул эшләрнең иң төп моментларына һәм тармакларына тукталам:

1. Югарыда әйтеп киткәнчә, мин партия мәктәбендә, команда курсларында, Татарстан Коммунистлар университетында эшләдем. Аннары Өлкә Комитеты мине Татарстан Мәгариф Халык комиссариатына эшкә җибәрде. Анда мин Мәгариф Комиссариаты коллегиясе члены, Гыйльми үзәк председателе, Татарстанны өйрәнү Гыйльми җәмгыятенең председатель урынбасары, Крайны өйрәнү бюросы председателе, «Безнең юл» журналы редколлегиясе председателе һәм «Мәгариф» исемле гыйльми-педагогик журнал редколлегиясе члены булып эшләдем. Бу учреждениеләрдәге хезмәтләремнең барысын да бик каты авырып киткәнче, ягъни 1927 елның 17 мартына хәтле башкардым.

2. 1922 елның 16 маенда ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитеты мине, партияле журналист буларак, иҗтимагый-әдәби мәсьәләләр буенча эшләү өчен «Кызыл Татар-

стан» газетасына (ВКП(б) Өлкә Комитеты органы) беркетте. Бу эшне мин Кырымга дәваланырга киткәнче өзлексез дәвам иттердем. Кайчакларда, теге яки бу очракларда, мәкаләләремне комсомолның Татарстан Өлкә Комитеты органы булган «Кызыл яшьләр» газетасында, «Яшь эшче» журналында (Мәскәү, ВЛКСМ Үзәк Комитеты янындагы Татбашбюро органы) һәм «Эшче» газетасында (Мәскәү, ВКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Татбашбюро органы) бастыргалый идем. Бу мәкаләләр, башлыча, эшче хәбәрчеләр хәрәкәтенә, яшь революцион язучылар әсәрләренә һәм пролетариат әдәбияты проблемаларына багышланган булалар иде.

3. ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитеты, партияле әдип дип, миңа, иптәш Исхак Рәхмәтуллинга һәм иптәш Латыйф Гомәровка Ленин әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү эшен оештыруны тапшырды. Өч кешелек бу комиссия ВКП(б) Өлкә Комитетының агитация һәм пропаганда бүлеге янында эшләде, Владимир Ильичның татар теленә тәрҗемә ителергә тиешле әсәрләренең исемнәрен күрсәтеп, бик җентекләп план төзеде. Бу план рус һәм татар телләрендә басылды. Шуның нигезендә, төрле мәсьәләләр буенча темаларга бүленгән, системалаштырылган рәвештә барлыгы 300 табак күләмендәге әсәр тәрҗемә ителергә тиеш иде. Председателе мин булган бу комиссия елдан артык эшләде (1924—1925) һәм татар коммунист әдипләр җитәкчелегендә берничә тәрҗемә коллективы оештырды. Бу коллективларның эшләре безнең баш редакцион комиссия аркылы уза иде.

Мин үзем, иптәш Рәхмәтуллин белән берлектә, Ленин әсәрләренең татар телендәге берничә җыентыгын һәм күп кенә брошюраларны редакцияләдем. Безнең комиссия төзегән план мин Казаннан киткәннән соң шул комиссиядә эшләүче башка иптәшләр тарафыннан, мәсәлән, иптәш Галимҗан Нигъмәти һәм башкалар тарафыннан әкренләп тормышка ашырылды.

4. Партия тарафыннан үткәрелгән төрле кампанияләр вакытында, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты кушуы буенча, коммунист язучы буларак, миңа үтәргә туры килгән заданиеләрнең барысын да санап чыгу һич мөмкин түгел. Өлкә Комитеты кушуы буенча үтәгән эшләремнең характерын һәм типларын ачыклар өчен генә түбәндәге өч эшне күрсәтеп үтәм: 1) 1925 елда, «Правда» газетасында басылып чыккан мәкаләләрдән җыеп, татар телендә «Троцкийның ленинизмга каршы көрәше» дигән җыентык оештырдым һәм редакцияләдем (150 бит, Казан, нәшрият һәм матбугат комбинаты); 2) беренче революциянең 20 еллыгы уңае белән, ВКП(б) Өлкә Комитетының Партия тарихы бүлеге кушуы буенча, «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» исемле гыйльми-тарихи хезмәт яздым (1926 елда, Казанда, Партия тарихы бүлеге иссменнән, рус һәм татар телләрендә басылды, 235 бит); 3) татар телендә чыккан беренче большевистик «Урал» газетасының (фактик редакторы, оештыручысы һәм җитәкчесе 1912 елда вафат булган большевик Ямашев иде) егерме еллыгы уңае белән, Татарстан Өлкә Комитеты кушуы буенча, «Урал» һәм уралчылар» исемле монография яздым (1927, Казан, Татарстан Дәүләт нәшрияты, 44 бит).

5. Оешма тарафыннан гыйльми-әдәби заданиеләр йөкләтелгән партия члены һәм язучы буларак, миңа партия оешмасы аппаратында эшләргә туры килмәде, ләкин аның төрле киңәшмәләрендә һәм комиссияләрендә һәр вакыт катнашып килдем, шулай ук Өлкә конференцияләрендә дә катнаштым. Шундый документларның берсен күрсәтеп үтәм:

Мандат

Бу мандатны күрсәтүче, РКП(б)ның Гомуми шәһәр район оешмасы делегаты иптәш Г. Ибраһимов чыннан да РКП(б)ның Тат. Соц. Сов. Республикасы X Өлкә конференциясенең члены булып тора.

Мандат комиссиясе: Председатель *Г. Касыймов.*

Секретарь (Имза).

Печать.

1 январь, 1925 ел.

Бер белешмә

Бу урында фактик характердагы бер белешмә бирергә кирәк табам.

Мин революцион марксизм-ленинизмга вак буржуаз баткаклыгы, сул народниклык аша килдем. Югарыда берничә мәртәбә әйтелеп үтелгәнчә, революциянең беренче елларында мин сул социалист революционерлар интернационалистлар партиясендә член булып тордым. Гәрчә большевик иптәшләр белән һичбер төрле фикер каршылыкларына килмичә эшләсәм дә, шулай да ел ярым чамасы рәсми рәвештә сул эсер булып саналдым. 1918 елның февраленнан башлап, мин сул эсерлар партиясе үзәк комитеты үткәргән линиядән читләшә башладым. Шуларның кайберләрен күрсәтеп үтәм:

а) 1918 елның башында, әле Петроградта чакта, Брест килешүе турында сөйләшүләр барган көннәрдә, мин сул эсерлар фракциясе карарына буйсынмадым, ВЦИК утырышында (ул вакытта мин аның члены идем) Германия белән килешү договорына каршы тавыш бирмәдем, моның өчен мине эсерлар партиясеннән чыгарабыз дип янадылар. Ләкин янауларын тормышка ашырмадылар.

б) Килешүгә кул куелганнан соң, үзегезгә билгеле, сул эсерлар үзәк комитеты үз партиясе членнарын Совет властеның үзәк аппаратларыннан чакырып алырга карар итте. Ләкин мин постымда калдым. Бу постка мин иптәш Ленин... кул куйган декрет белән билгеләнгән идем һәм иптәш Вахитов Казанга киткәннән соң (1918 елның июль — август айлары), үзем Казанга киткәнче, озак айлар Үзәк Мөселман комиссариатының башында торып, коммунист иптәшләр белән бергә эшләдем (бу уңай белән Владимир Ильич тарафыннан кабул ителүемне югарыда әйтеп үткән идем инде).

в) Шулай ук мин сул эсерларның Кызыл Армия оештыру, җир политикасы, зур хуҗалыклар һәм башка шуның кебек мәсьәләләр турындагы позицияләре белән дә килешмәдем. Гомумән мина, актив работникка, партиянең үзәк комитеты белән һәрвакыт фикери каршылыкта булу искиткеч авыр иде.

г) Сул эсерлар партиясе үзәк комитеты 1918 елның 6 июлендә Мәскәүдә Германия посолы Мирбахны үтергәннән, Совет властена каршы баш күтәргәннән, Сембердә, Көнчыгыш фронтында Муравьев фетнәсеннән соң, ягъни ул ачыктан-ачык хыянәтче контрреволюцион юлга басканнан соң, инде контрреволюцион партия булып әверелгән сул эсерлар партиясе белән идеологик һәм организацион багланышларымның барысын да өздем.

Бу белешмәгә шулай ук фактик характердагы тагын бер әһәмиятле мәсьәләне өстәргә кирәк табам:

Сул эсерлар партиясендә член булып торган заманда җыелышларда, митингларда булсын, матбугатта һәм административ эштә булсын, бер урында да революциянең нигез мәсьәләләре турында большевик иптәшләр белән бер тапкыр да җитди фикер каршылыкларына килгәнем, бәхәсләшкәнем һәм полемикага керешкәнем булмады.

Көрәшче, полемист журналист һәм работник буларак, минем бөтен көчем буржуаз хәрәкәткә һәм аның лакей агентларына каршы юнәлдерелгән иде.

1920 елда мин РКП(б) сафына кердем. Минем партия стажымны билгеләгәндә, югарыда күрсәтелгән моментларны исәпкә алдылар. Шуна нигезләнеп, стажымны 1917 елның 15 апреленнән санадылар.

Мәгълүм булганча, Коммунистлар партиясенең шул вакыттагы уставы буенча, революцион сул социалистлар партияләренең элеккеге членнарын (шул исәптән сул социалист-интернационалистларны да) РКП(б) сафына кабул иткәндә, кандидат итеп тотмыйча, элеккеге стажлары белән алырга мөмкин иде.

Татарстан республикасының коммунистлар оешмасы (Казан), минем партиядә тору стажымны билгеләгәндә, РКП(б) нын шул чактагы уставындагы югарыда күрсәтелгән әлеге моментны искә алды. Минем стаж мәсьәләсе 1921 елда партияне чистарткан вакытта, 1927 елда яңадан регистрация үткәргәндә һәм партия тормышындагы башка хәлләрдә дә Татарстан Өлкә Комитеты һәм шулай ук ВКП(б) ҮК тарафыннан бер төрле дә каршылыкка очрамады.

Бу кыскача белешмәдә әйтеп китәргә кирәк тапкан төп мәсьәләләр менә шулар.

Югарыда, шушы VII бүлекнең 1, 2, 3, 4 һәм 5 нче абзацларында күрсәтелгән, гыйльми-әдәби квалификацияле коммунист буларак мина башкарырга туры килгән

хезмәтләрнең барысы да партия оешмасының махсус заданиеләре нәтиҗәсе булып торалар.

Ләкин коммунист язучының бурычлары болар белән генә чикләнми. Тегеләрне, я бу заданиеләрне, зурларын да, кечкенәләрен дә үтәү эше, үзеннән-үзе билгеле, һәрбер дисциплинаны коммунистның бурычы. Мин үземне шундый коммунист итеп исәплим. Большевикларның коммунистлар партиясе, Коминтерн секциясе буларак, дөнья күләмендәге шундый бер революцион көч булып тора ки, бу көч, кешенең кешене эксплуатацияләвен юк итү һәм пролетариат диктатурасының авыр юлы аша бөтен дөнья-ны революцион үзгәртеп кору өчен, эшчеләр сыйныфы тарафыннан алып барылган бөтен дөнья күләмендәге көрәшкә җитәкчелек итә.

Коммунист язучының иҗаты һәм аның бөтен гыйльми-әдәби хезмәте менә шул бөек көрәшнең чагылышы һәм коралы булырга, көрәшүче кешелек җәмгыятенең шул төп фикере белән органик рәвештә сугарылырга тиеш.

Төп максат шундый. Барлык коммунист язучылар алдына, тел һәм милләт аерымлыкларына карамастан, шундый гомуми төп бурыч куелган.

Мин үземне бу армиянең солдаты итеп, коммунистлар партиясе җитәкчелегендә бара торган гомуми фронтның татар участогына куелган көрәшчесе итеп саныйм.

Язучылар оешмасы мәсьәләсенә килгәндә, ВАПП линиясендә торам (Пролетариат язучыларының Бөтенсоюз Ассоциациясе). Тик авыру сәбәпле, оешмада торып эшләрлек хәлем юк.

Кырымда дәваланып яткан хәлемдә, ТАПП (Пролетариат язучыларының Татарстан Ассоциациясе) җитәкчеләре белән даими бәйләнеш тотарга тырышам.

Иҗатымдагы кайбер конкрет моментларны ачыклау өчен, гыйльми-әдәби эшләремнең төп юнәлешләрен күрсәтеп үтүне кирәк табам.

Бу турыда алдагы бүлектә.

VIII

ИДЕОЛОГИЯ ФРОНТЛАРЫНДА

Гәрчә төп специальностем гыйльми-әдәби хезмәт булса да, кайбер чорларда, мәгълүм иҗтимагый бурычлар таләбеннән чыгып, мина көрәш мәйданын киңәйтергә һәм көрәшнең үзәк өлешен сәнгать һәм фән өлкәсеннән иҗтимагый-политик көрәшләр аренасына күчерергә туры килгәли иде.

1917, 1918, 1919 еллар тормышымның нәкъ менә шундый чоры булды.

Бу елларда мин, кин көрәш фронтына ташланып, организатор-администратор булып та, агитатор-пропагандист булып та һәм журналист булып та эшләдем.

Бу чорда мин күбрәк иҗтимагый-политик темаларга мәкаләләр яздым һәм аларны, башлыча, вакытлы матбугатта бастырдым.

Мәкаләләремнең формалары, эчтәлекләре һәм характерлары революциянең гомуми барышы унае белән татар массасы алдында торган бурычлар белән билгеләнде.

Татар массасына, гомумән, татарлар арасындагы сыйнфый көрәш турында иң элементар белем бирергә кирәк иде, аерым алганда, популяр мәкаләләр бирү таләп ителә иде.

Татар буржуазиясе матбугаты социалистик хәрәкәткә каршы мөмкин булган барлык провокацион ялганнарны таратты. Буржуаз милләтчелек хәрәкәтенең һәм аның оешмаларының сыйнфый йөзен һәрвакыт фаш итеп торырга кирәк иде.

Матбугат аша татар буржуазиясенә каршы көрәш февраль чорында да шактый каты булды, әмма Октябрь революциясеннән соң ул татар буржуаз матбугат тарафыннан чиктән тыш формада алып барылды.

Октябрь революциясе һәм аның казанышларын нығыту өчен актив һәм кыю көрәшүче иң күренекле әдипләрнең берсе буларак, минем үземә татар буржуаз милләтчә контрреволюцион матбугатның һәм буржуаз җәмәгатьчелекнең явыз бәйләнүләренә һәм көрәшләренә күп мәртәбәләр каршы торырга туры килде.

Ул вакытта безнең өскә ташланган иң көлке һәм провокацион «гаепләрнең», шуның белән бергә ялганнарның, гайбәтләрнең үзәк моменты шул булды: алар Совет

властен рус булмаган милләтләрне җәберләүдә гаепләделәр. Ул чакта алар бу турыда түбәндәгеләрне яздылар:

«Элек рус самодержавиесе инородецларга карата нинди милли политика алып барган булса, имеш, Совет власте да шул иске политиканы дәвам иттерә».

«Имеш, Совет власте төрек-татар халыкларының бөтен милли һәм мәдәни байлыкларын корал көче белән тар-мар итү өчен генә барлыкка килгән».

Безнең өскә бу кара провокацияне Мәскәүдә чыгып килгән «Ил» газетасы ташлады (редакторы хәзер эмигрант, авктивист). Аннары аны бер көтү татар буржуаз газеталар күтәреп алдылар: мәсәлән: Казанда «Кояш», «Корылтай», Уфада «Тормыш» (редакторы эмигрант), Сембердә «Җөмһүрият» һәм башка шуның кебекләр.

Ул чакта бу көрәшнең мәгънәсе нәрсәдән гыйбарәт икәнен кин катлау татар массасы начар төшенә иде әле. Безгә, бик аз санлы совет журналистларына, татар буржуазиясенең бу провокацион чыгышларын күптән түгел генә оештырылган совет газеталары битләрендә фаш итәргә туры килә иде.

Мин хәрби кеше түгел. Шулай да гражданнар сугышы елларында язган ижтимагый-политик мәкаләләремдә Совет илен саклау, контрреволюциягә каршы көрәшкә татар массасын оештыру моментлары төп мәсьәләләр булып тордылар.

Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, тыныч төзелеш чоры башлану унае белән, пролетариат революциясе алдында торган теоретик проблемаларны тирәнтен өйрәнү, эшкәртү һәм аларны масса өчен татар телендә бастырып чыгару мөмкинлеге туган кебек иде. Ләкин Идел буендагы куркынычлы ачлык кризисы яңадан бөтен көчебезне һәм игътибарыбызны ачлык белән көрәшкә юнәлдерергә мәҗбүр итте.

Ачлыкка каршы көрәш мәсьәләләренә багышланган мәкаләләремне бастыра бару белән бергә, җәмәгатьчелек игътибарын ачлык белән көрәш фронтына юнәлдерер өчен, ач балалар файдасына «Ярдәм» исемле ике җыентык чыгардым (1921—1922 еллар).

Тик ачлык куркынычы бетерелгәннән соң гына гыйльми-әдәби фронтларда тирәнтен эшкәртелгән марксистик хезмәтләр булдыру өчен яңадан шартлар туды.

Мәгълүм булганча, культуралары артта калган халыкларның работниклары, әзерлекле көчләрнең соң чиктә азлыгы аркасында, һәрвакыт бик күп төрле эшләрне, вазифаларны берьюлы алып барырга мәҗбүр булалар.

Мин гыйльми-әдәби аренага чыкканда, татар халкының культурасы бик ярлы иде. Шуна күрә мина берьюлы берничә төрле вазифаны үтәргә туры килде.

Октябрь революциясеннән соң минем элеккеге специальностьларыма тагын бер тикшеренү тармагы — революцион хәрәкәтне өйрәнү тармагы өстәлде.

Шулай итеп, минем идеология фронтындагы эшләрем түбәндәге өч тармакка бүленде:

1) татарлар арасындагы революцион хәрәкәт тарихын өйрәнү; 2) марксистик әдәбият белеме; 3) матур әдәбият.

1. Россиядәге гомуми хәрәкәт белән багланышта татарлар арасындагы революцион хәрәкәт тарихын өйрәнү

(...)

«Вестник научного татароведения»нең 1928 елгы 8 нче санындагы библиографиядә минем бу мәсьәләгә багышланган хезмәтләрем тулысынча күрсәтелеп бетмәгән булсалар да, аерым хезмәтләремә җентекләп тукталып тормыйм... «Галимҗан Ибраһимов» исемле җыентыкта (Сафа Борһан, Г. Нигъмәти һәм башка иптәшләр редакциясендә, 170—177 битләр)... минем бу хезмәтләрем беркадәр тикшереп [узыла]... Монда мин... [шул җыентыкта күрсәтелгән] хезмәтләрдән файдаланам (...).

а) Касыймовның «Милли идарәдә кадетлар нишләделәр» исемле җыентыгына сүз башы (1918, Мәскәү, 1—20 битләр).

б) «Шәрыкның бөек революционеры Вәлиханур Вахитов» (1922, җыентыкта шул ук исемдәге мәкалә).

в) «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (1920—1922, Казан, 147 бит).

г) «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә» (1922, Казан).

д) «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» (1924, Мәскәү).

е) «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» (1926, Казан, 235 бит).

ж) «Урал» һәм уралчылар» (беренче татар эшче газетасының егерме еллыгы унае белән, 1927).

Бу мәсьәлә турында аерым китап булып чыккан хезмәтләремнән тыш, материалларга, документларга, шулай ук бу эшнең методына караган күп кенә мәкаләләрем газета һәм журнал битләрендә басылды. Хәзергә кадәр аларны бергә туплый алганым юк.

Авырый башлаганчы, Татарстан Өлкә Комитетының кушуы буенча, татарлар арасындагы революция хәрәкәтләре турындагы китабымның икенче кисәген «Октябрь революциясендә татарлар» исеме белән язарга керешкән идем. Бу китап Октябрь революциясенең уникенче елына басылып чыгарга тиеш иде. Ләкин кинәт каты авырып китүем башка эшләремә дә һәм моңа да комачаулык итте.

2. Марксистик әдәбият белеме

1918, 1919, 1920 һәм 1921 елларда басылган мәкаләләремдә мин бу темага төрле уңай белән кагылгалап киткән идем. Ул мәкаләләремдә мин әдәби әсәрләрнең сыйнфый һәм материалистик нигезләрен күрсәтеп үттем яки түбән катлаудан чыккан яшь революцион көчләрнең ижатларын алга сөрдем, яки, аерым очракларда, эстетикадагы идеализм мәктәбе вәкилләре белән бәхәскә керештем. Ләкин төрле мәкаләләремдә сибелеп яткан бу фикерләремне бер тәртипкә салырга бары 1922 елда, ачлыктан соң гына керештем.

Очраклы сәбәп чыгып, «Татарстан хәбәрләре» газетасында бер реакцион әдәби теоретик белән бәхәс башланып китте (1922 ел, 5—7 март). Аңа каршы мин, татар ижтимагый тормышында кулланырга яраклы итеп, әдәбият мәсьәләләре буенча марксизм нигезләрен аңлатып язып чыктым. Шул уңай белән татар әдәбияты тарихын түбәндәге өч дәвергә бүлдем: Көнчыгыш реакцион феодализмы дәвере, буржуазия хакимлеге дәвере һәм, ниһаять, бүгенге әдәбият, пролетариат революциясе дәвере. Пролетариат революциясе дәверендәге татар әдәбиятының төп принциплары татар матбугатында беренче тапкыр бу мәкаләләрдә күрсәтелделәр.

«Ижтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» дип аталган («Безнең юл» журналы, 1922, № 1 һәм № 2), махсус язылган фәнни-марксистик мәкаләмдә мин бу фикерләремне тагын да киңрәк җәелдердем. Аннары, 1922—1924 елларда, газета-журнал битләрендә, аерым әдәби әсәрләрне тикшергәндә бу фикеремне үткәрдем. Бу мәкаләләремнең кайберләре «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1911—1923) исемле китабымда тупланганнар (Казан, 1924; икенче басмасы, 1927).

1924 елда мин «Пролетариат әдәбияты» исемле аерым китап чыгардым (Мәскәү, Нәшрият [кооперативы] басмасы). Анда мин, Плеханов һәм башка марксистларның хезмәтләреннән файдаланып һәм рус әдәбиятын тикшерүдә марксизм фәне тарафыннан эшләнгән положениеләргә таянып, бу мәсьәләне татар әдәбиятына карата эшкәрттем.

Бу фронттагы көрәшне көчәйтү өчен, 1924 елда мин «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» исемле китабымны бастырдым (Мәскәү, Нәшрият кооперативы). Анда, төрек-татар эмигрантларының чит илләрдә бастырган әдәби материалларына нигезләнеп, Казаннан, Кырымнан һәм Бакудан качкан төрек-татар ак эмигрантлары идеологиясенең сыйнфый, буржуаз-контрреволюцион асылын фаш иттем. Минем бу китабым, әзербайҗан һәм үзбәк телләренә тәрҗемә ителеп, Бакуда, Сәмәркандта басылып чыкты. Китабымда төрек-татар телләре турында аерым бүлек бар, ул бүлектә мин пантюркизмга каршы электән килгән көрәшемне яңартып җибәрдем (46—56 битләр). 1927 елда тел, әдәбият һәм культура мәсьәләләренә багышланган «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» исемле китабымны яздым (Казан, 40 бит).

Бу өлкәдәге соңгы китабым — «Урал» һәм уралчылар». Татар телендә беренче большевистик газета булган «Урал»ның егерме еллыгы уңае белән язылган бу китабымда бөтен татар вакытлы матбугатына сыйнфый анализ бирелә һәм беренче татар эшче газетасының туу тарихы, программасы, тактикасы күрсәтелә. Бу китабым авырый башлавымнан ай ярым элегрәк дөньяга чыкты.

Тел һәм әдәбият мәсьәләләре өстендә эшләгәндә ясалган бер хатам турында берничә сүз әйтеп китүне кирәк табам.

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатында Гыйльми үзәк председателе булып эшләгәндә (1925—1927), тоткан урыным буенча, мина төрле гыйльми җәмгыятьләрнең, әдәби оешмаларның җитәкчелек эшендә катнашырга һәм гыйльми командировкаларда булырга туры килә иде. Мәсәлән, Татарстанны өйрәнү гыйльми Җәмгыятенең президиумында эшләдем, СССР Фәннәр академиясенең ике йөз еллык бәйрәмендә катнашу өчен, Казан галимнәреннең җитәкчесе булып, Ленинградка, Мәскәүгә бардым (1925).

Мәгълүм булганча, 1926 елның февраль — март айларында Бакуда беренче Тюркология съезды булып узды. Бу съездга Татарстан Мәгариф Халык комиссариатының гыйльми оешмалары исеменнән Татарстан делегациясе председателе итеп мине командировать иттеләр. Съездның оештыру комиссиясендә эшләдем, президиум члены булып сайландым. Съездның көн тәртибендә торган барлык мәсьәләләрне тикшергәндә, безнең делегациябез актив катнашты, үзенең зур әзерлекле һәм квалификацияле икәнен күрсәтте, әмма бер мәсьәләдә безнең зур хатабыз булды. Бу хатаның җаваплылыгы, билгеле, безнең өскә, Татарстан делегациясенең коммунист членнарына төшә. Алар арасында, мәсәлән, миннән башка Сәлах Атнагулов кебек җаваплы работниклар бар иде. Съездда Татарстан делегациясе декларациясе белән мин чыктым. Декларациянең төп фикере түбәндәгедән гыйбарәт иде: ягъни без, әлифбабызны латинлаштыруга принципиаль каршы булмасак та, шулай да Татарстанның бүгенге конкрет шартларында шрифтларны латинлаштыруны тормышка ашыру мөмкин түгел дип саныйбыз (карагыз: «Всесоюзный Тюркологический съезд в Баку», съездның стенографик отчеты, рус телендә, Бакуда басылган, 277—280 битләр).

Съезддан соң Казанда әлифба мәсьәләсе буенча дискуссия ачылды. Башта партияле иптәшләрнең тар даирәсендә, аннары коммунистик матбугатта. Мин «Кызыл Татарстан» газетасы (ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитеты органы) битләрендә барган бу дискуссиядә актив катнаштым, югарыда әйтелгән төп фикерне киң итеп язып чыктым.

Дискуссия тәмамланганнан соң бераз вакыт үткәч, Татарстан республикасының югары партия-совет органнары бу мәсьәлә буенча билгеле карар кабул иттеләр. Яңа әлифба рәсми танылды.

Кырымда дәваланып ятуыма һәм авыру сәбәпле бер эшкә дә катнаша алмавыма карамастан, шулай да әлифба мәсьәләсендәге хатамны ачыктан-ачык тануны үземнең партия бурычым итеп санадым һәм җәмәгатьчелекне матбугат аша актив эшкә, яңа татар әлифбасын тиз арада зыянсыз рәвештә тормышка ашырырга чакырдым (карагыз: «Кызыл Татарстан», 1928 ел, 13 май, № 109, Казан).

3. Матур әдәбият өлкәсендәге эшләр

1917, 1918 һәм 1919 елларда мин бөтенләй политик көрәш белән мәшгуль булдым, каләмемне, башлыча, политик мәсьәләләрне аңлатып бирүгә һәм пролетариат революциясенә бәйләнешле вакыйгаларны матбугат битләрендә яктыртуга хезмәт иттердем. Билгеле, минем бу хезмәтләрем эченә татарлар арасындагы буржуаз-милләтчелек хәрәкәтен фаш итеп язган полемик мәкаләләрем дә керәләр.

Бу өч ел эчендә мин бер әдәби әсәр дә язмадым. «Безнең көннәр» исемле революцион романымның кулъязмасы барлыгын, 1914 елда язылган бу әсәремнең шул ук елны Казанда басыла башлавын, ләкин патша цензурасы тарафыннан туктатылуын югарыда телгә алып киткән идем. 1919 елда аны басарга бирдем. Роман 1920 елда матбугатка чыкты (трилогиянең беренче кисәге, 454 бит).

Бу хезмәтем турында бик күп тәнкыйть-рецензия мәкаләләре бар. Шуларның бары өчесен генә күрсәтеп үтәм: «Кызыл Шәрык» журналында (Казан, 1920, № 3—4, 142—145 битләр) иптәш Фатих Сәйфи-Казанлы тәнкыйте; иптәш Галимҗан Нигъмәтинең «Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә революция мотивлары» исемле мәкаләсе («Галимҗан Ибраһимов», җыентык, Казан, 1928 ел, 48—68 битләр); проф. Фалевның «Революцион роман» исемле рецензиясе («Фән һәм тәгариф» журналы, Төркстан Мәгариф Халык комиссариаты органы, Ташкент, 1922, № 1).

1920 елда «Яңа кешеләр» исемле драма яздым. Ул Октябрь революциясенең өч

еллыгын тантаналы рәвештә бәйрәм иткән көнне сәхнәгә куелды. Драмада, башлыча, татар районнарындагы гражданнар сугышы тасвирлана.

1922 елда «Кызыл чәчәкләр» исемле повестемны тәмамладым. Ижатымның башлангыч елларында язган әсәрләремдә, мәсәлән, «Карт ялчы» (1912), «Көтүчеләр» (1914)[1] исемле хикәяләремдә авыл ярлылары тормышы, ә «Безнең көннәр» (1914) романында яңа туып килгән татар эшче сыйныфы вәкилләре тасвирланган булса, «Кызыл чәчәкләр» повестенда инде төрле катлаулар арасындагы көрәш һәм сыйнфый дифференциация шактый өлгергән калән белән бирелде. Бу повестьта шулай ук татар массасының контрреволюциягә каршы көрәш фронтларында катнашы — чехларга, Колчакка, басмачыларга һәм башка шуның кебекләргә каршы көрәше кызылармеец образларында чагылдырылды. Идел буендагы ачлык фажигаләре «Адәмнәр» исемле хикәямдә чагылыш тапты.

Кулымда 1910—1911 елларда язган романымның кулъязмасы бар иде. Бу кулъязма Оренбургта һәм Киевтә ике тапкыр жандармерия кулына эләкте. Беренче юлы кулъязмамны бөтенләй кайтарып бирмәделәр, шуннан соң мин аны үземдә сакланып калган караламадан файдаланып яздым. Икенче юлы анын бер өлешен генә кайтардылар. 1923 елда мин, таркау яткан бу кулъязмамны жыеп, «Казакъ кызы» исеме белән бастырып чыгардым (1924, Мәскәү, 138 бит). Бу романда революциягә кадәрге Казагыстан тормышы картиналары, анын ыруг һәм социаль көрәшләре һәм патша империясенең колониаль политикасы бирелгән.

Минем «Тирән тамырлар» исемле соңгы әсәрем 1928 елда басылып чыкты. Бу романда соңгы ун ел эчендәге вакыйгалар, көрәшләр тасвирлана. Аны мин 1926 елда язып бетергән идем, ләкин Кырымга дәваланырга китүем һәм бөтенләй эшкә яраксыз хәлгә килүем сәбәпле кулъязманы тәмам эшләп бетерергә һәм типографиягә бирерлек итеп күчерергә хәлем булмады, шуна күрә китап дөньяга ике елга соңга калып чыкты. Ипташлар тарафыннан мина очраклы рәвештә жибәрелгән өч тәнкыйть мәкаләсен күрсәтеп үтәм: 1) ипташ А. Федотов мәкаләсе («Кызыл Татарстан», Казан, 1929 ел, 24 февраль, якшәмбе); 2) ипташ Касыйм Гыйрфанов мәкаләсе («Белем» журналы, Башкортстан Мәгариф Халык комиссариаты органы, Уфа, 1929 ел, 87—98 битләр); 3) Г. Нигъмәтинен «Революция елларында әдәбият» исемле китабындагы мәкаләсе (Мәскәү, 1929).

Мин инде күптән «Безнең көннәр» трилогиясенен икенче (реакция чоры) һәм өченче (Октябрь революциясе чоры) кисәкләрен әзерли идем. Ләкин каты авыруым эшемне бүлде, әсәремне төгәлләргә мөмкинлек бирмәде. Бу социаль трилогияне тәмамлау эше тулысынча минем сәламәтлянүемә һәм эшкә яраклы хәлгә килүемә бәйләнгән.

IX

АВЫРУЫМ

Туберкулезымның башлануы күптән; аерым билгеләре әледән-әле сизелгәләп тора иде. Ләкин 1927 елның мартында мин, тәмам аяктан егылып, үлем хәлендә яттым: тамагымнан бик күп кан килде, үпкәләремдә аспирацион пневмония һәм нәтиҗәдә каверналар хасыйл булды, бациллаларның саны бер карау мәйданында 60 ка житте, кыскасы, актив формадагы туберкулезның өченче стадиясе.

Казан университеты янындагы иске клиникада бер ай яттым. 1927 елның 21 апрелендә профессор Чебоксаров житәкчелегендәге профессорлар консилиумы тәкъдиме һәм ТАССР Халык Комиссарлары Советының карары белән мине, юлда хатыным Г. Мөхәммәдова һәм врач Уразов карамагында, Кырымга дәваланырга озаттылар; анда курортлар идарәсе консультанты доктор А. В. Дьяконов карамагына тапшырдылар.

Эшкә яраксыз хәлгә килдем. Ун ай буе түшәктән бөтенләй тормадым. 1927 елның декабренда тамагымнан яңадан кан китте, 21 көн дәвам итте. Шуна күрә ун үпкәмә пневмоторакс ясый башладылар (доктор Керцман).

---

[1] (1913)

1928 елның ноябрь — декабрь айларында тамагымда яңа авыру таптылар — тамак туберкулезы. Аны электричество белән яндырып дәваладылар.

Кырым һавасы, медицина тарафыннан билгеләнгән чараларны куллану һәм каты режим белән дәвалану аркасында (режимны ике елдан бирле үтәп киләм) хәзер инде аягыма бастым, бераз йөри башладым, газеталар, җиңел эчтәлекле әдәби әсәрләр укыйм, хатлар язам.

Врачлар экспертизасының Ялта бюросы минем төп авыруымны туберкулезның өченче стадиясе итеп тапты (шуның өстенә яшерен формадагы малярия һәм колит белән авырыйм) һәм мине 1 нче категория инвалид итеп билгеләде.

Мин, беренче категория инвалид буларак, пенсия алам. Татарстан хөкүмәте, пенсиямә өстәмә итеп, дәваланырга тоту өчен ай саен билгеле күләмдә акча җибәреп тора. Минем электә язылган әсәрләремне яңадан басып чыгарган өчен Татарстан Дәүләт нәшрияты һәм «Яңалиф» [нәшрияты] соңгы вакытларда миңа гонорар җибәрделәр.

Барысын бергә җыйганда, бу акчалар миңа Кырымда каты режим белән дәвалануымны дәвам итәргә, барлык техник чаралардан һәм медицина фәненең казанышларыннан файдаланырга мөмкинлек бирә.

Эшкә тәмам яраклы хәлгә килеп, үз вазифаларымны үтәргә кайчан керешермен — хәзергә анысын ачык итеп әйтүе читен. Һәрхәлдә сәламәтлегем әкренләп яхшыра бара (...).

X

РӘСМИ ХАРАКТЕРДАГЫ КАЙБЕР БЕЛДЕРҮЛӘР

(...)

1. Ялтага дәваланырга килгәч, 1927 елның җәендә, мин РСФСР Мәгариф Халык комиссариатының протоколга язылган бер карарын алдым; ул карарда миңа РСФСР Мәгариф Халык комиссариаты тарафыннан, аның исәбенә, чит илгә гыйльми командировка бирелачәге турында әйтелгән иде. Мәгариф комиссариатының чит илләргә гыйльми командировкалар бирүче Комиссиясе, өстәмә рәвештә миңа хат язып, командировка документларымны кайчан алырга теләвем турында хәбәр итүемне сорады (беренче документ № 84464, икенче документ № 59940). Ләкин, кызганычка каршы, каты авырып китеп, урын өстендә ятуым сәбәпле РСФСР Мәгариф Халык комиссариатының бу командировкасын файдалана алмадым.

2. Художество Фәннәре [Дәүләт] Академиясенә член булып сайлануым турында 1928 елның 25 январенда Мәскәүдән, Художество Фәннәре [Дәүләт] Академиясенең Гыйльми секретареннан 108 нче номерлы хәбәр алдым.

3. Казанда Татарстан Педагогия җәмгыяте мине үзенең почетный члены итеп сайлаган. Шул турыда 1928 елның 8 апрелендә почта белән хәбәр һәм 128 нче номерлы членлык билетын алдым.

4. Татарстанны өйрәнү Гыйльми Җәмгыятенең председателе профессор Н. Н. Фирсов, миңа рәсми хат җибәреп, Җәмгыятьнең гомуми җыелышында мине Татарстанны өйрәнү Гыйльми Җәмгыятенә почетный член итеп сайлаулары турында хәбәр итте. Член булып сайлануым турында рус телендә «Вестник Научного Общества Татароведения»нең 8 нче санында басылган.

5. Казагыстанның Кызыл Орда шәһәреннән дә шундый ук эчтәлекле телеграмма алдым.

6. 1927 елның[1] 10 мартында Татарстанда, партия-совет органнары җитәкчелегендә, шулай ук СССРның төрек-татар халыклары яши торган башка шәһәрләрендә, Көнчыгышны өйрәнү белән шөгыльләнүче күп кенә гыйльми учреждениеләрдә әдәби-иҗтимагый эшчәнлегемнең егерме еллыгы үткәрелде. Бу турыда матбугатта, рус һәм төрек-татар халыклары телләрендә махсус чыгарылган җыентыкларда, шулай ук газета һәм журнал битләрендә бик күп материал бар (...).

7. Татоблпрос һәм Татпрофсовет тәкъдиме белән 1928 елның 13 июлендә ВЦСПС

[1] 1928 елның.

Президиумы тарафыннан Хезмәт Герое исеме бирелү турында СССР мәгариф эшчеләре профсоюзларының Өлкә Идарәсе мина 1928 елның 27 августында № 36 (419) 163 ле хат белән Казаннан рәсми рәвештә хәбәр итте.

Август ахырында мин Татпрофсовет аркылы Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының 1928 елның 13 августындагы утырышының № 70 ле протоколыннан күчермә алдым. Күчермәнең № 56 белән күрсәтелгән пунктында түбәндәгечә әйтелгән: «Художество Фәннәре Дәүләт Академиясе члены иптәш Г. Г. Ибраһимовка Хезмәт Герое исеме бирергә».

Бу карар «Известия» газетасында (Бөтенроссия һәм СССР Үзәк Башкарма Комитетлары органы, 1928 ел, 16 август, № 189) рәсми рәвештә игълан ителде һәм аны «Красная Татария» газетасы күчереп басты (Казан, 1928 ел, 16 август, № 189 (3162).

1929 ел.

КПССның Татарстан Өлкә Комитеты партия архивы, 1378 нче фонд, 1987 нче эш, 110 нчы бәйләм, 99—135 битләр.

...Дөньяның кин форсатлы мөхәррирләре — зурлары, кечеләре үзләренең эшләү характерлары турында күп-күп язганнар, язалар. Мин бу хакта монарчы да яза алмадым. Әле дә авырулыгымнан бер бөтен нәрсә язарга хәлемнән килми. Без бит көрәш — иҗтимагый-әдәби көрәш эчендә гомерне үткәрдек. Шуна күрә элек вакытыбыз булмады. Хәзер, авырып егылгач, инде күп, ләкин хәл юк, кулда, тәндә куәт юк.

Монарчы минем турыда байтак-байтак яздылар. Рус, татар, башка телләрдә күп кенә нәрсә чыкты. Күбе үземдә барлар. Боларны сәламәт вакытта актаргалый идем. Җыенысыннан сыгып алганда, арада дөресрәк фикерләре, карашлары, менә шуна кайта иде.

Мин — реалист мөхәррир. Беренче әсәремнән хәзергәчә шул мәсләктә бардым. Арада кайбер әсәрләремдә романтизм элементларының бераз куера төшкән урыннары булгалады (реакция чорында), ләкин боларда да төп мөндәриҗә — нигез реализм иде. Беренче әсәрләремнән хәзергәчә мөндәриҗәләрдә төп характерлар һаман-һаман көрәш вакыйгалары, халыкның хезмәт процесслары тирәсендә, шулар белән сугарылды. Хезмәт — авылда, шәһәрдә төрлечә тасвирга алынган кебек, көрәш тә үзенең тәфсилен үзгәртте генә түгел, бәлки нык тирәнәйтте дә.

Беренче әсәр — «Зәки шәкерт»тә яна фикер реакциягә каршы көрәшсә, «Татар хатыны ниләр күрми»дә хатын коллыкка каршы көрәшсә, бара торгач, бу инде иҗтимагый каршылык, иҗтимагый көрәшләргә әйләнә.

Мина бу турыда Киев хәрәкәте, Киев зинданы байтак тәэсир кыйлды. Аннан соңгы «Көтүчеләр», «Мәрхүмнең дәфтәреннән», 1914 елда язылып тәмам булган һәм [1920 елда] үзгәртми басылган «Безнең көннәр» менә шуна мисал булыр.

Революциягәчә мин ул заманның хәрәкәтенә оппозициядә бардым. Февраль дәвере буржуага каршы тел, каләм көрәше белән үтте. Анда яза алмадым. 1918 елның башыннан Петербургта (Ленинградта) Комиссариаттан башлап тагын Октябрь һәм Совет өчен көрәш белән үтеп, әдәбиятка форсат тимәде. Бөтен үткән хәятым, яшьтән каты эшләп, бөтен 10—15 ел уку һәм яшь язучы заманнарын ачлык, ялангач һәм көрәш белән үткәрүләр мине мәҗбүри рәвештә коммунист-активист булырга әзерләп китерделәр. Минем марксист әдип булуым, пролетариат байрагы астында эшләвемне үземә тормышымның, гомеремнең төп максаты итеп куеп, шул юлны алуым бөтен үткән хәятымның тарихи мәҗбүри нәтиҗәседер.

Әгәр гомер булып та, бу үткән хәятны бер кин рәвештә яза алсам иде, хәзерге яшьләр өчен үткән безнең буынның нинди кыен, мөшкил шартлар, киртәләр, көрәшләр сөцында киңәеп, пролетариат байрагы астында көрәшергә, шунда эшләргә, каләмне, әдәбиятны шуна корал итәргә насыйп булганнарын күрерләр иде...

Ләкин эшләнгәннәрдән эшләнәчәкләрем, яртылай эшләнеп яки аклауны көтеп, дөньяга чыгуны көтеп яткаларым — миннән гомер, сәламәтлек көтеп яталар. Ни булыр — боларга кайтып, яңадан каләмгә утырыр көн килерме, әллә кабер алырмы?

Г. Толымбайскийга язган хатыннан. «Кызыл Татарстан» газетасы, 1927 ел, 4 декабрь, № 278.

...Дөнья шулайрак булып китте бит: мин, көн-төн туктамыйча, авыруның нәрсә икәнен белмичә, дәртләнеп эшләп йөргән чакта, кинәтрәк аяктан егылдым да, бөтен эшләремне ташлап, үлем белән көрәшү мәҗбүрияте астында калдым. Бу минем өчен көтелмәгәнрәк хәл булды.

Бәлки, газеталарда күргәнсеңдер, 26 нчы елның сентябрендә, кич, кабинетымда эшләп утырганда, бик аз ютәл соңында күкрәгемнән кан китте (стакан ярым чамасы). Докторлар киңәшенчә, Кавказга — Сухомга киттем. Анда өч айга якын торып кайткач, Казанда яңадан әүвәлгечә иркенлек белән эшкә тотындым. Мәсьәләләр шулай тыгыз килде ки, мина иртәдән сәгать 4 [кә] кадәрле Гыйльми үзәктә, совет аппаратында эшләү өстенә, ике ай ярым эчендә «Урал» һәм уралчылар» белән «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» атлы ике зур мәсьүлиятле әсәр язып чыгарырга туры килде.

Бәлки, шулар нәтиҗәседер инде, март 17 дә, көндез, Татарстанның Советлар съездында утырган чакта, тагын бераз гына ютәл артыннан күкрәктән кан китте. Ике тәүлек эчендә өч мәртәбә күпләп килгән канның микъдары алты стаканнан артып китте. Нәтиҗәсендә, үпкәне кан басудан аспирационная пневмония булып, минем хәл үлем чигенә килеп җитте. Эсселек 40 тан артып китте. Мин бөтен бер ай Казан университетының иске клиникасында яттым. Беренче көннән үк йөрү, сөйләшү бөтенләй мөмкин булмады. Үлем куркынычы әүвәлге атналарда бөтенләй килеп баскан иде.

Докторларның гадәттән тыш зур әһәмият белән карауларының да бер тәэсире булгандыр, мин тәндә жан сүнмәгән хәлдә, апрель 21 ндә Татнаркомздравның мине озатырга, юлдаш булырга дип биргән докторы һәм үземнең гаиләм белән берлектә, Кырымга киттем. Дөресе — мине күтәреп алып төшеп, поездга күтәреп кертеп, Кырымга алып киттеләр. Әлбәттә, куркыныч зур иде. Кырым шикелле ерак җиргә минем хәлемдә барып җитә алуның бик мөшкиллеге күз алдында иде, шулай булса да, Казанда калу минем үпкәләрем өчен һичбер төрле ярамаганга, ике куркынычның өметкә якынрагын сайладым. Ни булса — шул дип, Кырым сәфәренә тәвәккәл иттем. Монда килгәндә һәм килгәч, хәлем, рентгеннар аша карап, түбәндәге рәвештә табылды: өченче стадия туберкулез, уң үпкәдә ике каверна (тишек). Боларның берсе тавык йомыркасы зурлыгы, берсе кечерәк. Тәндә бер потка якын үлчәү житми — ягъни тик сөяк белән тире калган. Үзем теләгәнчә сөйләшә алмыйм, кроватьтан кузгалырга һич төрле ярамый, бөтен эшем тик шунда үтәлә. Болар өстенә малярия белән колит бар, кыскача, хәл менә шулай иде. Әгәр бервакыт мин, терелеп, яңадан хәятка кайта алсам, эшкә тотына алсам, син уйларга тиеш булырсың: — Галимҗанның организмысы үткән күп җәфалы тормыш аркасында бик чыныккан икән, дип.

Ләкин хәзергә ачык бер әйбер әйтеп булмый әле: үлем жиңәрме, минме?..

...Менә — минем хәл шулай бара. Үлемгә каршы бу көрәш байтак дәвам итәр әле. Докторлар әйтәләр: озак вакыт тынычлык белән, тыныч күнел белән нык дәваланганда, шөбһәсез, яңадан тазарырга, һич булмаса, әдәби-гыйльми эшкә кайтырга мөмкин булачак, диләр. Үзем, менә шул өметләр белән юанып, үлемгә каршы озак, кискен көрәш алып барырга планнар корып ятам.

Һич булмаса, күнелдә эшләнеп беткән, кайбере яртылай кәгазьгә төшкән, яки аклауны гына көтеп яткан әсәрләремне бетерә алырлык куәт кайтсын иде, шул чаклы гына гомер мина яңадан килсен иде. «Безнең көннәр»нең II нче, III нчеләре, «Тугры сүз»[1] әдәби хикәясе, «Татарлар арасында революция хәрәкәтләренең октябрь жилде» һәм «Әдәбият кануннары» кебек гыйльми нәрсәләрем ашыгып, мине үзләрен тизрәк эшләп бетерергә чакырып, папкаларда яталар бит. Әгәр кабер бик якын килгән булмаса, бер өмет бар — бәлки, шундый әйберләремне тәмам итәрлек куәт-гомер яңадан кайтыр әле. Әгәр кайтмаса, угылым Рөстәм тәмам итәр бәлки, дип юанудан башка чара калмый...

М. Гафурига язган хатыннан. 1928 ел, 18 январь, Ялта.

...Быел язга таба борчуларым байтак арта төште. Каты түзем, каты чыдам белән барам. Менә бәла бит. Кешеләр бер төрле үпкә туберкулезы белән генә еллар буенча авырыйлар. Миндә үпкәгә тамак, уң кабырга ягыннан тышкы эренле шешләр чыгып (эчке выкачивание эзләреннән) жәзалыйлар. Бары бергә жыелгач, күпкә китә. Шулай

[1] «Тирән тамырлар» романы.

да сер бирми, һәммәсенә каршы сугышам. Авыр, җәфалы, җәзалы, газаплы килә, шулай да сугышам. Бу катлаулы җәфа шул чиккә житкергән чаклары була ки, әгәр миндә бу дүрт катлаулы авыру урынына тик өченче стадия үпкә туберкулезы гына булса, мин дөньяда иң бәхетле кеше булыр идем дип уйлап куям...

Кави Нәҗмигә язган хатыннан. 1930 ел, 27 май, Ялта.

...Инде акрынлап эшләп тә куйгалыйм. Беләсең, күп еллар буенча «Безнең көннәр» трилогиясе минем алдымда тора. Аның берсе генә чыкты, инде хәзер нәүбәт калган ике томга житте. Шулар өстенә акрынлап эшләштерәм, болардан башка «Ялчылар», «Корбан», «Яз килә»[1] дигән кебек берничә кечерәк хикәяләрем бар. Шуларны да кузгатып куйгалыйм. Гомумән, Ялта мине үлемнән алып калды. Мәскәү, Казан совет хөкүмәтләренең туктаусыз ярдәм һәм пенсияләре — бу озак дәвалана алу эшендә мина нигез шарт булдылар. Соңгы заманда көтелмәгән бер рәвештә Үзбәкстанның да яхшы катнашы булды. Нәтиҗәдә мин инде, аякка басып, баш очымдагы үлемне күз алдымнан бераз куа алдым. Бу хәлгә килүемә үзем бик шатмын. 50—60 процентка эш көчем кайтачак, элекке кебек тәүлегенә 15—20 сәгать эшләп булмас булуын, шулай да материалы жыелган, планы, фикере төзелгән байтак гыйльми-әдәби нәрсәләрне эшли алырга хәлем житәр дип өмет итәм. Шул өмет өчен яшим, шуның өчен үлемгә каршы сугышам.

Мохтар Ибраһимовка язган хатыннан. 1932 ел, 5 октябрь, Ялта.

...Укучылар белән язучы арасында бәйләнеш ничаклы нык барса, һәр ике як өчен шул чаклы файдалы булачак. Шуна дүрә хатыгыз өчен рәхмәттән башка сүзем юк. Ләкин сез минем турыда зур сүзләр әйтәсез, минем аз, кечкенә хезмәтемне бик артык югары күтәрәсез. Белегез, иптәшләр, мин партиянең әдәби фронтында, кулдан килгәнчә, көч житкәнчә тырышып, эш-көрәш алып барган бер хезмәтчесемен. Партиянең әдәби хезмәтчесе дигән сүзне мин — үз совет илебездә дә, бөтен жир йөзендә дә капитализмга каршы социализм өчен, Маркс — Ленин байрагы астында эшләп баручысы дигән мәгънәдә аңлыйм. Сез әдәби сәнгать дисез, әдәби техника дисез, мин боларның һәммәсенә капитал коллыгында изелгән дөньяның хезмәт массасының азатлыгы өчен пролетариат диктатурасы аша коммунизмга бару өчен көрәш фронтының бер коралы, аерымрак бер коралы дип карыйм. Шунлыктан Г[алимжан] И[брагимов] дип, әдип дип зурлаулар — минем хәзерге психологиям өчен ничектер бераз ятрак нәрсәләр кебек булып тоелалар...

... Әсәрләрдә партиянең житәкчелек ролен ничек чагылдыру турында сүзне кирәк жирдән алгансыз. Совет әдәби хәрәкәтен караганда бу момент, әлбәттә, беренче урында торырга тиеш. Ләкин татарлар да, башкортлар, руслар, башка язучылар да бу зур бурычны тиешенчә үти алганыбыз юк шул әле. Тәжрибәләр булды, уңышлы чыкканы күп түгел. Русчадан Исбах («Крушение»), Горбатов («Наш город») кебекләр бөтенләй начар, уңышсыз чыкты. Либединский да канәгатьләнерлек ача алмады. Олы ата Серафимовичның «Железный поток» кебек кыйммәтле әсәрләрендә дә бу момент бөтенләй аз. Панферовның «Бруски», Шолоховның «Тихий Дон» кебек кадерле, зур, яхшы совет романнары да партиянең житәкчелеген укучыга ачуда тулы нәтиҗә бирә алудан ерак торалар. Бу юлда аеруча уңышлы әсәрләрдән берсе, бәлки, беренчесе Фадеевның «Разгром» атлы китабы булды. Ләкин бу мөхәррир дә икенче романы «Последний из Удеге» исемле әсәрендә партиянең авангардлык моменты тасвирда нык аксый. Гомумән пролетариат революциясе көрәшләрендә партиябезнең юлбашчылык роле, партия сешмаларының эчке тормышлары, зур кыенлыкларга каршы жиңү моментлары кебек зур жаваплы тема әле бездә тиешенчә югары дәрәҗәдә бөтен тулылыгы белән тасвир кылынып бирелә жителә алган әсәрләр бик-бик азлар. Бу момент коммунист язучылар алдында, әлбәттә, төп нигез, зур бурычларның алдынгысы булып тора. Мин үзем бу турыда күп уйлыйм, күп материал жыям, алдынгы темаларның берсе итеп ижат механизмысы үзәгенә утыртканым. Унбиш ел буенча мина пролетариат революциясе фронтларында өзлексез кайнарга туры килгәнгә, Бөек Октябрьның беренче елларында

[1] Бу хикәяләрне әдип үзе исән чакта матбугатка бирмәде. Кулъязмаларының әлегә табылганы юк.

революциянен Ленинград, Мәскәү кебек үзәкләрендә, Советның үзәк органнарында, партия совет житәкчелегенен якын эш системаларында катнашып эшләп үткән бер мөхәррир-коммунист булганга, аннан 1921—1926 елларда Казан, Татарстан активы эчендә хезмәт итеп килгәнгә, бу мәсьәләләргә багланышлы бик кыйммәтле материаллар, вакыйгалар дөньяга чыгарга сорап йөриләр. Болар өчен әзерлек бара. Ләкин болар алдагы көн, киләчәк көн эшләре. Әмма үткән әсәрләрдә бу момент күнелем канәгатьләнә алырлык чагыла алмады. Ләкин бөтенләй юк түгел. Мәсәлән, «Тирән тамырлар»да партия әгъзаларының көрәшләре, партия конференцияләре кебек моментлар бирелде. Шулай да мин үзем болар белән канәгатьләнүдән ерак, күнел тулганчы үтәү алдагы эш планында тора. Мин моны үземә караган дип кенә түгел, бөтен СССРда төрле телләрдә яза торган коммунист язучыларның уртак бурычлары итеп карыйм. Үзем шул зур коллектив эчендә бер хезмәтче булып эшләүне күз алдымда тотам. Өмет шунда...

Башкортстан Педагогия институтында укучы Афзал Кудаш, Ж. Локманов, З. Зөбәерова иптәшләргә язган хатыннан. 1932 ел, декабрь, Ялта.

* * *

Галимҗан Ибраһимов, каты авыру булуына карамастан, «материалы жыелган, планы, фикере төзелгән байтак гыйльми-әдәби» әсәрләр ижат итеп, аларны халыкка бирү өмете белән яши һәм шул өметне тормышка ашыру өчен дәһшәтле авыру белән көрәшә, үлемгә каршы сугыша. Бераз сәламәтлеге рәтләнгән кебек булып, кулына каләм тота алырлык хәлгә килү белән үк, әдәби ижат эшенә керешә, яза. Элек басылган, аерым китап булып чыккан, ләкин әдәби эшләнеше, идея эчтәлеге белән үзен канәгатьләндермәгән «Татар хатыны ниләр күрми» хикәясен һәм «Безнең көннәр» романын яңа баштан карап, төзәтеп, бөтенләй икенче редакциядә матбугатка бирә. Бу әсәрләрнең беренчесе 1929 елда, икенчесе 1934 елда Казанда басыла.

Шуннан соң әдип озак еллар уйлап, хыялланып йөргән, күнеленә тынычлык бирмәгән, кәгазь өстенә төшерелүне таләп иткән яңа әсәрләр, яңа образлар өстендә эшләргә тотына, сәламәтлеге мөмкинлек биргән һәр сәгатьтән, һәр минуттан файдалана. 1937 ел урталарында ул, «Солдаттан кайткач» исемле артык зур булмаган хикәясен тәмамлап, Татарстан китап нәшриятына жибәрә һәм аны Бөек Октябрь революциясенең егерме еллыгына багышланып чыгачак әдәби альманахка кертүне үтенә. Шул ук хатында ул «Безнең көннәр» романының икенче кисәген язып бетерүен һәм аны, машинкада күчертеп, ел азагында нәшриятка жибәрергә вәгъдә итә. Ләкин, кызганычка каршы, бу ике әсәрнең икесе дә дөнья йөзен күрә алмый калды. Галимҗан Ибраһимовның гомер юлы шәхес культы хөкем сөргән чорда, хаксыз гаепләүләр нәтиҗәсендә, 1938 елның 21 январенда төрмә больницасында өзелде.

Ул вафат булганнан соң, больницадагы авыруларның берсе аның палатасына керә һәм тумбочка тактасына калтыраган хәлсез кул белән язылган түбәндәге сүзләрне укый: «Партия каршында, халык каршында һичбер гаебем юк. Хакыйкать ачылыр, тарих үз сүзен әйтер. Галимҗан Ибраһимов».

Хакыйкать ачылды, тарих чыннан да үз сүзен әйтте. Озак еллар буенча көтелгән, халык күнелендә йөргән бу гадел сүзне бөек Ленин партиясенең XX съезды әйтте. Ватаныбызның нахакка гаепләнгән исемнәре вакытлыча сызылып торган намуслы, тугрылыклы улларының йөзләрен, эшләрен аклады. Шулар жөмләсеннән татар әдәбияты классигы, зур галим, жәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның да исеме акланды, ижаты халыкка кайтарылды. Хәзер аның әсәрләре меңнәрчә тираж белән басыла, миллионнар тарафыннан яратылып укыла, тугандаш халыклар телләренә тәрҗемә ителә, анда яңадан-яңа укучыларын таба. Гәрчә Галимҗан Ибраһимов тумышы белән татар булса да, үзенең әдәби жәүһәрләрен Татарстан жирлегендә ижат итсә дә, алар аны үз язучылары итеп саныйлар, ихтирам итәләр. Чөнки ул күп милләтле гомуми совет әдәбиятының зур вәкиле, кабатланмас таланты, художнигы.

Коммунист язучы Галимҗан Ибраһимов үзенең бөтен тормышын соңгы сулышына кадәр халык эшенә, бөек Ленин партиясе эшенә бирде, Ватаныбызның даны, тантанасы өчен көрәште, ижат итте.

Нури Арсланов

Моңсар

(Җыр турында легенда)

«Әй, халык, мәйданга бар!
Җыр алып кайткан Моңсар.
Ул кичкән илләр аша.
Бездә бүген тамаша!»

Шау-гөр килде зур базар,
Мәйданга чыкты Моңсар.

Бу ни?! Кинәт шул чакта,
Юл ярып ике якка,
Чабып килделәр атта....
Кубызын тартып алдылар,
Җырчыга боргау салдылар,
Кылычлар таккан ирләр:
— Ханнан килдек, — диделәр.

Гөж итеп алды халык.
Моңсар әйтте уйланып:
— Киек-җанвар беткәнме,
Нигә кеше аулыйсыз?
Гадел тормыш иткәнне
Нигә ханга каулыйсыз?
Явызлык кылмышым юк,
Ханда бер йомышым юк.
Минем юлым — далада,
Авылларда, калада:
Халык кайда — мин анда,
Кирәк түгел мин ханга!
Кубызым биреп кулыма,
Җибәрегез юлыма...

Сүзен сүзгә санамый,
Ай-ваена карамый,
Колак салмый Моңсарга,
Алып кайттылар ханга.

— Ә-ә-ә, синме ул җыручы,
Мине хурлап йөрүче?
Асарга иде сине.
Уемнан кайттым кире:
Шәфкатемне бел минем,
Күп яманлаган идең,
Инде, үзеңне аклап,
Җырла ханыңны мактап!

Чапан булыр иңеңдә
Олы җанлы ханыңнан,
Җырны тарат илемә —
Өлеш тияр малымнан.

Моңсар берни дәшмәде,
Богаудан азат булды да,
Кубызын алды кулына,
Аннан җырлый башлады:
— Батыр көчен көрәштә
Сынар өчен яралган,
Ярлы, толлар, үксезләр
Елар өчен яралган...
Ханнар, биләр халыкны
Буар өчен яралган.
Минем кебек акыннар
Җырлар өчен яралган.

Хан күтәрсә — би була,
Ил күтәрсә — ир була.
Бинең гомере — өч көнлек,
Ирнең даны — гомерлек!

Ат — атмыни, юл кичеп,
Тоягын ташка ормаса?!
Җил — җилмени, нык исеп,
Болытларны кумаса?!
Ир — ирмени, ил яклап,
Явызга каршы тормаса?!
Җыр — җырмыни, хан мактап,
Сарай мактап җырласа?!

Тәхет биек, таҗ биек;
Тик җыр килмәс баш иеп,
Тотам дисәң — ул киек,
Аны җитәр толпар юк.
Ана җирдә тоткар юк.
Ул — йөрәктән аткан ук:
Ул тисә кан чыгармый,
Ләкин аның ярасы
Мәңгелеккә каласы —
Ханның җаны чыдармы?!

Үлән үсмәс кыр булмый,
Диңгез җилдә тын булмый,
Ялагай сүзе чын булмый,
Ясалма җыр — җыр булмый.
Чын җыр ил белән бергә
Яши гомер-гомергә.
Җыр кәефкә корылмый,
Җырның ертыгы булмый.
Бер кабынса — җыр сүнми,
Җырчы үлә, җыр үлми!

Бик теләсән, Карунхан,
Сина җырлап карыйм, хан.

Җаның — таш, кулларың кан!
Яман синең хәлләрең:
Көтү-көтү малларың,
Алтын тажың, тәхетең,
Кәеф-сафа рәхәтең...
Бары да димсең синеке?
Синеке түгел, илнеке!

Хан түзмәде, кычкырды:
— Туктатыгыз җырчыны!

— Ашыкма, — диде Моңсар, —
Синең кулыңда көч бар!
Тик ул файда итәрме,
Җырга көчең җитәрме?
Бүген җыр монда кердe,
Синең кәефне кырды.
Э иртәгә — далада,
Авылларда, калада...
Ул гизеп китәр илне.
Я, тотып кара җилне!
Җыр туган син туганчы,
Җыр яшәр сиң үлгәч тә.
Җыр — өндәүче, җыр — ярчы:
Тәне гүргә кергәч тә
Телгә алыр яманны,
Телгә алыр яхшыны...
Җыр — хакиме шаһларның,
Бик белеп тор, хан, шуны!

Хан карады җәлләткә,
Җәлләт карады ханга.
Биләр, вәзирләр хәтта
Шаккаттылар Моңсарга.

Хан кинәт сикереп торды:
— Балтага! — дип кычкырды.

— Чыдамадың, хан, тордың,
Баш кисәргә боердың.
Җыр агачы тармаклы:
Һәр тармагы үзенчә.
Бер ботагын чапканнан
Ул корырмы сезнеңчә?
Җыр агачы биек ул,
Башы аның болытта,
Ана буе житалмый
Бәндәнең хан булып та.
Җыр агачы сөнгедәй —
Очын күккә ашырган,
Хан очына караса —
Тажы төшәр башыннан!
Масайма син көченә,
Кисеп булмый җыр башын!
Һәр җирдә, һәр кешедә
Җыр таба үз юлдашын.

Мин онытқан җырлар да
Яши халық исендә,
«Җыр бетсен!» дисәң — кирәк
Халық башын кисәргә!
Ә халық ул — үлемсез!
Юк сөйләп ни файда бар?!
Халкы юкның — иле юк,
Халыксыз хан кайда бар?

Башыма таж кидем, дип,
Җырдан да зур күренмә,
Йолдыз биек — үрелмә!
Бүген синең түрендә
Җыр кунакмы? — Яңгырасын!
Син таянма үлемгә,
Калдырып тор бүгенгә
Газраилен, алласын...
Тыңла җырын Моңсарның —
Тыңла халык моң-зарын.

Җырны чабар балта юк
Бөтен дөнья йөзендә.
Хакыйкать бар, хата юк
Минем шушы сүземдә.
Җырның кисәр тәне юк —
Үлемдә бер гаме юк,
Җыр яши җанга кереп,
Җыр үлемсез, мәңгелек!

Җыр минем милкем түгел,
Җырламый иркем түгел.
Җыр ил жанында туа,
Аннан кылларга куна:
Чыңлый-чыңлый тарала,
Моннан җырлар ярала,
Күчә телдән-телләргә,
Үтә килер көннәргә.
Карамый ул ханнарга,
Түрәләргә, байларга,
Дөресне ярып сала,
Тел тидермә син ана!
Җыр азык ул кешегә.
Килсәк минем эшемә:
Мин чиртәм кыллар гына,
Мин — җырчы Моңсар гына.

«Җыр — йөрәктән аткан ук,
Кансыз, — дидек, — ярасы».
Гадел хөкем ит җырга, —
Кансыз булсын җәзасы.
Гаеп шушы кубызда!
Әйдә, хан, әмереңә бозма,
Рәхим итеп суй, менә,
Тапшырам җәлләтеңә.

Шулай диеп җәлләткә
Моңсар кубызны сузды.

Э тышта бу сәгатьтә
Халык нәфрәте кызды.
Моңсарны — моң-зарчысын
Якларга килгән халык,
Үлемнән үз җырчысын
Сакларга килгән халык.

Пышылдаштылар биләр,
Каушап калды вәзирләр...
Җәлләт карады ханга,
Хан карады диванга:

Диван әһле — тарханнар
Аптырашта калганнар...
Хан берни эшли алмый —
Халык Моңсарны даулый!..

Әйтте хан җәлләтенә:
— Чап башын шул явызның!
Көттермәде теге дә —
Чапты башын... кубызның.
Өзелгәндә кыллары
Ул тагын бер чыңлады...

Диван киң сулыш алды:
Җибәрделәр Моңсарны.
Шатланып ул чыгуга
Халык гөж килде шунда,
Күтәреп алды җырны,
Җырлаган өчен чынны.

Ак чапан кидерделәр,
Яңа кубыз бирделәр:
— Уйна, Моңсар! — диделәр, —
Җырсыз — җирнең яме юк,
Җырсыз — тормыш тәме юк,
Җыр — сулар һава кебек,
Җыр яшә, җыр — мәңгелек!

1966

Ибраһим Газига 60 яшь

ЮК, ТУРГАЙ КАРТАЙМЫЙ...

Юбилей кичәсенең президиум өстәле артында утырган Ибраһим ага Газины күргәнебез юк безнең. Ихтимал, күргә насыйп та булмас. Чөнки теләме: кирәге юк һәм вәссәламе. Хикмәт тыйнаклыкта гына түгел, әлбәттә. Тантана вакытында трибунадан яисә адреслар папкасыннан ишетелүе мөмкин булган арттырулар, күпшы сүзләр курыта булса кирәк аны.

Талантлы зур художникның 35—40 еллык фидакарь хезмәтенә тәкъдир йөзеннән генә түгел, бәлки язучылар һәм укучыларның уртак бәйрәме итеп, И. Газины президиум өстәле артына утырырга күндерү начар булмас иде, югыйсә...

Нишлисең, рөхсәт-мазар сорап тормыйча, шушы бәләкәй мәкаләне генә язарга кала. Чын күңелдән әйтелгән сүзләргә, ихтимал, язучы үзе дә йөз чытмас, меңләгән укучыларының фикер-тойгыларын да азмы-күпме чагылдырып булыр.

Мәгълүм булганча, чын язучының иҗаты аның шәхесеннән аерылмый. Ибраһим Гази әсәрләренә табигыйлек, дөреслек һәм аяусыз реализм хас икән, бу аның ясалмалыкны, һәртөрле фальшьны сөймәвенә, һичшиксез, турыдан-туры бәйләнгән.

Реализм дибез, дөреслек дибез. Моның өчен иң элек тормышны бөтен вакыклары, ыбыр-чыбырлары, бөтен нечкәлекләре белән белү кирәк, әлбәттә. Ә инде бу мәсьәләдә И. Газиның тиңдәше юк дисәм дә, хата булмас. Хәтерем алдамаса, берваклыт күренекле язучылар, сүз арасында, кошлар дөньясына кагылышлы бик четерекле бер мәсьәләгә килеп төртелделәр. Шунда кемдер әйтә куйды: «Белсә, Ибрай гына белә инде аны»...

Әмма реализм тормышта ни күрдең, шуны тәфсилләп язу түгел әле. Әгәр художник бер этнең төгәл рәсемен эшләсә, дөньяга тагын бер эт кенә артыр иде, дигән бөек Гете. Реализм булсын дисәң, тормышның эчке мәгънәсен тотып аласы бар, әлеге ыбыр-чыбырларны аралап, характерлысын эләктерәсе бар. Моның өчен исә философ күзе, философ акылы кирәк. Бу очракта да И. Гази яр өстендә нык утыра. Философиянең аерата катлаулы мәсьәләләре турында сүз кузгалганда да еш кына шул сүзләрне ишетергә мөмкин: «Белсә, Ибрай гына белә инде». Әйтелгәннәргә И. Газиның граждан лык омтылышын, туган халкына мәхәббәтен һәм чын мәгънәсендәге партиялелеген дә өстәсәк, аның уңышка ирешү сере нидә икәнлеген аңларбыз.

Язучының иҗаты турында уйланырга тотындыңмы, аның йөзләгән геройлары, «менә мин, оныта күрмә» дигәндәй, күз алдыннан үтә башлыйлар.

Онытып буламени сине, лейтенант Сөләйманов?! Язучы агаң сине авызыннан ут чәчә торган начальник, күрку белмәс командир һәм таш бәгырьле солдат итеп күрсәткән булса, ихтимал, сик инде күптән югалыр идең.

Менә бит ул, җаваплы операциягә китәр алдыннан алга куелган заданиене нечкәләп уйларга тырышып карый да: «әй, баргач күз күрер әле, барыбер син дигәнчә булмый ул», дип кул гына селти. Яисә дошман борыны төбендә, автомат тотып, япа-ялгыз басып торганда, кое өсте ачык калып, улым төшеп китмәгәе дип, күңеле белән авылдагы гаиләсенә кайтып килә. Ә бит аның солдат кыяфәтендәге тыныч хезмәт кешесе булып калуында, бер тамчы суда кояш балкыгандай, шул вакытның олы хакыйкате чагылган иде.

Яисә менә Хәлим, Якуп, Шәрифҗан, Берьярым Миңнулла, Мәгъсүмә, Федюшкин һәм тагын бик күпләр... Буйга артып китеп, аркылыга җитми калган Миңнулланы — революция юлына үз сукмагыннан үзенең мәзәк адым-хәрәкәтләре белән килеп кергән крестьянны — ничек онытырга мөмкин! Изге көрәшкә күтәрелгән бу агай, алпавыт атларын бүтән атсызлар белән бүлешергә теләмичә, үзендә калдырырга тырышып, кендек күтәрмәгән булса, бәлки, бу чаклы җанлы булып күз алдына басмаган булыр иде. Без моны нәкъ менә психологик һәм тарихи дөреслек дип атыйбыз. Һәм гомумән, «Онытылмас елларның романының гәҗәп тере геройлары, революциянең олы хакыйкатен җиткерү белән бергә, аның татар халкы тормышындагы үзенчәлекле бизәк һәм оттеноклярын да күрсәтеп бирәләр.

Соң И. Газиның язучы буларак үзенчәлеге нидән гыйбарәт? Аек реализм, нечкә юмор һәм сүзгә саранлык, дип җавап бирер идек, ләкин бу сүзләр генә ул үзенчәлекне ин.ләп бетерә алмый. Өстәвенә художник күңелендә моңарчы тик торган берәр кылның чыңлап куеп, без биргән билгеләмәне җимереп ташлавы да мөмкин бит әле. «Тургай картая микән?» исемле хикәясе нәкъ менә шундый кылның чыңлавы түгелме? Хәер, аны хикәя дип булмый, чәчмә белән язылган шигырь ул.

Тургай, әлбәттә, картая да, үлә дә. Ләкин ул — бигрәк тә аның җыры — мәңге картаймый, мәңге күңелләрне кытыклап, хезмәткә дәртләндерә кебек тоела. Миңнулла һәм Якупларның, Мәгъсүмә һәм Хәлимнәрнең меңләгән прототиплары да туып.үсканнәр һәм, гомер итеп, юкка чыкканнар. Тагын да туарлар, тагын да үләрләр... Әмма аларның китаптагы җанлы сурәтләре, тургай җыры кебек, бик озак яшәр, бик озак яңгырап торыр.

Әнә шул җырны яңгыраткан Ибраһим ага Газига озын гомер телибез!

И. НУРУЛЛИН.

Ибраһим Гази

МАЛАЙЛЫКТА КУНАКТА

...Саламнан тәртә каерып,
Чикерткә жиккән чаклар...

Мин әкрен генә авыл урамыннан барам. Бу минем туган авылым — Карамал. Исәнме, Карамал, исән генә тордыңмы! Исәнмесез, кәжәле, казлы, бозаулы урамнар! Сөяккә эләгеп торасы килмәгән ыштанны күтәрә-күтәрә кайчандыр мин чабып йөргән урамнар, исәнмесез! Исәнмесез, тау башлары, иген кырлары! Кайда соң сез, яшьлегемнең күңелле иптәшләре, жил тегермәннәре? Тау башында никтер мин сезне күрмим? Сез инде юк... Сез череп ауган? Сезне тотып утынга якканнар? Шулайдыр. Колхоз хәзер оны электр белән тарттыра шул инде.

Әйе, мин малай чактагы тормышны тотып яктылар. Мин үзем дә кисәү белән болгатып тордым... Минем заманның кешеләре авылда инде бик сирәк. Кайда син, Хәмидулла абзый? Зәкәрия абзый? Минем күршем, Җәлил агай, син дә күптән юк инде. Мине күлдә батып барган жирдән тартып чыгаручы адашым, Галәү абзый Ибраһимы, сине дә күптән күрмим мин. Кайда минем иптәшләрем? Хәбир? Касыйм? Шакир? (Синең кушаматың Челән Шакир иде бит, син буйга бик озын идең.) Сезне соңгы сугыш ялмап йотты. Исән-сау әйләнеп кайтучылар яраларыннан үлделәр.

Минем каршымда яңа кешеләр. Машиналы, мотоцикллы, ун еллык белемле яшь кешеләр. Югары уку йортын тәмамлаган кешеләр...

Мин аллага ышана идем. Сез ышанмыйсыз. Мин бичурага, жеңгәпәригә, су анасына ышана идем. Сез, каһәрләр, ышанмыйсыз. Олы күлдә су анасының, басмага чыгып, ай яктысында чәч тарап утыруын күреп кайттым дип, Закир сукыр ялганлагач, без шуңа тәмам ышанган идек. Сукыр башы белән су анасын ул ничек күргән, шуны уйлап карамаганбыз. Ә сезне бар ышандырып кара. Без бүтәнрәк кешеләр идек шул. Сезнең әнә чатыр-чотыр мотоциклыгыз гына да биш су анасын, алты албастыны, жиде шүрәлене өркетеп качырырлык!

Хәер, без дә үзебезчә бәхетле идек. Баш очыбызда әйләндереп-әйләндереп торганнан соң, шарт иттереп чыбыркы шартлату рәхәте үзе генә дә ни тора! Андый чыбыркы эләкми әле ул сезгә. Аждаһа юанлыгы (тфү, тфү, хәзергеләр аждаһага ышанмыйлар, ә без ышана идек), аждаһа озынлыгы, дегетле, кыл очлы авыр чыбыркыны шартлатып карау бәхетенә ирешү өчен, башлап торып без көтүче агайның көтүдән качып игенгә кергән сыерларын борып алып кайтып бирә идек. Шуннан соң гына чыбыркы безнең кулга керә иде. Анда да әле көтүче агайның кәефе яхшы чак булса гына, бүген иртән фәлән абыстай аны итле токмач белән сыйлаган булса гына, янчыгы тулы махоркасы булса гына...

Әйе, без дә үзебезчә бәхетле идек. Авылга тәрәзә куючы килгәч, аның артыннан көнозын ияреп чабып йөрү бәхет түгелмени? Пыяла куючы җәяү килмәгән, ат җигеп тә килмәгән, калайлары елтыр-елтыр итеп тора торган ак велосипедка атланып килгән! Ә велосипедны безнең беренче күрүебез. Велосипедка безнең бармак белән орынып карыйсыбыз килә. Атланып карыйсыбыз, егылып карыйсыбыз килә... Пыяла чы агай безгә ерактан гына кararга рөхсәт итә. Кыңгыравына басарга теләсәк, әрләп куып җибәрә...

Минем әни дә тәрәзәнең ватык күзенә (мин ватканмындыр, минем терсәк бик тик тормас терсәк иде) пыяла куйдырды. Мин карап-карап тордым да бу пыяланы яңадан алып, яңадан куеп карамакчы булдым. Пычак тотып чыгып, замазкасын әйбәтләп кырып алдым да пыяланы куптарып нигезгә сөядем. Шул вакыт әни күрмәгән булса, күреп җилкә тамырына йодрык белән берне кундырмаган булса, мин ул пыяланы яңадан куймас идеммени? Замазкасын элеккедән дә яхшырак итеп яңадан сыламас идеммени? Әле ничек кенә сылаган булыр идем.

Минем бу эшемне малайлар карап тордылар. Карап кына түгел, котыртып, көч биреп тордылар (янәсе, булдыра, булдыра, пыяланы дүрткә ватарга өлгермәсә куячак!). Әнинең минем җилкәгә тамызганын күргәч, рәхәтләнеп шырык-шырык көлештеләр. Ә мин, юләр, аларны дуска санап, замазканың бер кисәген тотып кararга биргән идем. Биргәндә үзем генә бирдем, сораганда әни белән сорадык, шулай да кайтарып ала алмадык. Янәсе, нинди замазка ул, күргәнебез дә юк. Ул көнне миңа әнидән, ай-яй, эләккән иде. Әле дә булса кабыргалар чымырдап тора — шул вакытныкы...

Бүрәнә өстендә әкият сөйләшүләр, яңгыр боткасы пешерүләр, кызлар белән әйлән-бәйлән, сукыр бүкән, таккаравыл, биш таш уеннары уйнаулар, атка атланып болында җилдәй чабып йөрүләр, иреннәребез күгәргәнче су коенулар, кышларын мәдрәсәдә мендәр белән сугышулар — болар үзенә күрә малайлар өчен зур рәхәт түгелмени?..

Аннары беренче тапкыр китап тоту рәхәте. Хәзерге заманда гына ул китап күп. Авыл саен китапханә, мәктәпләрдә дә китапханә... Без малай чакта алай түгел иде. Китап бик кадерле иде. Әти, базарга чыгып киткәндә, «Китап алып кайтырмын» дисә, ул көнне җанга тыныч лык бетә иде инде. Кайчан кайта дип, алып кайтамы дип, әллә таба алмыйча буш кул белән кайтып керәме дип, көн буе ут йотып тора идем. Юлга этинең каршысына чыгып торулар, кулга китап эләккәч, куанычтан сикеренүләр, китапны тышлаулар, кадерләп кенә укулар... Хәзерге яшьләр андый рәхәтне белләрме икән?

Безнең авылда русча-татарча мәктәп ачылды. Әле революциягә хәтле үк. Карт мулла дип йөртелгән Садыйк мулла (Садыйк Галимов) бу мәктәп өчен бинаны үз йорты янына салдырткан иде. Башлап мәктәптә мулланың Әхәт исемле улы укытты (Әхәт абый дип йөрттек). Бер кыш рус телен Аркадий атлы рус укытты (безнең телдә аның исеме Әркәди иде). Алардан соң Кадыйр Халитов исемле шушы Карамал авылы кешесе укыта башлады. Шушы мәктәптә укып чыккан безнең авыл егетләре революциянең беренче елларында зур урыннарда эшләделәр. Абыегыз да шул мәктәптә белемнән беренче тапкыр авыз итте.

Революциядән соң авылда урта мәктәп ачылгач, Кадыйр Халитов, урта мәктәпкә күчеп, ничәмә-ничә буын балаларын (үзебезнең авылныкын да, күрше авылларныкын да) тәрбияләп чыгарды. Аның шәкертләреннән чыкты врачлар, чыкты инженерлар, чыкты геологлар, чыкты... Кыскасы, дөньяда нинди профессия кешеләре бар, бар да чыкты. Халитов Ленин ордены белән бүләкләнде, атказанган укытучы исемен алды. Хәзерге көндә ул инде вафат.

Мин әкрен генә авыл урамыннан барам. Бу минем туган авылым Карамал. Миңа инде алтмыш яшь. Мин үземнең малай чагымны эзләп

кайттым. Күземне йомсам, күз алдыма тузанлы урамнан чабып баручы чандыр гына бер малай килә... Өстендә эшсе суккан күк күлмәк, ботында алача ыштан. Аяклары чебиләгән. Бу мин шулай үз хыялымда чабып йөрим. Чабарга дигәндә мин бик оста идем шул... Исәнме, тузан туздырып чабып йөрүче түбәтәйле яшьлегем? Исәнмесез, тал агачлары! Кызыл авызлы тирән ермаклар, исәнмесез!

— Исән әле, бик исән, — диләр кебек тагын да тирәнәя төшкән кызыл ермаклар. — Үзең исәнме! Без сине бик хәтерлибез. Язгы ташу кайткач, ермак төпләреннән шома ташлар җыеп, аларны уенчык итеп (кайсын коймак, кайсын кабартма итеп) уйнап йөри идең син, шук малай!

— Исән әле, бик исән, — диләр кебек яр буендагы карт өянкеләр.— Без дә сине онытмадык, безнең ботаклардагы карга ояларына көн күрсәтми торган идең син!

— Исән әле, — диләр кебек мина тузанлы юллар. — Карамал юлларын онытмагансың, кайткансың... Син киткәннән соң бу юллардан күпме кеше китте, күпмесе кире кайтмады...

— Э менә мин кайттым... Карамал юлларын бик яхшы беләм. Шушы юллар бит инде минем әтине шахталарга алып киткән, алып кайткан. Шушы юллар минем әнине алып китте дә кайтарып куймады. Шушы юллар үземне дә алып китеп балалар йортына илтеп бирде...

— Әйтегез әле, ни өчен соң каберстанда каберләр ул тикле күбәеп китте? Э? Вакытлар бик күп үткәнгә дисезме? Синең үзеңә дә инде алтмыш тулды, дисезме? Шулай шул. Вакыт аккан су кебек үтте дә китте. Алтмыш.

Клуб каршында кино көтүче әнә теге яшьләр өчен бүгенге машиналы, кинолы, телевизорлы Карамалдан башка, бүтән Карамал юк бит инде. Аларга Карамал гел шушындый булгандыр да гел шушындый булыр кебектер. Миңа да кайчандыр Карамал баш өстендәге якты кояшы, тулган ае, чекерәешкән йолдызлары белән, авыл уртасындагы зәңгәр манаралы мәчете белән, малайларны лапыр-лопыр куып килә торган усал ата казлары, ыржаеп капка астыннан өреп чыга торган усалдан усал бурзайлары, актырнаклары, сарыколаклары белән, албастылары, бичуралары, убырлары белән мәңге булгандыр һәм мәңге булачак кебек тоела иде. Сука белән җир сөрүче, чана белән печән ташучы, тегермәндә дөнья хәлләрен сөйләшеп утыручы Җәлил абзыйлар да, Гапсаттар агайлар да мәңге булган, мәңге булачак кебек иде.

Менә бүген дә... Һаман шул ук кояш. Ай да шул ук. Йолдызлар да. Ике тау арасындагы чишмәләр дә... Агайлардан тау башында каберләр генә калган. Ул каберләрне дә инде эзләп табып булмый, чөнки авыл башлыклары үзләренең эти-әниләре яткан каберлекне койма белән әйләндереп алуны кирәк тапмыйлар. Олы күлдәге су анасы да күптән вафат, шүрәлеләр дә, бичуралар да вафат... Чыпчыклар да бүтән — яшь чыпчыклар, каргалар да... Тормыш бүтән. Кырык-илле ел эчендә шундый мәңге үзгәрмәс шикелле тоелган авыл танымаслык булып үзгәрде.

Үзгәрде. Ләкин мин иске Карамалны, яшь чагымдагы ал истәлекләргә төренгән карт Карамалны, бөтен иске матурлыклары белән һаман күреп торам. Җәлил абзый да исән, Гапсаттар абзый да... Тау башындагы җил тегермәннәре дә... Минем нигез күршем Галиәскәр абзый әнә урамдагы биек кузла башына менеп баскан да, буй пычкының югары башыннан тотып, кулларын канат шикелле җилпи-җилпи, үзенең олы улы Габделбарый абый белән такта яра. Габделбарый абый пычкыны аскы башыннан тоткан, гүбәтәенә, иңбашларына, кашларына сап-сары булып пычкы чүбе кунган, аяклары тубыктан агач ярмасына баткан... Алар йорт салалар.

Габделбарый абый дигәч искә төште: әни аңардан гел зарлана.

Ул безнең читәнне таптый икән. Караңгы төшкәч, безнең бакча читәне аркылы Әсма апаларга кереп китә икән. Мин дә керәм Әсма апа янына. Төнлә кермим, көндез керәм. Читән аркылы кермим, капкадан керәм. Мин аның уенчыклары белән уйныйм. Ул үзе инде уйнамый, ул үскән, мин уйныйм аның тәти чынаяклары белән... Габделбарый абый бит инде чынаяк уйнамый. Нигә дип төнлә безнең читәнне таптый икән? Шуны һич аңлый алмыйм.

Җәлил абзый, мәрхүм, бик үк ярлы хуҗа булмаса да, камыт бавын ни өчендер гел юкәдән генә ясый иде. Ә тау башындагы җил тегермәне, мулла тегермәне дип йөртелгән тәбәнәк буйлы базык тегермән, бик тә холыксыз нәрсә иде, бичара. Катырак җил чыкса, канатларын тотып-тотып җиргә ата иде. Гүя ярминкәдән исереп кайтып килүче Шәйхәттар агай: ул да бит тиктомалга без малайлар алдында үзенең бүреген җиргә күтәреп бәрә иде. Ә икенче берсе, тегермәнне әйтәм, бик авыр сөякле иде, көчкә кыймылдый иде. Аның каравы онны мамык иттереп тартып бирә торган иде. Дөрес булса, андый мамык оннан пешкән кайнар кабартма бик тәмле була иде дип сөйлиләр. Хәер, минем андый оннан пешкән кабартманы ашап караганым булмады.

Ә бүгенге яшьләр колхозның электр тегермәнен генә беләләр, анда да әле Диллус абыйлары тегермәнгә кертәме икән аларны? Ә без бит тегермәндә куна-төнә ята идек. Тегермәнчедән яшереп, аның салат онын ашый идек. Тәмәке тартырга да шушы тегермәндә өйрәндек. Төрле кызыклы әкиятләрне дә шушы тегермәндә ишеттек, дөнья хәлләрен дә тегермәннән белеп кайта идек. Тегермән безгә клуб иде, мәктәп иде.

Әйе, барысы да күз алдымда... Күпер башы Хөснулла абзыйларның бакчаларындагы киң авызлы кызыл ярлар, андагы бака яфраклары, балтырган үләне... Балтырган җыеп кайтырга дип килгән мин үзем, ябык, чандыр малай (шундый ябык, сөяккә тире генә тартып куйган, кабыргаларны бармак төртеп санап чыгарга була!).

Балтырган жыярга мине әни җибәрде. Балтырганнан ул аш пешермәкче була. Булуын була да, үлән ашына йомырка сытарга кирәк, май салырга... Ә безнең маебез юк, чөнки сыер асрый алмыйбыз, чөнки без ярлы, чөнки этиебез үлде. Балтырган җыеп кайтып биргәч, әни мине Җәлил абзый хатыны Гажилә апа янына сөт сорарга, май сорарга кертәчәк, ә минем һич тә керәсем килми, аларның ата казлары бик усал...

Тирән яр эченнән миңа күк йөзенең бер кыйпылчыгы зәп-зәңгәр булып күренеп кала. Мин, туктап, гажәпләнеп карап торам: нинди нәрсә ул зәп-зәңгәр күк йөзе, ак болытлар, кояш, йолдызлар? Очып барган ап-ак болыт кисәгенә минем бармак белән төртеп карыйсым килә...

Ә кошлар? Бер генә көнгә кош булып торсаң иде, бер генә көнгә, бер генә сәгатькә... Әнә теге тилгән кебек, канат какмыйча, көн буе һавада әйләнеп йөрсәң иде. Бик рәхәттер югарыдан авылда ниләр барын, кемнәрнең нишләвен карап йөрү... Кошларга мин бик сокланам. Кош теләсә кая таба оча ала. Теләсә Олы күл өстенә барып чыга, теләсә мәчет манарасына куна, теләсә Иделдәге пароходларны барып күрә ала... Ә мин бик теләсәм дә Олы күлдән ары бер яры бара алганым юк, анда да әле әни җибәрсә генә. Әни әйтә, су анасы алыр үзеңне, йөрисе булма күлгә, ди.

Инде самолетларда да күп очылган, тик шулай да малай чактагы кош булып очып кararга теләү һаман күңелдә яши. Самолетта очканда очу рәхәтен сизмисең, киресенчә, кыймылдамыйча, бер урында утырып тору авыр. Бәлки, очу рәхәтен пилотлар беләдер, бигрәк тә аваз тизлегеннән дә тизрәк оча торган самолетларны йөртүче пилотлар... Ә без, гади пассажирлар, самолет тәрәзәсеннән карап, шырпы тартмаларыннан торган шәһәрләрне, шәһәр урамындагы кырмыскаларны, атлап чы-

гарлык сары елгаларны, теш казыгычына гына сындырып алырлык агачларны йөз дә беренче кат күреп баручы пассажирлар, очу рәхәтен татымыйбыз...

Балтырганны алып кайтып бирдем. Әйттем бит: әни Җәлил абзыйларга сөт сорарга кертә дип... Казлары өйдә юк, күлдә, ди әни әйтә, курыкма бар кер, ди. Кулыма табак тоттырып, аркамнан этә... Әй, яратмыйм да соң кешегә әйбер сорарга керүне! Ата казны да кермәс өчен генә сылтау итәм. Бик куркып тормыйм ата казларыннан...

Илле еллап элек йөргән эзләремә басып йөрим. Таулар шул ук та, түгел дә... Урамнар да шул ук, ләкин шул ук түгел дә... Әнә колхоз председателе Габбас Кәримуллин, үзенең «Победа»сына утырып, кырлар йөреп кайтып килә... Урак өстә якыная. Балта осталары ябык ындырны киңәйтәләр... Аларның балталары кояшта ялтыр-йолтыр итеп китә... Озакламый комбайннар борчак ура башлаячак...

Авылда комбайн, радио, телевизор, урта белем, югары белем... Шулай да авылга күп нәрсә җитми әле: башлап төзеклек җитми. Яңа йортлар аз. Коймалар юк, читәннәр ауган. Шул ук радио: авыл радиолашкан, дибез. Ләкин радио теләсә сөйли, теләмәсә юк. Теләсә кычкырып җибәрә, теләсә чыштын-пыштынга күчә. Шул инде радиолашкан санала. Сводкаларда, отчетларда радиолашкан, тормышта, практикада радиолашып җитмәгән.

Суны алыйк: авыл уртасында инеш. Суы чиста, салкын. Ләкин бит ул авыл уртасында, э югары очларга су ташу кыен, бигрәк тә кышкы буранларда, бигрәк тә мунча яккан көнне. «Нишләп бакчагызга яшелчә утыртмыйсыз?» дисәң, «Су юк!» диләр. Чынлап та, көянтәләп ташып, күпме генә кәбестә, кыяр, помидор, кишер үстерергә мөмкин? Әгәр берәр агай алма бакчасы үрчетергә теләсә? Элек бит Карамал алма бакчалары белән дан тота иде. Авылга килеп кермәс борын ук көз көннәрендә алма исе килеп бәрелә иде. Элек заманда хуҗа бакчага суны мичкә белән ташып сибә иде шул, хәзер хуҗалыкларда атлар юк. Димәк, балаларга кара карлыган да юк, виктория җиләге дә, помидор да, кишер дә юк. Колхоз бакчасыннан җиләк-җимеш алып булмый, чөнки колхоз өләшми, илтеп сата.

Көнкүреш ягы Карамалда (бер Карамалда гынамы?) шактый унайсыз. Гомуми мунча кирәк, пекарня кирәк. Аяк киемнәре төзәтә, иләкчиләк төзәтә торган мастерской кирәк. Магазин кирәк. Хәзерге кибет кысан, карангы. Яхшы клуб кирәк. Китапханә кирәк. Кайчандыр искене бозып салган клуб та яраган. Хәзер инде ярамый. Казаннан артистлар килсә, клуб кечкенә, клуб иске. Китапханә дә бозып салган гына. Кечкенә. Китаплары аз. Кайчандыр бөтен Тәтеш кантонында культура ягыннан данлыклы Карамал бүген мескенләнеп калган.

Кешеләр, барлык җирдә дә авырган кебек, Карамалда да авырганнар. Фельдшер бар. Пункт бар. Тик бинасы кышын шундый суык була дип сөйлиләр, мичендәге утлы күмер суыктан дер-дер калтырый, имеш. Бинаны тышлау, җылыту — әллә кем эше. Колхозныкы да түгел, авыл Советыныкы да түгел. Авырырга осталык зур, авырырга өйрәнеп життек. Берни булса, уколга йөгереп киләбез. Юк, эчә торган дару кирәкми, укол булсын, укол бик шифалы. Анысына өйрәндек. Э менә медпунктны жылытырга, анда эшләүчеләр өчен адәм рәтле эш шартлары булдырырга өйрәнеп житә алмыйбыз. Гүя пункт авыл өчен, колхозчылар өчен эшләми, э урмандагы шүрәле өчен эшли.

Пунктгагы фельдшер күрше авылларга да йөри. Әлбәттә, жәяү йөри. Кышын да, жәен дә... Әгәр авырган авыл ат жибәрә икән, алып килү өчен генә жибәрә, кайтып китү фельдшерның үз эше. Авылда белемнең һәм белем ияләренең кадере киткән. Янәсе, урта белемсез дә сөт савучы булып була. Янәсе, үзегезгә зур хезмәт хакы алу өчен генә безнең балаларны укыттырасыз. Шуннан китә инде: медпунктта

туң, авыллар арасында жәяү чап, син бит акча аласың. Янәсе, миңа рәхмәт әйт, минем баламны укытып акча көрисең!

Туктагыз әле, сүз башым бит шүрәле дигәндәй, сүз малай чагым турында иде түгелме? Әти үлде, дигән идем. Ә минем өчен әти исән, әни дә исән, алмагач кимерергә бик ярата торган азгын кәҗәбез дә исән... Кәҗәбез безнең гел бер урында әйләнеп торырга ярата. Әни әйтә, аңа әйләнчек булган, ди. Шундый авыру бар икән. Авыргач ничләп соң аның күзләре шундый матур? Гыймадый абзый кибетендә сатыла торган кара җимеш төсле... Мин аның күзләренә бармагым белән орынам, ә кәҗә... Әни әйтә, ул күрми, ди, сукырайган, ди. Кызык, шундый матур күзләр күрмиләр...

Бер көнне ишек алдына чыксак, кәҗәбез үлгән. Кәҗәдән соң чебеш әнкәбез тәгәрәп үлде. Әллә ничә еллар буе чебеш чыгара-чыгара остарып беткән чебеш әнкәсе иде. Чебиләр чи-чи килеп йөгерешеп йөриләр, әнкәләре читән буенда аунап ята...

Әти исән чакта сыерыбыз да бар иде, атыбыз да... Кешегә сөткә керми идек. Атны инешкә сугарырга барганда, эти мине атландырып бара иде. Ул вакытта миңа ничә яшь булды икән, бер биш яшьтән артык булмагандыр. Атның ялына чытырдап ябышам, ботларым белән сыртын кысам. Ат куркыпмы, я ничекме анда катырак чабып китсә, биянең сыртыннан очып төшеп калган чакларым да була иде. Андый вакытта эти миңа: «Егылмадың, юк, сикердең генә», ди торган иде дә, мин үземнең егылмаган, ә сикергән генә булуыма тәмам ышана башлый идем.

Хәтеремдә, җәй көне кичләрен олылар Галиәскәр абзыйларның өй каршыларындагы бүрәнәләренә чыгып утырырга яраталар иде. Әтинең чабуына тагылып, мин дә бүрәнәгә чыга идем. Бер тапкыр... Ялган булмасын, эңгер-меңгер төшкән чак иде бугай. Эти әйтә, бар кер дә ятып йокла инде син, ди, мич артындагы чикерткә сине юксынып беткәндер, ди. Мин әйтәм, юк, мин синең белән бүрәнә өстендә утырам. Галиәскәр абзыйның мунча пәрие турындагы беркөн сөйләп бетермәгән әкиятен тыңлыйм. Бәйләнеп булса да утырып калдым.

Баш өстендә кыеклап-кыеклап ярканатлар очалар. Һава тәмле төтен исләре белән тулган. Эти шунда әйтте, бар әле, улым, диде, Җәлил абзаңның яшь үгезе урамда калган икән, куып керт шуны, бер яхшылыгың булсын, диде. Карасам, урам уртасында караңгыда чынлап та үгез басып тора. Йөгердем. Кычкырам — үгез кыймылдамый да, кизәнәм — үгез бар дип тә белми. Таяк алып тегенең бот башына шарт! Үгез борылды да минем өскә! Мин куркып бер читкә... Бүрәнәдәгеләр шырык-шырык көлешәләр... Аларга көлке, ә мине үгез үзенең мөгезенә элмәкче... Тик соңыннан гына әйттеләр, үгез бөтенләй үгез булмаган, Галиәскәр абзыйның олы улы Габделбарый абый, тунын эчке ягы белән бөркәнеп, урам уртасында дүрт аякланып басып торган, эти мине юри үгез куарга дип жибәргән. Мәрхүмнең шулай шаяргалый торган гадәтләре бар иде.

Безне атсыз да, сыерсыз да, сөтсез дә, майсыз да калдырып, үзе үлде дә китте. Рәхмәт Гажилә апага, сөтне күп итеп биреп чыгарды, өсте алынган сөт булса да бик әйбәт сөт. Әни балтырганнан аш әмәлли, үлән ашына сөт катып ашап жибәргәннән соң абыегызга көч кереп китәргә тиеш, ә көч кергәч мин инде бер урында гына басып тора алмыйм, тагын урамгамы, бакчагамы йөгереп чыгып китәм...

Әни кызык кеше:

— Агачларны сындырма, үләннәрне, чәчәкләрне өзмә, алар барысы да аллага зекер әйтеп, дөньяда яшәүләре өчен куанышып утыралар, үсә бирсеннәр,— ди.

— Ә балтырган аллага зекер әйтмимени? Балтырганны ни өчен өзәргә ярый?

Сораулар белән бик йөдәтә башласам, жавап таба алмаса, әни:

— Бар, тамагың туйды инде, бакчадан әрекмән жыеп кайт, төеп тавыкларга бирербез, — дип, миннән котылырга тырыша.

— Әрекмән дә үлән бит, аны өзәргә ярый. Кычытканны да ярый, эт эчәгесен дә, сөтле үләнне дә... Гажәп бу дөнья. Кайсын ярый, кайсын ярамый.

— Ә баканы үтерергә ярыймы? — дип сорыйм мин әнидән.— Бака да аллага зекер әйтәме? Шундый ямьсез нәрсә?

— Бакага да тиярга ярамый. Бака яңгыр тели, идән астында чөлдерррр итеп бака кычкырганны ишеткәнең бардыр ич, чөлдер дигәне яңгыр теләве инде аның...

Үләнне, чәчәкне өзәргә ярамау белән килешәм. Үлән матур, чәчәк матур. Ә менә таш астында ята торган чабата-чабата бакага ник тиярга ярамый, һич аңламыйм. Яңгыр ул бака теләмичә дә ява. Ә бака ямьсез, бака мут, бака хәйләкәр, ташны күтәргәч, башын төртеп, үлгәнгә салышып ята. Өстенә баса башласаң, сикерә дә китә... Шундый котсыз тагы үзләре... Әни ярамый дигәч, ярамый инде, үтермим мин аларны, ә үзләрен бер дә яратмыйм.

Баланың шушындый наив тикшеренүләреннән башланып киткән бит инде бүгенге фән, бүгенге философия. Бик борынгы кешеләр белем ягыннан бала булганнар. Бүгенге әти-әниләр баланың төпченеп сорашуларына түземлек белән дөрес жавап бирә барсалар, бәлкем, балага ун ел буе мәктәпкә йөрүнең кирәге дә булмас иде. Профессия сайлаганда да аптырамас иде. Белергә тиешле гыйлем күләме елдан-ел арта. Укыту хәзергечә барса, урта белем алу өчен генә дә кешегә уйбиш еллар мәктәп эскәмиясендә утырырга кирәк булмагае. Ә кайчан яшәргә? Кайчан эшләргә? Гомер артмый бит.

Начар ашаганнандыр инде, тавык күзе каныкты. Кич булды исә, берни күрмим. Яктыда чыгып китеп, караңгыга калсам, өйгә кайтып керә алмыйм. Андый чакта иптәш малайлар сизеп алсалармы, беттең диген. Аларга уен, йөгерешеп сине ташлап китәләр дә, тыннарын да чыгармыйча, берәр жирдә посып торалар. Син, күзе ачылып житмәгән мәче баласы кебек, ары-бире төртелеп, кая таба барырга, ничек кайтырга белми аптырыйсың. Менә бервакыт әллә кайдан ерактан сиңа кычкыралар:

— Без монда! Кил бире! — Син абына-сөртенә тизрәк тавыш килгән якка йөгерәсең, ә тавыш ул арада бөтенләй икенче яктан ишетелә башлый.

Инде үскәч, һәвәскәр артистлар белән Тәтештә спектакльләр уйнап йөргән чакта (абзагыз артист та булып йөрде бит!), тагын шулай тавык күзе авыруы белән жәфаландым. Ярый әле — уйный торган ролем комический иде: абынып егылсам да көләләр, килеп бәрелсәм дә көләләр. Ә миңа бер дә генә көлке түгел, электр яктысында да күрмим.

Канткомның агитпроп башлыгы шулай бер тапкыр олылар спектакленда уйнарга кыстый башлагач, тегенә серне ачтым. Ышанмый, врачтан язу китер, ди. (Ышанмау элек-электән килгән авыруыбыз.) Тәтештә Соколов дигән күз врачы бар иде. Киттем аның янына. Соколов әйтә, тавык күзен белеп булмый аны, ди, шулай да справка бирде. Справкага өстәп, тимер тамчысына рецепт биреп жибәрде. Янәсе, миндә малокровие икән дә шушы тимер тамчыларын эчсәм, полнокровие булачак.

Тәтештә тагын бер врач бар иде. Аркадий Боголюбов. Минем хәтергә ул сарырак сакал-мыеклы, базык гәүдәле булып кереп калган. Ул больницада эшләүдән тыш үз өендә барлык кешене акчасыз кабул итә иде. Без, приют малайлары, авырып китсәк, аның өенә йөгерә торган идек. Ул карый да, үзе даруын да биреп жибәрә иде. Унту-

гызынчы, егерменче елларда шәһәр клубында лекцияләр укыганы исемдә. Боголюбов гомер буе Тәтештә яшәде, атказанган врач исемен алды. Ватан сугышыннан соң, үземнең бала чакларымны искә төшереп, Тәтешкә барып чыккач, мин доктор Боголюбов янына кердем. Сөйләшеп утырдык. Ул үзенең яшь чакларын, холера белән, трахома белән көрәшеп йөргән заманнарын хәтерләп, Тәтештә үткән беренче елларын миңа сөйләп бирде. Картайган иде инде. Соңгы елларда ул үлеп китте. Аны Тәтештә генә түгел, Тәтеш тирәсендәге авылларда да бик яхшы беләләр иде.

Менә шушы әйбәт кешенең, бөтен гомерен халык бәхете өчен куйган олы жанлы кешенең, яхшы врачның истәлеге яшь буыннар күңелендә саклансын дип, тәтешлеләр бер урамга Боголюбов исемен кушканнар.

Бүгенге Карамал яшьләре авылдагы үзләре укый торган зур тәрәзәле, якты бүлмәле урта мәктәпне генә беләләр, кайчандыр мин укып йөргән сукыр тәрәзәле, тәбәнәк түшәмле караңгы мәдрәсәне белмиләр. Юк, мәдрәсә турында язарга жыенмыйм. Язылырлыгын инде яздылар, аннары безнең авыл мәдрәсәсе типик мәдрәсә түгел иде. Алай да мәдрәсә шуклыклары бар иде. Мендәр белән сугышу, чиртмеш уйнау, каләм уйнау... Эчә торган чәйнеккә бәвел итү... Әйттем бит, язмыйм мәдрәсә турында, тик үземнең беренче тапкыр укырга баруымны гына язып үтәм. Әти житәкләде дә алып китте. Миңа алты яшь. Равил абый, безнең мөгаллим,— гомере озын булсын, амин! — миңа беренче көнне **Са** хәрефе яздырды. Әлс дә хәтеремдә, язган юлым кыегаеп-кыегаеп аска таба төшеп киткән иде. Сез әйтерсез инде, төшеп китмәгәе, анда безнең ни эшебез бар, диярсез. Дөрес, сезнең эшегез юк. Ләкин миңа, беренче тапкыр укырга барган көнемне исемә төшереп, бер рәхәтләнергә ирек бирегез инде. Ул көн бит миңа бик кадерле. Тик менә ни өчен беренче көнне үк Равил абый, әлифбаның уртасыннан тотып, **Са** хәрефен яздырган, э бүтән берәр хәрефне яздырмаган? Әйтик, нигә **Ты** хәрефе түгел, я нишләп **А** түгел? Бусын инде мин Равил абыйдан сораганым юк.

Бик кызу кеше иде, Равил абыйны әйтәм. Берни булса, чалт яңакка! Янсә утырган жиреннән өстенә коръән белән шалт! Тондыра. Идәнгә егып, тимерле каеш белән суктыра торган иде. Сабакларын белмәүче малайлар, кыйналудан куркып, мәдрәсәгә килми качып йөриләр иде. Шулай да рәхмәт Равил абыйга, укырга-язарга өйрәтеп чыгарды.

Бик күп еллар читтә йөреп авылга кайткач һәм Даныш урманындагы колхоз умарталыгына Равил абый янына баргач, әйттем тегенәргә:

— Әй-яй, Равил абый, яшь чакта син яман кызу канлы идең,— дидем.

— Мин хәзер дә кызу канлы,— диде бу.

Мәдрәсә турында язмыйм дисәм дә, үзем дә сизмәстән әллә нихәтле язып ташлаганмын. Тагын бер-ике генә сүз. Сыйныфта (хәзергечә әйтсәк, класста) Гарифулла тана исемле егет бар иде. Үзенә инде каралып мыек чыккан, гәүдәсе белән тана гына түгел — үгез! Әнә шул мыекбай дәрәссен тынлата алмагач, мөгаллим, әлеге яман кызу канлы Равил абый, безгә — алты-жиде яшьлек малайларга — әйтә: өйрәтегез сабагын шул күсәкнең, ди. Яңаклагыз үзен! Гарифулла абый (әйтәм бит, инде мыеклы, өйләндерергә вакыт) ничә еллар мәдрәсәдә утырып та әлифне таяктан аера алмый, без аның сабагын өйрәтәбез. Мөгаллим моның яңагына чабарга куша, э без чабарга куркабыз: үзенә кире берне салып торып жибәрсә, бөз бит инде әллә кайларга чәчрәп барып төшәчәк. Шулай да мөгаллим чабарга кушкач чаптык. Чаптык дип, уч белән битенә орындык. Менә мөгаллим абзый жилләнеп килеп житте.

— Алай чабалармыни! Менә болай чабалар аны! — дип, башта минем яңакка салып жибәрде, күзләремнән утлар күренде, аннары Га-

рифулла тана яңагына! Ул кымшанмый да, тана кебек мышный гына. Кыйнала-кыйнала өйрәнеп беткән инде. Ә минем яңак, кыйналырга өйрәнмәгән яңак, көн буе янып йөрде.

Әти, үләренә берме-икеме көн калгач, мине урамнан чакырып кертеп сөйләште. «Әниеңнең сүзен тыңла!» дип әйтеп калдырды. Бик тыңлыйсы иде дә бит, әни эшне уенның нәкъ кызган чагында китереп куша. Ничек инде шундый тәмле уенны ташлап, эшкә тотынмак кирәк! Бүтән малайлар әнә эшләмиләр, рәхәтләнеп уйнап йөриләр. «Аларның әтиләре, абыйлары бар, ә син үзең әти урынында калдың». — Бу мина әнинең жавабы. Ай, уеннан аерылып эшкә тотынулары... Уйнарга бик яратам шул мин. Шар сугулар... Качышлы уйнаулар... Аннары биш таш уенын бик яратам. Кызлар уены булмагае... Мин аны кызлар белән уйныйм да... Гөлниса, Галиәскәр абзый кызы, ота да ота мине. Отып кына калса ярар иде, отканнан соң котырта: — Бетләдең, ди, бетле чумар ашадың, ди... Биш ташны тегенең битенә атарлык булам. Йодрыкларымны йомарлап, кызның өстенә ташланам. Гөлниса капкаларыннан кереп кача да ярыктан миңа телен күрсәтә...

Икенче көнне, берни булмаган кебек, без янә бергә... Бүрәнәгә аркылы такта куеп, таган атынабыз... Әллә нәрсә шунда, гел шушы Гөлниса белән уйныйсым килә. Юкса инде бүтән кызлар да бетмәгән ич... Бер тапкыр Гөлниса үзләренең тәрәзәләреннән елмаеп миңа карап торганда, такта яра торган кузла башына мендем дә агач ярмасына сикердем дә төштем. Шундый биектән бит! Гөлниса: «Юләр!» дип кычкырды. Көлде. Аннары икенче бер тапкыр, Гөлниса кечкенә чиләкләр белән инештән тыпыр-тыпыр су алып кайтып килә иде, Жәлил абзыйларның ата казы муенын сузып, гыжылдап, моның өстенә томырылып килә башлады. Мин йөгереп барып, ата казның түшенә тибеп торып жибәрдем! Каян килгәндер миңа шундый батырлык. Бүтән чакта ата каз күрсәм, үзем дә биш чакрымнан әйләнеп үтәм.

Кайвакыт мин читән тишегеннән Галиәскәр абзыйларның ишек алларына карап торам. Гөлниса чебешләр туйдыра... чикерткә сыйрагы кебек озындыр сыйраклары, ә куллары... Кояшта янган кара куллары неп-нечкә... Икмәк катысын чәйни дә чебешләргә ата. Чебешләр талаша-талаша ашыйлар да, ашап бетергәч, Гөлнисаның артыннан өялды баскычына менеп китәләр. Гөлниса, күлмәк итәген жилпеп, аларны өялдыннан куып төшерә...

Ә бер тапкыр сукыр тәкә уены уйнаганда, Челән Шакир Гөлнисаның элеге неп-нечкә кулларыннан тотты. Шундый ачуым чыкты, әтәч кебек өстенә барып кунасым килде. Аның ни хакы бар Гөлнисаның кулыннан тотарга? Гөлниса Челән Шакир күршесе түгел, минем күршем! Гөлнисасын әйтер идем, шул Челән пәридән кулын тоттырып тора...

Юк, минем үпкә бик тиз бетә... Гөлнисага һич ачу саклый алмыйм. Тик менә көнозын минем белән уйнасын икән ул, ә ул керә дә китә. Мин өй нигезендә утырып калам. Чыгар әле дим, көтә башлыйм. Аптырагач, тәрәзә яңагына ябышып, өй эчләренә карыйм. Гөлниса мәче баласын тоткан да утыра. Юк, мәче баласы түгел, йомгак, йон йомгагы тотка... Тәрәзәдә мине күрде дә, кашларын жыерып, кечкенә генә йодрыгын күрсәтте. Казан тирәсендә кайнашкан әнкәсенә таба ымлый: кит тәрәзәдән, әни күрер, дип әйтүе... Мин китмим, борынымны пыялада ямьшәйтеп, һаман тәрәзәдән карап торам. «Чык!» дип, кул изим. Ул йомгагына күрсәтә, йон катасым бар, ди.

Бер көнне Гөлнисаны алдап жиләккә алып киттем. Ни өчен алдап? Барырга теләмәгәнгә. Зират елгасында жиләк күп, әйдә! — мин әйтәм.

— Тукта, савыт алып чыгам, — дип, өйләренә кереп китте.

Качты дип курыккан идем. Чыкты тагы. Киттек. Анда бер жиләк, монда бер жиләк. Аларны алып каптык. Жыеп бетергәннәр икән, дим, әйдә Ике тау арасына, анда шундый күп, хет утырып жый.

Ярны чыкканда кулыннан тотып чыгардым. Терсәге чат сөяк... Әни әйтмешли, ит кунмаса да кунмас икән кешегә. Ә бит минем ише түгел, көн саен сөт ашый: сыерлары бар, таналары... Атлары хәтта икәү... Ә үзенең кулын тотарга куркыныч, өзелеп төшәргә тора... Куркыныч дип тормыйм тагы, тотам. Тотышабыз да чәчәкле үләннәр эченнән йөгерешеп китәбез...

Ике тау арасында җиләк табылмагач, Ташлы елгага барырга кыстый башладым. Гөлниса кайтам дип чәбәләнә. Ә минем җибәрәсем килми, көн буе үз янымда йөртәсем килә...

Алып киттем бит ахырда... Барган өчен чынаяк уенчыкларымны бирергә вәгъдә иттем. Минем чынаяк уенчыкларым бизәкле-бизәкле. Мин аларны малайлардан отып алган идем. Әйдә, әллә кемгә китми әле, Гөлнисага китә...

Ташлы елгада үлән билдән икән... Еланнан куркам дип, Гөлниса чәрелди башлагач, алдан үзем ерып кереп киттем.

— Әйдә минем арттан! Безелдек!

Мин салган эздән дә барырга курка. Тагын кулыннан җитәкләргә туры килде.

Умарта корты да белә кемне чагарга! Мине чакмады, Гөлнисаны чакты. Үрсәләнеп кычкырып җибәрде кызыгыз. Умартаның өзелеп калган угын тартып алдым да чаккан җирен төкерегем белән ышкыдым.

Бара-бара су очрады. Күтәреп чыгардым. Каурый! Ничек ике чиләкләп инештән су ташый икән бу каурый кисәге? Су очрый, җиләк очрамый, бака очрый, җиләк очрамый. Ә миңа җиләкнең кирәге дә шул хәтле. Минем янымда чикерткә сыйраклы Гөлниса барамы? Бара. Миңа шул җиткән.

Ташлы елгадан инде урманга да ерак калмады.

— Беткән баш беткән. Киттекме, Гөлниса, Тенеш урманына?

Гөлнисам авызын ямьшәйтеп елый ук башлады. Ике күзендә ике тамчы яшь... Өйгә кайтасым килә, ди, әни ачуланыр, ди...

— Синдә бар әни миндә юкмени? Ачуланса асып куймас әле. Киттекме, күрше?

Әйдә, мин гел алдан барам. Умарта чакканнан кеше үлми ул. Үлмәдең ич әле. Менә мин юри дә чактырам умарта кортыннан. Карап тор, менә. Чәчәккә кереп баткан умартаны тотып, кулымны чактыртып күрсәттем.

— Менә, тамчы да авыртмый!

Гөлниса күзләрен зурайтып карап торды. Мин, чыраемны да сытмыйча, тагын берсеннән күл аркамны чактырдым.

— Урманда булырга тиеш инде ул җиләкнең оясы! — дим.

Гөлниса җиләк савытын үлән арасына төшереп калдырган. Киттек килгән әз белән аны эзләргә. Таптык. Савытны үз кулыма алдым.

— Я тагын төшереп калдырырсың, кит!

Урманда ничек җиләк җыюыбызны, тузбаш елан тотуыбызны (мин тоттым, Гөлниса читтән муенын сузып карап торды) сөйләсәм, озакка китәр. Арып, ачыгып, авылга кичкырын гына кайтып кердек. Бакча башына җиткәч, аерылыштык. Гөлниса үзләре бакчасына, мин үзебезнең бакчага кердем. Алмагачлар арасыннан бер-беребезне күрә-күрә кайтып киләбез.

— Курыкма, асып куймаслар! — дип, мин Гөлнисаны һаман юатам, ә үземнең күңелдә таракан... Әләгә инде әнидән.

Мин буш кулымны селкеп кайтам, Гөлниса буш савытын селкеп кайта.

Әйтергә онытып торам икән, бакча башына кайтып җиткәч, табак төбендәге ике-өч җиләкне сытып йөннәребезгә буяган идек. Мин курка-курка гына үзебезнең өй бусагасыннан атладым да бөтенләй гөнаһсыз төс белән (гүя көн буе югалып тормаган):

— Әни, күрәсеңме минем иреннәрне, кып-кызыл! — дидем. Ничек тә сүз башларга кирәк иде ләбаса!

Аннары:

— Әни, мин җылан тоттым! Монавың хәтле! — дип, колачымны җәеп, еланның зурлыгын бер биш тапкырга арттырып күрсәттем.

— Тотармын әле мин сиңа җылан! — диде әни коры гына. — Кайда соң җыйган җиләгең? Ашап бетереп бармагансың ич?

— Бетердем, — дидем мин. — Кара иреннәремне... Кызылмы?

Гөлниса өйдәгеләр ни әйткәндер, беренче сораулары нинди булгандыр? Бик озак югалып торганнан соң сораулар булмыйча булмый инде. Мин әле сезгә бөтенесен дә әйтмәдем. Әнинең беренче соравы миңа мондый булды:

— Кырык эш кырык җирдә кырылып ятканда кайда олагып йөрден көнозын, эт көтүчесе? — Шундый булды мина беренче сорау.

Авылның мең дә бер күзе бар. Безнең киткәнне күрүчеләр булган. Зират елгасында йөргәнебезне дә күргәннәр. Ташлы елгадагысын да... Әни бик борчылмаган. Әллә ни каты эләкмәде. Әни, тавышланган булып, кулына уклау алган иде дә, мин, куркытыр өчен генә алганын күреп, качмадым. Уклау күтәреп килеп:

— Качмый да ичмаса... — дип, әни уклавын баш очымда бер-икс уйнатып алды да кире тараканнарга кимерергә куйды.

Инде күп еллар үткәч, мыек-сакал үстереп йөри башлагач, бер шулай авылга кайттым да Галиәскәр абзыйларның хәлен белергә кердем. Галиәскәр абзый инде вафат. Әнкәләре Фатыйма апа өйдә. Бик картайган. Гөлниса да шунда. Әнкәсе янына килгән чагы икән. Кая киткән өзелергә торган нәзек куллары, чикерткә сыйраклары... Алдымда тулы тәнле матур бер хатын. Олы хатын инде. Балалары җитеп килә. Сөйләшеп киттек.

— Кайттың алайса? — ди.

— Кайттым, — мин әйтәм. — Чыпчык та бит үз чытырманым дип әйтер ди, үз авылым, туган җир...

— Исеңдәме, — ди Гөлниса тәмам балкып китеп, — без синең белән бакчадагы үлән эчендә качып ятканда әллә ни хәтле тавык йомыркасы тапкан идек.

Үз чиратымда мин:

— Э синең исеңдәме? — дип тотындым. — Исеңдәме, сине шаккатырмакчы булып, мин ыштан балагын сызганып, урмандай кычыткан-лык арасына кереп киткән идем?

Исеңдәме дә исеңдәме... Сөйләшәбез, көлешәбез. Гөлниса кинәт кенә миңа әйтә куя:

— Тирестән көрәк булдың бит син, Ибраһим, — ди. (Бездә аны катырак итеп тә әйтә беләләр.)

Бу аның үзенчә мине мактап әйтүе. Дөрес әйтә ул. Иске Россияне яңа Россия сугып екмаган булса, мин көрәк буласы кеше түгел идем. Яңа Россия генә мине тирестән көрәк итте.

Кичә әнидән: «Эт көтүчесе!» дигән сүз ишеттем бит инде, аның алдында гаепле булдым. Бүген инде бу гаепне ничектер юарга кирәк. Әнинең кушкан йомышларын гел үтәп кенә торам...

— Әни, миңа тагын нинди эшләрең бар? — дип, әнидән тагын эш кушуын сорадым.

Ни гажәп, эш кушмады. — Ерак китмә, йорт тирәсендә генә айкал, кирәккәч дәшәрмен, — дип, ишек алдына чыгарып җибәрде. Ишек алдына ярагач, урамга чыгарга да ярый торгандыр дип уйладым. Урамга чыктым. Галиәскәр абзыйларның каз бәбкәләре өстендә карчыга әйләнә иде, кычкырып, аны куып җибәрдем. Мәче үтеп бара иде, аңа таш аттым. Мәчет карты очрады — аңа кычкырып сәлам бирдем. Гөлнисаны күрәсем килә, Гөлниса юк. Ары сугылдым, бире сугылдым.

Өянке башына менеп, карга ояларын тикшереп төшәргә булдым. Беләм, оялар буш, карга балалары күптән канатта, әнкәләре белән басуларда очып йөриләр. Шулай да менеп карап төшүдән ни зыян...

Соң бит мин инде күлмәк агач ботагына эләксен дә ертылсын дип менмәгән идем, э ул эләкте дә ертылды. Ертылды гынамы соң әле — яртылаш аерылып чыкты.

— Үләм инде шушы малай белән! — ди өйгә кайткач әни. — Сиңа ничек өс-баш төткәзим, көн дә генә саен ертып торгач... Чуен күлмәк кирәк сиңа, — ди...

Әнине бер дә ачуландырасым килми дә бит, гел нинди дә булса бер начарлык эшләп куям.

— Өйдә генә уйна, йөрмә урамда чабып...

Шулай диде дә әни, капчык төбенә ясмык салып, тегермәнгә менеп китте. Өйдән чыкмый гына уйнадым. Урамда Гөлниса күренмәгән булса, мин аны тәрәзә каршына чакырып китермәгән булсам, нәзек-өзек кулларыннан тартып, тәрәзәдән өй эченә кертмәгән булсам... Әйе, булсам... Э мин керттем... Гөлниса тәрәзә кысасына сыдырылган беләгенә төкерек сылады да аякларын бөкләп сәкегә утырды... Чәчләрен маңгаеннан сыпырып җибәреп, каен күмередәй кара күзләрен миңа төбәде:

— Нинди уен уйныйбыз? — диде.

Өй эчендә биш таш уйнап утырмассың бит инде. Май атлау уйнарга булдык. Сәкедәге түгәрәк тишекләргә таяк тыгып, атлый да башладык.

Каян килгән сәкедә бу тишекләр? Әни киндер тукыганда, шушы тишекләргә чөй тыгып, шул чөйләргә буй җепләрен бәйләп куя иде. Менә каян килгән сәкегә ул тишекләр.

Май атламак — жан чыкмак бит инде. Гөлниса, әнкәсеннән күрмәле: «Ай, күлбашларым! Ай, өзелеп чыга!» дигән булып, аргандай итеп атлый. Мин дә иңбашларымны тотам... Куера башлаганмы дип, пешкәкләребезне (таякларыбызны инде, билгеле) тартып чыгарып карыйбыз. Бармакларыбыз белән сыпырып, «каймак»ны ялап та куйгалыйбыз. Китерәбез инде, бик китереп уйныйбыз.

Уйный-уйный май атлаудан арыдык. Тәрәзәдән төшеп, эт борчагы җыеп ашарга тотындык.

Кичен әни, сәке астыннан нидер алмакчы булып, сәкене ачты да:

— Бетергән! Йомыркаларымны бетергән! — дип кычкырып җибәрде.

Гөлниса белән без әнинең сәке астына җыеп куйган йомыркаларын ботка иткәнбез.

Туздырды әни. Нишләргә инде миңа? Җиләккә барырга ярамый — көнозын югалып торам. Өянке башына менәргә ярамый — күлмәгемне аерып төшәм. Май атларга тагын ярамый — йомыркаларны ватам. Нишләргә генә ярый соң миңа? Сикерергә ярыймы икән? Күпер башы Хөснулла абзыйның улы Касыйм белән аларның чормасыннан сикереп уйнарга булдык. Өйләре тәбәнәк, яртылаш җиргә чумган. Йомшак булсын дип, чолан идәненә мендәр салдык. Касыйм әйтә, башлап син сикер, ди. Әйтмәсәң дә беренче сикерәм инде мин. Тоттым да сикереп төштем. Мендәр дә салган бит инде, шулай да аягым бик авыртты. Баса алмыйм, егылып-егылып китәм. Өйгә кайтсам, әни тагын туздырачак. Касыймнарда гына ятып тордым. Аягым гөбе кебек шешеп чыкты. Ертылган күлмәк итәген әле яшереп була иде, чатан аякны ничек яшерәсең! Ике атна буе аягыма баса алмадым. Баса алмауга карап, йөрмәгән икән дип уйламагыз. Икенче аяк бар ич әле минем. Яшел ташы кебек атылып, кая карама анда мин сыңар аякта чабып йөрим.

Әни ураза тота башлады. Мин кичен азан әйткәнне тыңларга мәчет катына барам. Һаман шул сыңар аяк белән тыраклап йөрим бит. Мәзиннең чалмалы ак башы манара тәрәзәсендә күренү белән, авыл өстендә «аллаһ әкбәр!» сүзе яңгырау белән, без, түбән очтан килгән бер көтү малай:

— Азан әйтә, базар кайта, әти күмәч апкайта! — дип такмаклап, өйләребезгә таба чабышабыз. Мин дә сыңар аякта сикерә-сикерә кайтып керәм дә:

— Әни, әйтте! — дип кычкырам. Әни, бисмилласын укып, авызына бер чеметем тоз каба...

Әти күмәч апкайта дигәннән, авылда чагымда миңа күмәч эләкмәде. Тик бер тапкыр... Кич булган иде инде: кояш баешында карбыз телеме төсле кып-кызыл болыт кисәге эленеп тора иде. Мин басу капкасы тирәсендә айкалам — базардан кайтучы атлы кешеләргә капка ачам. Күреп алдым, кыр юлыннан арбалы кеше килә, дугасындагы кыңгыравының чыңгыл-чыңгыл итүе миңа бик ачык ишетелә... Йөгереп бардым да басу капкасын ача башладым. Яман авыр капка... Аскы иренемне тешләп, көчәнә-көчәнә ачам. Ачып кына бетердем, үзебезнең оч малайлары тасырдашып килеп җиттеләр:

— Яп! Урыс ич, күрмисеңмени! — ди-ди, урыска капка ачарга ярамауны әйтеп, мине ачуланырга керештеләр. Ачуын ачтым, ябарга көчем житмәде. Базарчы урыс мин ачкан капкадан узышлый миңа бер сынык ап-ак күмәч тоттырды. Иптәш малайлар миңа:

— Ташла! Дуңгыз масында пешкән! — дип, күмәчемне ташлатырга азаплансалар да, мин күмәч сынығын кысып тоттым да өйгә таба сыпырттым.

Әни әйтә:

— Бисмилланы әйт тә аша, бернәрсә дә булмас, — ди. Бисмилланы әйттем дә ашадым да куйдым күмәчне... Бүгенгә хәтле берни булганы юк.

Әлегә тикле мин бер аякта гына чапсам, аягым төзәлгәч, тагы ике аякта чаба башладым. Бу малайдан беразга котылып торыйм диптер инде, әни мине, әтинең энеләренә тагып, болынга чыгарып җибәрде.

Безнең болын ерак. Идел кичәсе бар. Паром сүзен беренче шунда ишеттем. Паромның үзен беренче шунда күрдем. Урам киңлеге зур бер көймә икән. Атлар, арбалар, кешеләр кереп төялгәннән соң да, мин, шук малай, йөгереп йөрерлек урын калды әле. Әтинең энесе Миңлевәли абый миңа бармак яный:

— Суга егылырсың, сикеренеп йөрмә, — ди. Аның сүзен тыңлап торырга, минем әтинең энесе ич ул бары.

Шушы хәтле су Иделгә каян җыелган? Безнең авылның хатыннары, кызлары, барысы бергә чиләк тотып килеп, бер ай буе, юк, бер ел буе ташысалар да бу тикле суны ташып бетерә алмаслар иде. Бу суны эчеп бетерү өчен ничә мең ат кирәк булыр иде икән?

Инде паром Иделнең уртасына житте. Килгән яктагы ташлы текә яр кеп-кечкенә булып артта калды. Алда вак куаклык, яшел болын...

Менә бервакыт паромда атлар тибешә башлады: гөрс тә гөрс тибешәләр. Күрми калам дип йөгереп барсам, агайлар сикерешеп торганнар, атларга «Тпру!» дип кычкыралар, тезгеннәреннән тарталар... Бер ат чупырт итеп суга барып төшмәсенме!.. Пошкыра-пошкыра йөзгән, күзләре акайган атның су эченнән колаклары гына күренеп бара... Ишкәкчеләр иркенләп ишә алмыйлар, судагы ат комачаулый.

Ахырда куып җибәрделәр. Ат паромны узып китте дә бездән алда ярга барып чыкты. Рәхәтләнеп бер кагынды, авызын яшел үләнгә төртте... Бу атта чынлап та ат көче бар икән, тамчы да арымаган...

Миңлевәли абый арбага яткызып дилбегә белән бәйләп куйган жирдән мине чишеп җибәрде (аяк астында бик чуалгач, ул мине, мәче баласыдай күтәреп китеп, дилбегә белән аркылы-торкылы арбага бәйләп ташлаган иде). Мин күз яшьләремне сөрттем дә сикерә-сикерә паромнан чыгып киттем.

Болында мин инде уйнап йөри алмадым. Атларны эчердем. Бәрәңге

әрчедем, аш пешердем. Печән пакосларын әйләндереп киптердем. Атка атланып чүмәлә тарттырдым. Бер иманага эш житәрлек булды.

Абыйның аты бик усал, хәзерге тел белән әйтсәк, хулиган ат. Теге атны суга тибеп төшерүче шул абый аты булды бит. Тотам дигәндә һич тоттырмый, тоткач атландырмый, аяктан тешли... Минем бит инде аяк болай да имгәнгән, ат та тешли башласа, аннары кая китә ул. Юк, аякны тешләтеп тормам мин синнән.

Абыйлар ашадылар да, чалгыларын иңбашларына күтәреп, иртәнге чыкта печән чабарга киттеләр. Мин куыш янында калдым. Башлап Түгәрәк күлдән ашлык-чәйлек су алып кайттым. Бәрәңге кырдым. Атны да эчереп кайтасым бар. Шул чукынмыш усал атның янына барырга кан калтырап торам. Һаман сузам. Ут яктым. Казан астым. Суга бәрәңгене салдым. Атка чират житә бит каһәрең!

Йөгәнне тотып ат янына киттем. Икмәк катысын сузам да, баһ! баһ! дип, үземчә бик ягымлы гына итеп дәшеп карыйм. Юк. Мин якынлашканны күрүгә башын чөя дә китеп бара. Мин аның артыннан ияреп барам. Баһ! Баһ! дим, мә икмәк бирәм, тиле! дим. Куып йөри-йөри тәмам арып беттем. Атның да ачуы чыкты, минем дә... Кычкырып елыйсыларым килә. Нишләтергә соң бу разбойникны? Бик якын барсам, колакларын шомартып, өстемә килә башлый. Йөгән белән кизәнеп кенә туктатып калам. Аптырагач, аунап яткан озын таякны алдым да кизәнә-кизәнә тегенең өстенә бара башладым. Ат миңа таба борылды да, арт аякларына күтәрелеп, башын чайкый-чайкый минем өскә ташланды... Бетсәм бетәрмен, акылга утыртырмын мин сине дип, таяк белән тегенәргә сыптырырга тотындым — аякларына, муенына, кабыргаларына, кай төшенә туры килә... Атым чигенә башламасынмы! Мин, батыраеп китеп, һөҗүмгә күчтем. Атны, куып барып, гөлҗимеш чытырманлыгына кысрыкладым да, күпме кирәк, күпме кирәк! Менә сиңа разбойникка! Хулиганга! Шул көннән башлап атым май булды. Йөгәнгә үзе үк башын тыгып тора. Абый сорый, ничек няләштердең син аны? ди. Кыйнадым димим, таптым инде рәтен, дим. Атын кыйнаганны белсә, абый үземне дилбегә белән тотып ярачак...

Терлекне шунда беренче һәм соңгы тапкыр кыйнадым.

Болында бик озак торылды. Ун көнләп. Яңгырлар яуганда куышта тик утырулар бик ямансылатты. Җитмәсә, куыш эченә тач-тач тамчы тамып тора. Өйне үлеп сагына башладым. Бер тапкыр абыйлар алдында еладым да жибәрдем.

— Ни булды сиңа? — ди Миңлевәли абый.

— Әнине сагындым, — дим.

— Карагыз әле бу күсәкне, — дип абый көлә башлады. — Әнисен сагынган...

Сагынгач нишләтим. Сагынам. Хәзер инде абыйларга әйтми генә сагынам. Күнелем бик сыза башласа, атка атланам да китәм чабып... Колак төбемдә жил бөтерелеп бара... Чабылмаган үләннәр өстеннән, күлләр яныннан, печән чүмәләләре арасыннан чаба-чаба әллә кайларга, Идел буйларына тикле барып чыгам да аргы яктагы ак ташлы текә ярларга моңаеп карап торам. Шунда бит инде безнең кайтасы юлыбыз. Аннары кире борылам да, кушаякланып, тагын болынга жилдертәм. Ун көн эчендә атта чабарга мин бик каты остарып житкән идем.

Байтак еллар узганнан соң, А. К. Толстойның бер шигыренә тап булдым. Бу шигырьдә ат атланып кыңгырау чәчәкләре арасыннан чабып үтү турында языла.

Колокольчики мои,
Цветики степные,
Что глядите на меня,
Темноголубые?

. . . . . .

Я бы рад вас не топтать,
Рад промчаться мимо,
Но уздой не удержать
Бег не укротимый, —

дигән юлларны укыганда, үземнең кайчандыр болында абыйның усал атына атланып чабып йөрүләрем исемә төште. Радиодан шушы романсны ишетсәм, бүген дә шул чаклар бөтен матурлыгы белән күз алдыма килә, кыңгырау чәчәкләре арасында атта җилдереп йөрүче кеше мин үземдер кебек тоела...

Болыннан кайткач, әни миңа әйтте:

— Улым, син анда чыгып әйбәт иттең, абыйларың кышка бер йөк печән бирәчәкләр, — диде.

Минем күңел сикереп куйды: эшкә ярый башладым бит! Әнигә болын хәлләрен сөйләгәндә, и мактадым, и мактандым! Әни көлә.

— Ялганлыйсыңдыр инде бераз, — ди.

Ялганлыйм, үзем дә сизәм, — ялганлыйм, ләкин ялганлау ниятe белән ялганламыйм. Мин бит булганны арттырып кына сөйлим... Идел аркылы кичтекме? Кичтек. Ак яллы дулкыннар көймә өстенә, минем баш очыма сикерешеп менделәрме? Юк, менмәделәр. Ә мин менделәр дип сөйлим. Шулай күңеллерәк, шулай кызыграк... Каты җил дә юк иде, ә мин, көймә Идел уртасына җиткәч, бик каты җил чыгып, паромны агызып китә язды, ишкәкчеләр ишә-ишә тәмам хәлдән тайдылар, агайлар белгән догаларын укырга тотындылар дип, чамасыз арттырып, гажәп куертып сөйлим. Ә үзем бер дә курыкмаган булып чыгам. Тагын шунысы да гажәп: әнигә сөйләгәннәр барысы да булган, барысы да чын кебек тоела башлады хәзер минем үземә дә... Күз алдымда таудай дулкыннар сикерешә, агайлар тезләнешеп дога кылалар: коткара күр, ходаем!

Икенче көнне тагын да арттырыбрак сөйләдем: янәсе, болындагы бүленеп калган суда балык шундый күп җыелган иде, су өстендә елтыр-елтыр май тәнкәләре йөзеп йөри иде. Ал кашык та ашый башла, майлы балык шулпасы синең алдыңда...

Соңыннан, балалар йортында яшәгәндә, минем коточкыч кабартып сөйләвемне тыңлагач:

— Син фантазер! — ди торганнар иде.

Миңа инде ун яшь тулды. Уйнап йөрүләр бетте: мин хәзер эш кешесенә әйләнеп барам. Икенче елны язын Җәлил абзыйга тырма тырмаларга ялландым.

Әйткән идем бугай, без Җәлил абзыйлар белән элек-электән йөрешәбез. Дөресрәге, без аларга йөрибез: катыгын сорыйбыз, мунчаларына ягабыз, иләк-чиләккә дә мине әни аларга кертә... Җәлил абзыйның җиткән кызы бар. Фәгыйлә. Фәгыйлә апа миңа чия ашата, кысып-кысып кочаклый, битемнән үбә. Мин аның үбүен бер дә яратмыйм, үпкәч үк жиңем белән сөртеп ташлыйм, йомшак кочагыннан тизрәк ычкынырга тырышам. Менә шушы Фәгыйлә апаның әтисе Җәлил абзыйга мин тырма тырмалашырга ялландым. Әни әйтә, тамагың гына булса да алар өстеннән үтәр, ди.

Җәлил абый үзе сүз сөймәс кеше. Агайлар белән бүрәнә өстендә утырганда да, ул сүзгә катышмый, тыңлап кына тора. Бик көлке жирдә генә, күп булса, шул тамагын кырып куйгалый. Авылда аны астыртын кеше итеп саныйлар. Кушаматы да Мыштым Җәлил. Икенче кушаматы Юкә камытбау Җәлил. Аның тырма тырмаларлык малае юк, гел кызлар гына...

Яшь айгыр, биягүрсә дөньяны яңгыратып кешнәп җибәрә торган гадәтле дуамал айгыр — шул айгырны Җәлил абзый миңа тоттырды. Ә ул мине бөтенләй санга сукмый. Күршедә сукалый торган биягүрсәгә

күзләрен челәйтеп, кешнәп торып жибәрә дә китә ашкынып, китә очынып, башын чөеп, башын чайкап... Тырма сикеренә, тешләре тигән жиргә тия, тимәгән жиргә тими кала. Мин дилбегәне кулларыма чорнап тоткан, йөгерә-йөгерә көчкә генә айгыр артыннан өлгерәм. Инде һич жинә алмагач, тырма өстенә сикереп менеп басам. Айгырга минем авырлык нәрсә ул... Тырма үрле-кырлы сикеренә башлагач, куркып, мин кире сикереп төшәм дә аякларымны тери-тери тырма яныннан йөгерә башлыйм.

Жәлил абзый сука тоткаларына ябышып, бөкрәеп, үзенең сукалавын белә, минем якка күз дә төшерми.

Сизми дә калдым, айгырым урманны яңгыратып (жиребез урман буенда иде), бик дәртле, бик моңлы итеп кешнәп торып жибәрде дә китте чабып, китте уйнаклап... Тырма артыннан буран уйнап бара... Мин, гәүдәмне артка ташлап, киерелеп, бөтен көчкә айгырның авызлыгын тартам. Инде өстерәлеп диярлек барам, чөнки аякларымны атларга өлгерә алмыйм. Жир башына барып життек, жир башын узып киттек, әллә кемнәр жиренә барып кердек... Тузан оча, кантар оча... Тырма һавага сикерә... Мин, дилбегәне кулдан ычкындырмаска тырышып, елый-елый тырма артыннан чабам.

Булмады. Мәтәлеп жир өстенә егылып калдым. Китте айгыр. Чапты айгыр. Юкә баулар өзелеп калды, тырма капланып калды. Жәлил абзый, сукасын ташлап, айгыр артыннан чапты. Кешеләр аңа ярдәмгә ташландылар. Айгырны урманга кысрыклап тоттылар.

Авыл агайлары Жәлил абыйны сүгәләр: бала кулына шундый айгырны тоттыргансың, диләр. Жәлил абзагыз бер сүз дәшми, тамагын гына кыра...

Икенче көнне айгырны сукага жигеп, карт бияне тырмага жиктек. Бу юлы инде мин түгел, Жәлил абзый үзе мәтәлеп калды. Айгыр, кырын егылган суканы өстерәп, китте басу буйлап чабып...

Көз көне Жәлил абый мине тагын эшкә алды. Эшкә алды дип бик зур итеп әйтеп ташладым. Эшкә түгел — алма сатышырга.

Безнең авылда бакчасыз кеше юк иде. Жәй көннәрендә барлык бакчаларда кызарып алма пешә. Мулла тыкрыгында ике як бакчаның ботаклары килеп кушылу сәбәпле, тыкрыкка һәрвакыт алма коела... Малайлар аларны жыеп ашыйлар (һәр йортның үз бакчасы булса да, кеше алмасы тәмлерәк). Көз көннәрендә авылга алма байлары киләләр. Бакчасы белән сатып алып, үз каравылчыларын куялар да хужаны бакчага кертмиләр.

Жәлил абзый үзе акча танымый. Алма сатканда алданудан куркып, ул мине иәртеп барырга булды, чөнки мин акча таныйм. Тәнкә башына бер тиен — Жәлил абзый миңа шундый хак куйды. Бер тәнкәлек алма саткан саен, бер тиен минем кесәгә тамачак. Алманың бәясе кадак башына өч тиен, биш тиен. Биш тиеннән сатканда, миңа бер тиен тамсын өчен, егерме кадак сатарга кирәк.

Юк, мин акча өчен ялланмадым. Авылда Равил абыйның бәрәнге бакчасында чүп үләне утап та, мин көненә 15—20 тиен эшли алам. Шул ук акчаны тирестән кирпеч сугып та ала алам. Ә сезнең тирестән кирпеч сукканыгыз бармы? Башта су сибә-сибә тиресне аттан таптаталар. Килеп чыга тирес боткасы. Аннары малайлар (анысы без инде) тактадан куш кирпеч формасында ясаган нәрсәгә төя-төя шушы ботканы тутыралар да жиргә илтеп каплыйлар. Кирпеч кибә. Ягуга китә... Билгә алъяпкыч бәйләп, терсәк тиңентен шушы тирес боткасына буялып, мин шундый кирпечләрне үз гомеремдә бик күп суктым. Йөзе бер тиен... Кирәксә сугып бирәм!

Ат Жәлил абзыйныкы, арба Жәлил абзыйныкы, ашыйм дисәм, алма да Жәлил абзыйныкы... Авыз минеке. Күзләр дә, колаклар да минеке... Мин дөнья күрергә чыктым, акча эшләргә чыкмадым. Минем бит әле

авылдан ары беркайда да булганым юк. Әнә теге жир белән күк тоташкан урынны күрәсезме? Шуннан ары китсәң дөнья бармы икән? Минем әле шул күк белән жирне тоташтырган зәңгәр сызыкка барып житәсем килә... Барып житеп, билгә таянып, карап торасым килә...

Җәлил абый әйтә:

— Син алманың кортлысын гына сайлап алып аша, — ди...

Мин зур ак алманы кире куям да, кортлы кызыл алма алып, ат койрыгына карап ашыйм. Кортлы алма тәмлерәк тә була ул әле, беләсегез килсә...

Кич белән зур яшел мәчетле бер авылда кунарга туктаган чакта, без инде кырык кадактан артык алманы саткан идек. Минем кесәмә ике тиен акча тамган иде.

Икенче көнне без атны жиктек тә чыгып киттек. Авылдан авылга йөрибез. Басу капкасыннан килеп керүгә Җәлил абый:

— Алма сатам, алма! — дип кычкырып жибәрә...

Башлап торып малайлар йөгерешеп килеп житәләр... Аннары олылар ашыкмый гына, бик исләре китми генә кабык әржәле, малайлы, алмалы арба катына якынаялар. Җәлил абзый үлчәп сатып тора, акчаны мин алам:

— Ун тиен, унбиш тиен, — дип, акчаларны танып, Җәлил абзыйга биреп торам.

Бер авылда без бәлагә тап булдык. Кунарга кергән жирдә безнең әржәдәге алмабызны сыер ашады. Дөрес, сыердан калган алмаларны да без кадагы өчәр тиеннән байтак саттык, ләкин сыер ашаган хәтлесен сатып булмады шул инде. Сыер дигәнең алманы бик ярата икән, әржәнең төбендә генә калдырган иде. Минем кесәгә әллә ничә тиен зыян килде.

Жир белән күкне тоташтырган зәңгәр сызыкка мин нихәтле генә барып житәргә тырышмыйм, барып житә алмыйча кире борылдык. Инде соңыннан, үсеп сакал-мыек житкергәч, Ватан сугышы вакытында мин Варшаваларны, Берлиннарны узып киттем. Китсәм киттем, ә күкне жиргә тоташтырган әлеге серле сызыкны барыбер куып житә алмадым.

Әлегә... Әлегә арбада селкенә-селкенә без кайтып барабыз. Мин кайтам. Минем күзләр, колаклар кайта. Җәлил абзагызның сары сакалы кайта. Аннары минем кесәмдә... туктагыз әле, санап багыйм, минем кесәмдә... биш тиен акча кайта.

Биш тиен акчаны алып кайтып тоттыргач, әни күңелсез генә көлеп жибәрде.

— Йөрисең шунда көн уздырып, көл туздырып, — диде, бакырларны мич сырына куйды да, ашарга утырырга кушты. Ярмалы кайнар бәрәңге бик тәмле иде. Алмадан соң бигрәк тә...

Авылдагы революция елларын язмыйм. «Онытылмас еллар» романында ул заман бик нечкәләп тасвир ителгән. Кабатлау кирәксез хезмәт.

Тик шулай да әйтеп үтим. Без кызыллар, аклар булып сугыша башладык. Зират елгасыннан таш жыябыз да чынлап торып сугышабыз. Канга буялып кайткан чакларыбыз була. Гөлниса тәрәзәсе каршыннан узган чагымда, мин канлы яраларымны юри күрсәтеп үтәм: янәсе, аның күршесе канга батканчы кызыллар ягыннан сугышкан...

Сатлыган авылы янына аэроплан егылып төшкәнне дә язмыйм. Аны кararга дип, көтүебез белән шунда таба чабышуыбызны да язмыйм. Безнең авыл аркылы кызыл гаскәр узды, кесә тутырып патрон урлап калдык. Күмер кыскычы белән тотып, учак утында пуля эреткән чакта аягыма кайнар кургашын тамды — анысын да язмыйм. Алпавыт урманын кисеп, көне-төне бүрәнә ташыганны да язмыйм. Мин ташымадым, әлбәттә. Минем атым юк. Галиәскәр абзыйлар ташыды. Җәлил абзый ташыды. (Юкә баулары ничек чыдады икән!)

Революциянең мин капкан беренче жимеше шул булды — бездән

налог түләтми башладылар. Юкса налог түли алмаган өчен дип, староста самоварны, түшәкне алып чыга торган иде дә, без чәйне казанда кайнатып, йокыны каты сәкедә йоклый идек. Икенче жимеш — укыган өчен акча алудан туктадылар. Мин хәзер үзебезнең авылдагы русча-татарча укыта торган мәктәпкә йөрим. Сидеть белән седеть сүзләрен аера алмыйм. Пыль белән пыл сүзен дөрес итеп әйтеп бирә алмыйм. Воз, на воз, навоз сүзләрен бутыйм, кайсы йөк, кайсы тирес — белмим. Язын гадәтемчә сыерчыкларга оя куям. Җәйләрен ашка тагын балтырган жыям.

Әни белән без бөлүнең соңгы чигенә життек бугай инде. Терлектуардан карап торган бер чуар тавыгыбыз гына калды. Арышны яшел килеш урып, яшел арыштан яшел ботка пешереп ашыйбыз. Нәкъ менә шушы көннәрдә инде миңа бераз соранып йөрергә дә туры килде. Эттән куркуым шул заманнан калган инде минем. Теләнчене беренче башлап эт каршылый бит. Эт тавышын ишеткәч кенә, хужа башын тәрәзәгә тыга. Сакаллы баш булса өмет итмә инде, яулык бәйләгән баш булса, өмет бар. Сакаллылар хәерчене борып чыгарырга яратучан: «Гаеп итмә, наным, үзебезнең дә такы-токы». Менә шул вакытта инде этнең иң усал чагы. Чатка тикле артыңнан ырылдап килә. Хатын-кыз кызганучан, буш кул белән борып чыгармый.

Соранып кына тамак туйдырып булмый инде. Этинең әнеләре минем теләнеп йөрүемнән хурландылар булса кирәк. Әни янына килеп, нидер сөйләшеп киттеләр. «Бар, син уйна», дип, мине өйдән чыгарып жибәреп сөйләштеләр. Безгә бераз ашарга бирергә жыеналар, ахры.

Мин шулай дип уйлаган идем. Әнине кияүгә китәргә димлиләр булып чыкты. Мин моны, әлбәттә, соңыннан белдем.

Әнинең кышлый эрләп куйган жепләре булган икән. Ул аларны кар өстенә жәеп агарткан булган. Ә менә хәзер, миңа күлмәк-ыштан тегеп калдырырга дип, киндер сугарга утырды. Әйтәм бит, мин әле берни сизмим, киндер сугуга да игътибар итмим. Ел да эшләнә торган эш.

Әни мине дә эшкә утыртты. Мин көре аркылы әнигә жеп биреп торам. Уенга чыгып чабасым бик килә, юк, ярамый. Иелеп (гел иелеп!), әнинең сузылган бармакларына жеп бирәм. Жилкәм өзелеп төшәрлек булып сызлый. Безнең өй турысында малайлар шаулашып уйныйлар. Ә мин жеп бирәм. Безнең өй турысыннан малайлар Олы күлгә чабалар. Ә мин һаман жеп бирәм. Сезнең көн буе иелеп жеп биргәнегез юктыр, шуңа күрә жилкә сызлавының «тәмен» белмисез.

Әни янына Жәлил абзый хатыны кереп, ни турындадыр сүз чыгара гына башлаган иде, әни шундук аңа:

— Тешеңне бик агартма! — дип әйтеп куйды.

Минем алда сөйләшергә ярамый торган сүз икән дип уйладым. Шулай да бернәрсә дә сизмим әле.

Беркөнне әни өйдән чыгып китте дә юк булды. Инде караңгы да төште. Өйгә керергә куркам — почмакларда әллә кем посып тора кебек. Аннары өйдә бичуралар, пәриләр дә бар бит әле. Революция алпавытны качырса да, бичураларны качыра алмады. Әни кайтканчы ишек алдында гына йөреп торырга булдым. Менә бакча ягында аяк тавышы ишетелде.

— Әни!

Бакча капкасына ташландым. Кая барганын әйтми. Бер сүз сөйләшмичә йокларга яттык. Инде соңыннан гына белдем, ул кичне әни этинең әнеләрендә утырган булган. Күнелем сыза! Әнинең әйткәне бар:

— «Сүз тыңламыйча уйнап кына йөрсәң, ташладым киттем булыр үзеңне!»

Әллә китәргә йөриме? Шушы көннән башлап, мин әнинең һәр адымын тикшереп кенә тора башладым. Бала күнеле сизә икән. Ничек кенә яшерергә тырышса да, сиздем: әни китәргә жыена... Әти үлгәннән

соң ин яраткан кешем әни булганга, әнисез тормышны күз алдыма китерә алмаганга, мин бакчага яшеренеп елый башладым. Йөрәгем көнләр буе сызлый. Йоклаган чагымда да йөрәгем сызлауга уянып китәм.

Менә әни яңа күлмәк тегеп бирде. Кидергәндә:

— Яңадан-яңаны киергә насыйп булсын! — дигән була. Ташлап киткәч, мин моннан ары ничек яңадан-яңаны кия алам ди инде! Күзләремне мөлдерәтеп әнигә карыйм. Чыраеннан берни аңлап булмый.

Июнь урталары идеме икән, иртүк әни миңа үзебезнең бердәнбер чуар тавыгыбызны тотарга кушты. Куып йөри-йөри тавыкны мин тәмам әлсерәттем дә абзар почмагына кысрыклап тоттым. Аш пешә... Ташлап китмәсен дип, мин әнинең барлык йомышына атлыгып торам. Каршы бер сүз дә әйтмим. Күзем гел әнидә генә... Юк, әни соңгы көннәрдә тынычланды. Ләкин дөбердәтеп йомырка сала торган актык тавыгыбызны ник суйдырды соң әле ул?

Ишек алдыбызга арбалы ат килеп керде. Арбага ак сакаллы бабай утырган. Күз күрмәгән кем соң бу? Әтинең бер энесе бабай белән янәшә... Менә әни йөгереп килеп чыкты. Шушы ак сакаллы бабайга әнине кияүгә бирәләрдер дә, бабай әнине алып китәргә килгәндер дип һич башыма китермим бит әле. Белгәч, кычкырып елап жибәрдем, әнинең кулына барып ябыштым. Китмә! дим, үкереп елыйм. Берсе дә минем елавыма игътибар итми, гүя мин бөтенләй юк. Бабай өйгә керде. Утырышып дога кылдылар. Миңа да кылырга кушалар. Мин һаман елыйм.

— Әниеңне бәхетсез итәсең, елама! — ди миңа әтинең энесе Миңлевәли абый. Утыз сигез яшьтә алтмыштан узган картка кияүгә чык, шуннан да зуррак тагын нинди бәхетсезлек булырга мөмкин! Бусын инде мин бүгенге акыл белән әйтәм. Әнигә асылындым, берәүгә дә бирмим, дим, елыйм да елым. Әни бит минеке!

Колагыма ягылып калган: әтинең энеләре, бабай инде карт, озак яшәмәс дип, мине юатырга азапландылар. Әнине дә, күрәсең, шулай дип юатканнардыр. Янәсе, бабай үлә дә малы безгә кала. Ачлык елны чынлап та башлап бабай үлгән. Яклаучысыз калган минем әнигә бабайның олы яшьләрдәге улы ашарына бирми башлагач (дип сөйләделәр миңа), әни, күрәсең, теләнергә чыгыпмы, әллә туган авылы Данышка барыпмы, кышкы буранда адашып катып үлгән...

Бу инде соңрак, егерме беренче елгы ачлыкта булган хәл. Әлегә бабай безнең өйдә утыра. Әни кабаланып аш урыны әзерләп йөри. Бабай, ашап тормабыз ахры, ди башлады. Баласы, әнкәсенең муенына асылынып, елап торганда нинди ашап утыру инде ул. Әйберләрне арбага төйи башладылар. Аннары әни:

— Ягез, бер дога! — дип, йөзлеккә килеп сөялде дә үзе дә үксеп елап жибәрде. Бабай кулларын күтәреп, битен сыпырды да урынынан кузгалды. Мин артларыннан ишек алдына йөгереп чыктым. Арбага барып ябыштым. Мине арбага утыртмыйлар. Мине арбадан куалар. Кычкырып елыйм. Арбага әни янына менәргә тырышам... Миңлевәли абый мине чытырдап ябышкан жиремнән күтәрып ала да, ычкындырмыйча тотып тора.

Утырыштылар да капкадан чыгып киттеләр. Мин дә урамга йөгереп чыктым. Әни утырган арба артыннан барам. Әни борылып карады, шушы гына көткән кебек, мин арбага таба ташландым. Бабай атка сукты. Ат чаба, мин йөгерәм. Ат чаба, мин йөгерәм. Күпергә тикле йөгердем, артык йөгерә алмадым. Туктадым. Китеп барган арба артыннан шашып карап торам...

Ул төнне минем белән Гөлниса кунды. Әтинең энеләре мине үзләренә алып китмәкчеләр иде, бармадым. Гөлниса минем әнинең киткәнен читән ярыгыннан карап торган, минем елаганны да күргән, мин тамчы да күз яшьләремнән оялмыйм. Әнисе шулай китеп барса, Гөлниса үзе

еламас идемени! Олылар кебек, ул минем аркамнан сыйпый, башымнан сыйпый. Ашарга өйләреннән икмәк алып керде. Минем бит инде чын икмәк ашамаганыма ни гомер... Ашаганым гел яшел арыш боткасы...

Икенче көнне уяным китсәм, янымда Гөлниса юк. Ул инде торып чыгып киткән. Мин ялгыз. Бу дөньяда мин япа-ялгыз калдым бит инде. Әти үлгән чагында: «Минем каберемә баргала», дигән иде. Бүген әти каберенә барып кайтырмын... Күптән барганым юк. Этине онытканмын.

Мәчебез аягыма сырпалана... Бакчага алмагачлар янына чыгам. Кайчандыр әти яраткан алмагач төбенә килеп егылам. Битем белән үләнгә капланам да сулкылдый башлыйм. Бөтен күңелем белән мин әти янында... Бераз тынычланам... Кемдер мине дәшә... Исемем белән эндәшә. Колагыма гына ишетеләдер дип уйлыйм. Гөлнисаның әнисе Фатыйма нәнәй икән.

— Әйдә безгә, ди, чәй, эчәрсең, ди.

Гөлниса да аның янында кашын җыерып басып тора... Мин алмагач төбеннән көчкә кузгалам.

Минем икенче як күршем дә бар бит әле — анысы Таифә нәнәй. Әни барда ул безгә гел кереп йөри торган иде. Керә дә елый. Аның бердәнбер улы Фәйзерахман абый сугыштан кайтмады. Күзләрен башындагы яулык очы белән сөртә-сөртә:

— И, наным, — ди торган иде Таифә нәнәй миңа, — күз яшьләрем коргаксыды инде елый-елый, рәхәтләнеп елый да алмыйм хәзер...

Мин аны кызгана идем. Кызгана торгач, улына атап бәет чыгардым. Үзем белгән авыл җырларыннан оештырып, Фәйзерахман абыйның исемен китереп кушып, Таифә нәнәйнең үз исемен дә кертеп, Фәйзерахман абыйны бик батыр кеше итеп чыгарып язган идем мин ул бәетне. Таифә нәнәй бәетне бик яраткан иде, кызарып беткән күзләрен сөртә-сөртә тыңлаган иде. Унбиш тиен акча да биргән иде. Әдәби хезмәтем өчен беренче гонорарны мин, шулай итеп, Таифә нәнәй кулыннан алган идем.

Таифә нәнәй әнине озатырга керде. Ул да мине, үз өйләренә чакырып, чәйләр эчереп чыгарды.

Казанда тавык ашы барлыгы кайгы белән онытылган. Өченчеме көн дигәндә казаннан тәмсез ис килә башлагач, Гөлниса белән ачып карасак, бер казан аш әрәм булган... Нинди аш бит әле, тавык ашы...

Бер көнне әтинең энесе төште. Тәрәзәләрне сәке такталары белән кадаклады да мине үзе белән алып китте. Артка борылып карадым: тәрәзәләре кадакланган, өебез сукыр кеше шикелле...

Малайлыгым сынды. Көлә белмәс, уйный белмәс кешегә әйләндем. Инде соңрак сынган урын ялганса да, сынган күңел сынган күңел була икән инде ул. Холкым ук үзгәрде: сабырландым, олыгайдым. Элекке шикелле, чабып, сикереп йөрмәс булдым. Башны түбән салып, әкрен генә йөрим. Каршыма очраган кешеләр хәлемне сорашалар. Кайсылары башымнан сыйпый, киңәшләр бирә...

Олыгайгач аңладым: әни башкача итә алмаган. Этинең энеләренә салынып гомер яшәп булмый, үзе генә хуҗалыкны алып бара алмый, ә мин әле бик кечкенә... Этинең: балаларны калкытканчы кияүгә чыкмый тор, дигән сүзен тыңлап, ул болай да инде берничә ел ялгыз башы тырышып карады, ләкин еллар авыр иде, атсыз, сыерсыз, ярдәмчесез хатын-кыз нишли алсын! Барып егылырга колхоз юк бит ул заманда...

Шулай итеп мин абыйларда тора башладым. Көн саен диярлек үзебезнең өйгә төшәм. Баштарак мәчебез мине таный, миңа иркәләнә иде, соңрак мине күргәч кача башлады. Мәче дә хәзер мине ташлады. Күңел талана... Ятимлеккә бик кыенлык белән генәияләштем.

Абыйның өлкән кызы миңа шакмак күз дигән кушамат бирде. Шайтандай арык малайның, бигрәк тә кеше кулында яши торган үксез

малайның күзләре шакмак, үзе жен булып күренүе бер дә гажәп түгел. Ә менә «күп ашый!» дигән сүзләренә аптырыйм. Мин бераудан дә артык ашамыйм кебек. Сүз дә ишеттереп торгач, ипи сыныгына куркакурка гына сузылам, табыннан туяр-туймас кузгалам. Ашамый гына яшәргә мөмкин булса, бер дә ашамас идем дә бит, ашыйсым килеп аптырата шул... Аннары бит мин эшлим. Эшләгән кешенең ашыйсы килми булмый ич инде.

Бер тапкыр абый мине ишек алдына дәшеп чыгарды да:

— Мә, жиңгәчәңә күрсәтми генә ашап жибәр, — дип, пешкән йомырка бирде. Мин, абзарга кереп, йомырканы ялт иттереп ашап куйдым. Жиңгәчи минем ашаганны яратмыймы икәнни? Ә бит ул миңа: «Наным» дип кенә эндәшә, ашыйсың килгән чакта кер дә ипи кисеп алып аша, ди. Аңламассың: боларның кайсы миннән ашау кызгана торгандыр? Әллә чынлап та үзем күбрәк ашап ташлыйммы икән? Алар да бай тормыйлар бит, икмәкләре яңага әллә житә, әллә юк. Абый шулай дибрәк сөйләнеп торды.

Приютка илтәбез, диләр. Анда, янәсе, бик әйбәт икән. Әниемнән аерылдым, инде туган авылымнан да аерылам. Арышны урып бетергәч, кулыма бер бөтен икмәк тоттырдылар да, Хафиз дигән олырак бер малай белән Тәтешкә приютка жибәрделәр. Хафиз шәһәрдә укырга керәчәк, мин — приютка... Соңыннан Хафиз үзе дә балалар йортына эләгеп, мин аның белән бик дуслаштым. Хафизсыз бер минут тора алмый башладым. Ул бит үзебезнең авыл валчыгы. Хафизны бүтән малайлардан көнләшә идем. Бу әле соңрак, хәзергә мин — приютка, ул — укырга...

Приют дигәннәре миңа бер дә генә ошамады. Рус малайлары башымдагы кәләпүшемне алып атып бәрәләр. Йөгереп барып алам да яңадан киеп куям. Тегеләр тагын тотып аталар. Сугышырга куркам: алар күп, алар көчле... Коры идәндә өстәл астында йоклыйм, минем бүтән урыным юк. Кием дә бирмиләр. Ашаганым әчегән кәбестә, гомер ашап караган нәрсәм түгел. Малайлар төнге йомышлары белән ишек алдына чыгып тормыйлар, баскыч алдына гына туктыйлар. Ә мин авылда сасыга ияләшмәгән. Кичен бүлмәләрдә ут булмый. Караңгыда олы малайлар тотып «масло» бирәләр, ягъни баш бармаклары белән чәчемне каршыга сыдыралар. Авыртуын әллә ни авыртмый, ләкин бик хурланам...

Юк, мин мондый жирдә яши алмыйм. Яши алган яшәсен, мин качарга ниятләдем. Өстәл аслары белән әчегән кәбестә ашлары үзләренә булсын. Иртән кухняга кереп, бер телем икмәк кисеп алдым. (Авылдан абыйлар биреп жибәргән икмәкне кухаркага кертеп куйган идем.) Бөтенләй алсам, качарга жыенганны сизәрләр дип курыктым, гүя мин качканга кемнең дә булса исе китә. Икмәкне ыштан кесәсенә тыктым да койма аркылы сикердем (капкадан чыгып качу — качу буламыни ул!).

Кырык чакрым жирне бер елап, бер жырлап, йөгерә-йөгерә кайттым. Иртән чыккан кеше, көндез мин инде авылда идем. Шул арада авыл бик сагындырган. Үз авылыңның читәнгә кунган чыпчыкларына, тал ботагында тибрәнгән каргаларына хәтле күңелгә якын. Абыйларга ялганладым: янәсе, мине кайтарып жибәрделәр. Ышанмаганнардыр, әлбәттә. Ышану алар эше, ялганлау минем эш...

Икенче көнне иртән әни янына барып кайтырга ниятләдем. Салтык авылы безнең авылга ерак түгел — минем әни Салтыкта бит инде.

Әни аркамнан какты, ике кулбашымнан тотып, күзләремә бик озак карап торды. Бабай каршында күз яше күрсәтмәде. Мин дә тешемне кысып чыдадым.

Чәй эчкәндәй иттек. Аннары бакчага чыгып, сөйләшми генә әни белән басып тордык.

— Тары урырга барасым бар, — дип, әни озакламый җыена башлады. Безнең юллар бер якка икән. Әни иңбашына урагын салды. Без киттек.

Юлда әни белән ни сөйләшкәнбез — хәтерләмим. Тик шунысы хәтердә:

— Әни,— дидем мин аңарга,— тарыны син ялгыз башың гына урасыңмыни?

— Бабаң карт, ура алмый, улының уракка йөрисе килми, урак хатын-кыз эше дип әйтә, — диде миңа әни.

Әни белән минем шушы актыккы күрешүем, актыккы сөйләшүем булды. Әнине артык күрә алмадым. Авылны чыккач, әни үз юлы белән китте, мин — үз юлым белән. Әле дә күз алдымда: иңбашына урагын салган, беләкләрендә ак җинсә... Китте әкрен генә тары җиренә таба... Бабай йортында да ул бәхет таба алмаган икән. Хезмәтче булып кына йөри.

Бәрәңгеләр алып бетергәнче авылда тордым. Абыйларга бәрәңгеләрне алыштым, бүтән кыр эшләрендә булыштым. Аннары бер көнне абый атын җикте, арбасына тимер сәнәк салды (бүре очраса-нисә дигән була. Ул заманда бүреләрнең ике аяклысы да очраштыргалый иде). Мине яңадан Тәтешкә балалар йортына илтеп ташлады.

Шушы урында туктап торып, үземнең беренче ботинкам турында языймсана. Миңа ботинка бирделәр! Әле нинди ботинка! Асты күн (һәрхәлдә, мин күн дип уйлыйм). Өсте яшел постау (хәзерге тел белән әйтсәк, яшел сукно була инде). Минем чабатадан узмаган аягымда (анда да кыш көне генә, язын-көзен ялан аяк!), әйе, минем туйганчы чабата да күрмәгән аягымда күн ботинка! И, кадерләп кидем дә соң мин ул ботинканы! Ул заманнан бирле минем аякта нинди генә ботинкалар булмагандыр (мин хәтта төймәле хатын-кыз ботинкасы да киеп йөрдем, бик яратып кидем), барысы да онытылган, ә өсте яшел постау ботинкам, җан кисәгем, һаман да күз алдымда...

Аннары тагын шуны әйтәсе бар икән әле: ботинка минем аякта гына бит, аннары Анатолий Браун исемле малайда бар. Чөнки без икәү шәһәр мәктәбенә йөреп укыйбыз. Бөтен балалар йортыннан йөреп укучы без икәү генә... Анатолий миннән зуррак. Ул кечкенә яшьтән үк приюттта үскән. Аны «койма яныннан табылган малай» дип котырталар. Янәсе, бәби чагында койма янына ташлап киткән булганнар. Ул инде зур, укый. Шулай да кайвакыт минем белән сөйләшә. Сөйләшүе шул, миннән үзенең исемен әйттереп карый:

— Ну-ка, «Толя!» дип әйтеп бак, — ди. Мин, иреннәремне очлайтып, «Түлә» дигәч, кычкырып көлеп җибәрә. Аның күзләре зәңгәр, алгы тешләре сырлы-сырлы иде — шул күңелдә калган. Озакламый мин аның исемен дөрес итеп әйтә башладым бит әй!

— Молодец! — диде бу миңа, мактады.

Ул буяу белән яхшы гына рәсем төшерә иде. Минем сызды-бызды рәсемнәремне тикшереп, киңәш бирә иде.

Менә шулай. Толя белән икебездә генә ботинка. Аннары арты ерык кара шинель дә бездә генә. Ул кара шинель миннән күргән кадерне бераудан дә күрмәгәндер. Ыспайлап, сыйпап кына тотам. Ә ботинкамны, ул чактагы Тәтешнең пычрагын ярып мәктәптән кайткач, юып, әйбәтләп сөртеп куям. Ул ботинка, мескен, асты каты кәгазь булганга түгел, ә мин үзлексез юып торганга шулай тиз тузды булса кирәк.

Кышын киез итек бирделәр. Шундый зур, ике аягым белән керсәм дә, тагын бер аяклык урын калачак. Аның каравы искитмәле җылы! Кислота белән генә катырып куйган итек түгел инде, чын итек. Янгын каланчасына кызыл әләм чыгарып элгән көннәрдә дә (бик суык көн), мәктәпкә бер дә туңмыйча барып җитәм.

Минем балалар йортындагы тормышым әнә шулай башланды. Озак-

ламый зәңгәргә буялган зур йорт минем өчен төп йортка әйләнеп китте. Эти дә, әни дә шунда... Авылны әкренләп сагынмый башладым.

Студент булып Казанда укып йөргән чакларда каникулга авылга кайткач, абый миңа әйтә иде:

— Теге вакытта авылдан приютка китү ансат булмагандыр, аның каравы хәзер син әнә нинди... Өс-башың гына ни тора... Авылдан китмәсәң, минем кебек надан мужик булып калган булыр идең...

Аның миңа болай дип әйтүендә акланырга тырышу сизелә иде: әнидән соң ике ай да узмады, мине приютка илтеп бирде бит.

Приютта мин тиф белән авырдым. Сәмыйк исемле малай белән бер караватта ятып авырдык. Сәмыйк саташып урыныннан сикереп тора иде. Андый чакта мин Сәмыйктан бик курка идем. Күзләре тиле кешенеке төсле була иде Сәмыйкның.

Мин инде терелеп киләм. Бер көнне иртән уяндым да карыйм. Сәмыйк, күзләрен яртылаш кына ачып, мин курыксын дип, суламыйча ята. Мин чынлап та шүрли калдым.

— Шаярма, Сәмыйк! — дип, тегенәргә терсәгем белән берне кададым. Сәмыйкның авызы ачылып, яге салынып төште... Мин караваттан мәтәлә-кадала идәнгә егылдым. Сәмыйкны озакламый алып чыгып киттеләр. Карават шуннан соң гел буш калды. Мин идәндә генә йокладым, карават яшына барырга курыктым.

Балалар йортына килгән чагымда, мин русча берничә сүз белә идем. Шулар арасында «яблоко» сүзе. Мин аны «яулык» сүзенә охшатып отып калган идем. Приютта «гололобый татарин», сүзен, «свинью ашал, ухо куда девал» кебек сүзләрне һәм бер-ике сүгенү сүзе оттым. Бу унтугызынчы ел. Егерменче ел кышлый мин инде русча китаплар укый башладым. Э егерме беренче елда, Идел буендагы ачлыктан качып, приют Белоруссиягә барып чыккач, андагы поляк, яһүд, белорус малайлары һәм кызлары белән бергә рус мәктәбендә укып йөрдем. Нужа печән ашата, дигәннәр. Башына төшкәч, абыегыз русчаны нинди тиз өйрәнде! Э чит телне, немец телен, урта мәктәптә дә укыган, югары мәктәптә дә укыган, шулай да ни укый, ни яза белмим диярлек.

Чит телне балага мәктәпкә хәтле үк инде өйрәтергә кирәк. Элек дворяннар үзләренең балаларына бонналар яллаганнар, без яллый алмыйбыз. Э ник яллый алмыйбыз?

Радиоприемник, кер юу машиналарын төзәтеп (бозып!) бирү өчен «Бюро добрых услуг» яшәп килә. Теләгән кешеләргә балаларына чит телләр өйрәтү өчен совет бонналары табып бирүче «Бюро добрых услуг» ник булмаска тиеш? Килепме йөри, семьядамы тора, «Добрые услуги» боннасы бала белән чит телдә сөйләшә, кирәксә укыта да... Моны эшләргә мөмкин ич. Мөмкин генә түгел, кирәк! Юкса кайчандыр французча, немецча, инглизчә бик яхшы белгән рус иле (чит тел белүчеләр татарлар арасында да булган) хәзер үз теленнән башка бүтән бер телне белми, чит илгә барса, сөйләшә алмый, рус китабыннан башка китапны укый алмый. Коммунизм төзүче алдынгы ил өчен бу бөтенләй дә килешми бит инде.

Белоруссия безнең приютны саламлы чана, жылы тун, йомшак киез итек һәм якты чырай белән каршы алды. Казаннан көзли чыгып киткән балалар йорты, Витебск губернасындагы Сенно исемле өяз шәһәренә кар яугач кына барып керде.

Тәтештән безне көтмәгәндә алып чыгып киткәннәр иде. Пароход белән Казанның Ерак Усиясенә килеп төшкәч, йөк машинасына төяп, көзге пычрак юлдан шәһәргә алып килделәр. Машина безне Кабан күле каршындагы ниндидер мәктәп бинасына китереп аударырга тиеш иде. Ләкин килеп житәрәк чих-пих итеп туктады да, шофер: «Артык бармый!» дип, безне урам уртасында машинасыннан төшерде. Минем аякларымда үзем генә әмәлләгән чүпрәк тапочка иде. Шул тапочкаларым

белән пычрак юлга сикереп төштем дә, жыелып торган суларны аркылы сикерә-сикерә, Кабан күле каршындагы мәктәпкә йөгердем.

Ул төнне без, парта араларына утырып, башыбызны парта тактасына салып йокладык. Иртән кукуруз оныннан кайнар боламык ашаттылар да жыенырга куштылар. Башка бинага күчерәләр, имеш. Аяк киемнәребез аз булу сәбәпле, партияләп-партияләп күчәбез икән. Мин соңгы партияләрнең берсенә туры килдем. Тапочкамның киярлек жире калмаган иде, миңа артсыз агач башмак бирделәр. Оегым юк иде, ялан тәпигә шул артсыз юкә башмакны элдем дә урамга чыктым.

Минем алдан бер кыз бала атлый. Безнең приют кызы. Аның аягында киез итек. Итегенең үкчәләре, юри уеп алган шикелле, түгәрәкләнеп тишелеп чыккан. Әле дә күз алдымда: ул, шушы тишек киез итекләре белән урам пычрагын ярып, минем алдан бара, мин, аның ялтыраган аяк үкчәләренә карап, арттан барам һәм кыз баланың октябрь пычрагында киез итектән йөрүенә дә, үкчәләре ялтырап күренүгә дә гажәпләнмим. Казан урамыннан үземнең ялан тәпигә артсыз башмак киеп, пычрак сөреп баруыма да аптырамыйм.

Каршысында Лобачевский һәйкәле басып тора торган, хәзер үзебезнең тел-әдәбият, тарих институты урнашкан бинага теге кыз белән шулай аллы-артлы барып кердек. Баскычтан югары катка күтәрелдек. Юынып чыгарга душка керегез, диделәр. Кайнар сулары беткән. Салкыны да тамгалап кына тора. Бирә торган киемнәре миңа кендектән генә. Өстемдәге киемнәрем яхшы дип, алар биргәнне алмадым. Душларына кермәдем. Кергән кешеләр соңыннан авырып яттылар.

Шушы бинаның Лобачевский урамына караган зур бер бүлмәсендә атна буе поезд көтеп яттык. Безне төяп каядыр озатырга тиешләр, ләкин кая? Берәүләр әйтә, Америкага озатачаклар икән, диләр. Ышанмыйбыз. Шулай да Америка картасын карыйбыз, океан өстеннән юл сызабыз. Ашарга кукуруз оныннан пешергән ап-ак күмәч бирәләр. Сыныгы кәгазьдән бераз гына... юкарак. Күлга тотсаң урталай сынып төшә. Ашны консерва тартмасына салып өләшәләр. Бик сыек булганга күтәреп кенә эчәбез. Икенчегә — ботка. Анысы маистан (кукуруз ярмасыннан). Ботканы консерва тартмасына салдырып тормыйбыз, чөнки шундый аз, ягылып кына бетәчәк, учка гына салдырып алабыз (һич ялган түгел). Агач калак белән ләч иттереп салалар. Карават башыннан кечкенә генә калак телеп алабыз да (караватлары агач иде, без бер караватны телеп бетерә яздык бугай), учтагы ак ботканы шул калак белән чемченеп, бик озакка сузарга тырышып ашыйбыз. Тамак кына котырынып кала.

Эш бүлмаганлыктан, бөтен үйлаганыбыз ашау. Көндезгесен ашап бетерүгә, кайчан кичкесе житәр икән дип, зарыга башлыйбыз. Кичен шул ук ботканы учка ләч! Аннары кишер чәе — консерва тартмаларына салып... Аннары ач карынга йокы.

Ул елларда ата-анасыз, йортсыз-жирсез калган балалар иксез-чиксез булганлыктан, республика өстенә килгән ач үлемнән ул балаларны ничек тә коткарырга тырышканлыктан, Казанда һәм өязләрдә балалар йортлары бик күп ачылган иде. Шул хәтле баланың ничек тамакларын туйдырып бетерергә дә ничек өс-башларын карап житкерергә... Гражданнар сугышы яңа гына беткән. Шунын өстенә ике ел рәттән корылык... Идел булып Идел кипте, жәяүләп аркылы чык, шундый сай урыннары бар. Пароходлар йөри алмый. Ачка үтерүдән куркып, хөкүмәт балаларны икмәкле якларга озатырга кереште. Без дә озатуны көтеп, агач караватлы таш бүлмәдә каңгырып ятабыз.

Менә бер көнне консерва савытларын ялап, коелган валчыкларны жыеп ашап бетергәч, куанычлы хәбәр алдык: иртәгә китәбез! «Иртәгә китәбезләр» инде бүлгалаган иде. Шуңа күрә ышанып та бетмибез. Юк, бу юлы чынлап китәбез ахры. Лобачевский һәйкәле каршына трам-

вай килеп туктаган (ул елларда трамвайлар, Кремль турысыннан борылып, вокзалга төшеп китәләр иде). Балаларның күбесе ялан өс, ялан аяк. Каршыга килеп туктаган трамвайга чыгып утырырлык та рәтләре юк. Без, зуррак малайлар, кечкенәләрне җилкәләребезгә атландырып ташый башладык. Ике баланы култык астына кыстырам да, артсыз башмак белән ялангач үкчәмне шап-шоп кыйный-кыйный, бакча аркылы трамвайга таба йөгерәм...

Кич белән санитарный вагоннарга төялеп бетеп, әкрен генә кузгалып киттек. Поездга беренче утыруым. Тәрәзәдән көзге пейзажны карап барам. Авыллар кала. Моржадан чыккан төтеннәр кала. Үлән ашап йөрүче сыерлар кала. Агачлар артка таба чабыша, ерактагы урман, поезд белән узышып, алга таба чаба. Аннары бер зур күл калды. Күлдә казлар калды. Барысы да калды, без киттек тә киттек.

Бер көн бардык, бер атна бардык, бер ай бардык... Паровозның ягарына беткән чакларда, вагоннан төшеп, урманда утын кисештек. Утынны паровоз тендеренә ташыштык. Казаннан октябрьда чыгып киткән идек, Белоруссиягә кышлый гына барып кердек.

Чаналарга төяп, безне алып киттеләр. Америкага барасы кешеләр Сенно шәһәренә барып егылдык. Салам җәелгән идәнгә түшәлеп йокыга киттек.

Җирле халык, белорус хатыннары, Идел буеннан ач татарлар килде дигән хәбәрне ишеткәч, култык асларына икмәк кыстырып, безнең янга килә башладылар. Шулай бер көнне бер бөтен икмәк тоткан белорус хатыны ишекне ачты да миннән сорый:

— Кайда монда Поволожьедан килгән ач татарлар? — ди. (Анда Поволжье димиләр, Поволожье диләр.)

— Менә, мин әйтәм, мин булам инде ул ач татар, Идел буеннан килдем.

— Алдама, — ди бу миңа, — син татар түгел, — ди, кулындагы икмәген бирәсе килми. Күрәсең, татар булгач, ач та булгач, ниндидер коточкыч кешеләр, тарих китабы битләренә төшерелгән тере ерткыч монгол-татарларга охшаган булырга тиешләр дип уйладылар бугай.

Хәйләсез — дөнья файдасыз, дигәннәр. Безнең арада бишектә чакта ук «пәри алмаштырып киткән» бер бик ямьсез малай бар иде. Арыклыкка ач шайтаннан да арыграк. Белорус хатыннары икмәк күтәреп килсәләр, шушы малайны чыгарабыз. Ул: «Мин ач татар, Поволжьедан килдем» дип, хатыннардан үзен кызгандырып, икмәкләрен алып керә иде. Инде соңрак, мәктәптә укып йөргән чакта, белорус, яһүд, поляк малайлары, кызлары да мине «Син татар түгел» дип йөдәтәләр иде.

— Я алайса, әйт берәр сүз татарча, — диләр.

Мин әйтәм. Юк, диләр, син татарча әйтмәдең, син татар түгел, беләбез инде без татарларны, укыганыбыз бар... Татарлар корявый була, ә мин, янәсе, корявый түгел. Ни булса булды, белорус, яһүд кызлары үзләренең балалык мәхәббәтеннән мине дә мәхрүм итмәделәр. Рәхмәт аларга. Мин нәкъ менә шулар арасында үземне башка милләт кешеләре белән бертигез итеп сизә башладым. «Гололобый татарин» сүзен алардан ишетмәдем. Белорус кызы Таня миңа үз өйләреннән укырга китаплар ташый иде. Мин аның матур кулларыннан Гогольне, Пушкинны, Крыловны алып укыдым. Рәхмәт йөзеннән мин ана китапларын төплэп бирә идем. Таняны минем белән бер партада утыручы белорус егете Недосеко (егете дип, ундүрт яшьлек малай) ярата иде. Ул Таняга багышлап шигырьләр язды, Таня өчен атылырга йөрде. Минем янга балалар йортына килә иде дә, револьверын өстәлгә чыгарып куеп, Таняга язган шигырьләрен миңа кычкырып укый иде.

Белоруссиядә икенче кышны кышлаганда, мин бик күп рус классикларыннан авыз иттем. «Евгений Онегин»ның, «Медный всадник»ның, «Полтава»ның аерым бүлекләрен, Крылов мәсәлләрен күңелдән биклә-

дем. Хәтта Гогольнең (проза бит инде!) «Старосветские помещики» дигән хикәясен, аннары «Страшная месть»ны («Чуден Днепр при тихой погоде» дип башлана торган кисәген) күрми укырга өйрәндем. Рус әдәбиятына мәхәббәтем шушы елларда туды булса кирәк. Татар малае булсам да, русча сочинениеләрдә алда бара идем, минем язганнарымны класста кычкырып укыган чаклар да булгалый иде.

Шәһәр мәктәбенә йөреп укучылар монда да без тагын икәү генә булып чыктык. Шуңа күрә безнең пальтоларыбыз бар иде. Калган балалар кышның кыш буе пальтосыз, аяк киемсез, башларыннан юрган бөркәнеп (ике малайга бер юрган), өйдә утырып чыктылар. Кайчан гына кайтып кермим (мәктәптән, китапханәдән, утын тураргa барган жирдән), идәндә кара юрган бөркәнгән чүмәлә-чүмәлә малайлар утырып тора. Әгәр берәр малайны кая да булса жибәреп кайтарасы булса, башлыклар кычкыртып минем пальтомны салдырып алалар иде (мәктәп урам аркылы гына, пальтосыз да йөгереп керә алам, янәсе). Белорус малайлары, кызлары миңа, әлбәттә, кием бирә алмадылар, э ашарга ташыдылар, якшәмбегә үзләренә кунакка алып киткәләделәр.

Балалар йортында дежур тору минем ише зуррак малайлар жилкәсенә төшә иде. Дежур малай төнлә ат сакларга бара, иртән мичкә белән су китерә, икмәк турый, шикәр комы бүлә һәм башка эшләр эшли.

Мин дежур торган көн иде бу. Заведующиебыз ат жигеп каядыр китте. Мин инде мәктәптән кайттым, э ул әле кайтмаган. Идәннәрне себердем дә дәрес әзерләргә утырдым. (Якты күздә әзерләп калмасаң, ут әллә була, әллә юк.) Кич житте, тәрәзәләр караңгыланды. Инде бүген кайтмый ахры, минем дежурлык ат сакламый гына үтеп китә икән дип, сөенеп торганда, ишек алдында арба тавышы ишетелде. Кадалып кына китсен! Кайтты бит. Кулындагы чыбыркысын да куймаган, минем янга кергән, гүя мине чыбыркы белән куасы.

— Бар ат сакларга, — диде бу миңа.

Ат саклау малайлар күп булганда гына күңелле, бәрәңге пешереп, әкият сөйләшеп ятканда гына... Э мин бит бер ялгызым барасы. Дөрес, ат белән икәү, бөтенләй үк ялгыз түгел. Шулай да көзге төндә, өйдән тышка, караңгыга, салкынга чыгып китүләре...

Шунда әйттем заведующийга:

— Бик соң бит, сәгать уннар бардыр инде...

— Иди и больше никаких! (Безнең заведующийның яратып әйтә торган сүзләре.)

Янгыр булса-нитсә, дип, кожан кидем дә атланып чыгып киттем. Шәһәрдә электр утлары сүнмәгән, сәгать унбер юк. Якты тәрәзәләргә карыйм: анда кеше күләгәләре... Бар бит бәхетле жаннар, дип уйлыйм: өйдә, жылыда... Ашыйсылары килсә, алып ашыйлар. Э мин бер телем икмәксез төнгә каршы шәһәрдән чыгып китеп барам. Бердәнбер иптәшем ат... Мин аңа кешегә дәшкән кебек дәшәм:

— Менә шулай инде ул дөнья... — дим. Тик жавап кына ала алмыйм... Ат көнозын юлда булды, арыгандыр, ашыйсы килгәндер.

Уйланып барам. Кайда ашатырмын соң мин сине? Шәһәрдән өч-дүрт километрларда урман янында үзәнлек бар, шунда тышаулап жибәрсәм? Үзем берәр агач төбенә бөгәрләнеп ятармын. Безнең имгәнеп беткән атыбыз бандитларга кирәкми, урманнан бүре-мазар гына чыкмаса... Бүре турында алай әллә ни ишетелгәне юк шикелле.

Япан кырга килеп чыккач, каерылып артка таба карадым. Жемжем иткән утлары белән шәһәр шактый артта калган, алда кап-караңгы бушлык... Икенче тапкыр борылып караганда, шәһәр ягы инде дөмкараңгы иде. Утлар сүнгән. Димәк, унбер тулып узган. Атны кызулый башладым, тырык-тырык чабам. Минем мәктәп иптәшләрем инде рәхәтләнеп йоклыйлардыр. Таня да йоклый булыр, э мин, татар малае, белорус жире буйлап төн ургасында атта чабып барам.

Баядан бирле инде, офыктагы багана-багана кызыллык минем игътибарны үзенә тарта. Кояш күптән баеган, таң атарга бик ерак. Каян килгән бу кызыл баганалар? Шулай дип уйлыйм, үзем чабам да чабам...

Байтак чапканнан соң, алда кап-кара тау күренде. Бу — урман. Үзәнлек ундарак булырга тиеш. Атны шул яккарак бордым. Карангыда чамалап бетереп булмый — кайда килеп туктаганмын, белмим. Шулай да ат сыртыннан сикереп төштем, атны тышауладым да жибәрдем. Бик ачыгып кайткан икән хайван, кытырт-кытырт ашарга да тотынды.

Мин кожанга төрендем дә агач төбенә барып егылдым. Атның якын гына ашап йөрүе, пошкыргалап куюы жанга тынычлык бирә. Бердәнбер иптәшем ат бит минем монда... Теге ут баганалары башымнан чыкмый: нәрсә булды икән соң алар?..

Бөгәрләнәм, йокламакчы булам. Кая... Башыма әллә нинди уйлар килә. Үзем Белоруссия жирендә ятсам да, күңелем үзебезнең якларда йөри. Авылны, Гөлнисаны искә төшердем. Унбиш яшьләрдәге кыз бит инде ул. Ачлык ботарлап ташламаса ярый инде үзен, минем кара чикерткәмне, дип уйлыйм. Абыйны да искә төшердем, әнине дә... Исәннәрме икән? Ачтан үлмәделәрме икән?

Нәкъ шушы кышта минем әни юлда катып үлгән, э мин, аның улы, әнисе буранда адашып йөргән чакта, берни белми тыныч кына йоклап ятканмын...

Аннары кызыл баганалар турында уйлыйм, бүреләр, бандитлар турында...

Байтак вакытлар үткәч, янучылар файдасына дип, калай савытлар асып, безнең шәһәрдә акча жыеп йөрделәр. Ниндидер шәһәр янган. Мине шомландырган ут баганалары шул янгын шәүләсе булган икән.

Атым читкәрәк китте, ахры: ашавы ишетелми башлады. Калкынып тыңлап торам. Гөп-гөп сикерүен ишетәм. Бүре куып йөрмидер бит? Шырпы да алмый чыкканмын. Бүре уттан курка дип сөйлиләр. Менә тагы кырт-кырт ашаганы ишетелә башлый. Тынычланам. Күзләремне йомам. Уйланам.

Бер тапкыр мин Гөлнисага үзебезнең бакчадан чия жыеп биргән идем. Кара янып пешкән чияләр. Аннары без чия төше белән атышып уйнаган идек. Елаткан идем мин аны шунда. Анысы Гөлнисаны елату өчен күпме кирәк... Елый да, шундук көлә дә... Елавы да матур иде аның... Мин аны шуның өчен елата идем дә...

Ат минем яныма ук килеп житкән. Аяк очымда ашап йөри. Мин аңа дәшәм. Ул, жирдән башын күтәреп, бераз тыңлап тора да, янә кырт-кырт ашарга керешә... Шушындый карангыда яп-ялгыз ул бер дә курыкмыймы икәнни? Әллә ул да, минем янәшә ятуымны белеп, шулай иркенләп курыкмыйча йөриме?

Тынычлангач йоклап киткәнмен. Аягыма орынганга сискәнеп уянып киттем. Күзләремне ачып жибәрсәм, янымда мунча хәтле бер кара нәрсә тора... Куркырга өлгермәдем, «кара нәрсә» мыш! иттереп бик каты сулап куйды. Эчәсе килгән хайванның.

Инде яктыра. Күк йөзе приют юрганы төсле соры, күңелсез...

Туңганмын. Калтыранам, иңбашларымны жыерам. Атның тышавын чиштем. Атландым да эчерергә алып киттем.

...Ул елларда балалар йортларында бертөрле дә тәрбия эше алып барылмый иде. Ачтан үлмәсәләр — шул житкән.

Политика турында безгә берәү дә бер сүз сөйләми. Дөньяда нинди хәлләр — без берни белмибез. Балалар йортына газета-журнал алдырмыйлар. 1922 нче елда Ленинның сәламәтлеге хакында чат саен бюллетеньнар чыгарып ябыштырдылар. Без туктап-туктап укый идек.

Урамда политика кайнап тора иде. Налог инспекторының йортын шәһәр сәүдәгәрләре төн уртасында ут төртеп яндырдылар. Без, чаң тавышын ишетеп, янгынны карарга чаптык. Тирә-күрше йортларны кар

белән күмеп, инспекторның йортын карап торып яндырдылар. Инспектор үзе ялан өс тәрәзәдән сикереп чыгып котылды, дип сөйләделәр.

Урам җырчылары җирле совет башлыкларын мыскыл итеп җырлап йөриләр иде. Аларның җырлаганын мин хәтта бүген дә кәгазь битенә яза алмыйм. Комсомоллар турындагы җыр болай иде:

— Пароход идет, вода кольцами,
Будем рыбу кормить комсомольцами.

Шәһәргә йөреп укучы без икәү генә дидем (икенчесе Володя Сироткин). Без аның белән икебез мәктәп кичәләрендә катнашабыз, шәһәрдәге спектакльләрдә уйнаштырабыз. Бер тапкыр миңа исерек офицерны уйнарга туры килде. (Бу турыда «Онытылмас еллар»да язылган.) Гомер офицер булып карамаган, исереп тә карамаган. Уйнадым. Офицерны дөрес уйнамыйсың диюче булмады, ә менә дөрес исермисең дип, төзәтүче табылды.

— Ике якка да исерергә кирәк, ә син бер якка гына исерәсең, — дип, залдан кереп төзәттеләр. Мин бер якка гына авам икән. Тәҗрибәле кешенең киңәшен искә алып, икенче пәрдәдә «ике якка да исерә» башладым.

Бер тапкыр спектакль алдыннан сәхнә артына ялтырап торган зур маңгайлы утызлар тирәсендәге таза гына бер кеше килеп керде дә, үрә катып, барыбызга да честь бирде:

— Здравия желаю! — дип, үкчәсен үкчәгә шалт иттереп бәрде. Аннары бик җитди кыяфәт белән:

— Минсез башламый торыгыз, мин бик тиз килеп җитәрмен! — диде дә үзе чыгып китте. Без елмаешып артыннан карап калдык. Бу кешене без беләбез. Без генә түгел, аны бөтен шәһәр белә. Ул Сенно шәһәренең мәшһүр тилесе.

Урамда йөргәндә, ул, кинәт кенә туктап, кояшка честь бирә иде дә: «Ваше величество, я к вам!» дип, кояш белән сөйләшә башлый иде. Яисә шәһәр электростанциясенә килеп керә дә: «Минем рөхсәттән башка җибәрмәгез, мин озакламам, килеп җитәрмен!» ди дә чыгып китә. Пасхада шушы кеше чиркәү манарасына чаң сугарга менгән малайларның берсен тотып манарадан җиргә атты... Аннары пичектер ул безнең шәһәрдән югалды. Аны шпион булган икән дип сөйләделәр.

Белоруссиядән безнең китү көтмәгәндә булды. Июнь ае иде. Яһүдләрнең нинди дә бәйрәмнәре. Шуңа күрә мәктәптә укулар юк. Балалар йорты иртәгә китәчәк, диләр. Үз гомеремдә минем бу тикле кабалан җыенуны, кабалан китеп баруны бервакытта да күргәнем булмады. Бер көнне хәбәр алынды, икенче көнне арбаларга төялдек тә сау бул, Белоруссия! Китапханәгә кайтарасы китабымны да кешегә генә биреп калдырдым. Мәктәптәге иптәшләрем белән дә саубуллаша алмадым. Мәктәп бикле. Тәрәзәдән кереп, парталарга үземнең китүем турында язулар язып калдырдым. Таня утыра торган партага укырга биреп торган китабын куйдым.

Казанга кайтып төшкәндә, Казан тирәләрен бөтенләй су баскан иде. Пароход белән Тәтешкә төшеп киттек. Идел әллә кайларга җәелгән. Болын яктагы агачлар муеннарыннан су эчендә утыралар.

Бу юлы инде Тәтешкә үз өемә кайткан кебек кайтып кердем. Шәһәр клубына йөрибез. Яшьләрнең драмтүгәрәкләрендә уйныйбыз. Мин Лев Толстойның «Воскресенье»сын укып йөрим. Белоруссиядә чакта миңа бу китапны, «балаларга укырга ярамый» дип, китапханәдән бирмәгәннәр иде. Таня да табып бирә алмаган иде. Тыелган китап хакында ишетсәк, аны табып укырга тырышабыз инде. А. Куприннның «Яма»сы тыелган китап иде, шуңа күрә мин аны Белоруссиядә чакта ук укып чыктым. Генрих Сенкевичның «Ганя»сы тыелуын тыелмаган, әмма мәхәббәт турында. Аны йотлыгып укып чыктык. Мәхәббәт турында булса безгә генә бир инде. Ә драмтүгәрәктә гашыйклар ролен уйный алмыйм. Оялам.

Мин хәзер инде комсомол члены. Биографиямне сөйләгәндә тамагымда спазма, тавышым бетте... Бик каты дулкынланганмын. Комсомолга кергәч, политикага чумдым. Укыганым гел политик китап. Капиталның нәрсә икәнен беләсезме? Капитал — это стоимость, приносящий прибавочную стоимость, путем эксплуатации. Шулай иде бугай. Инде онытыла башлаган.

Кулда винтовка. ЧОНга (часть особого назначения) йөрим. Төннәрен складлар сакларга барабыз. Винтовка корылган, шулай да төнлә ялгыз басып торган чакта күңел шүрли. Урманда бандитлар күп дигән хәбәрләр бар.

Үземнең туган авылыма кайтып абыйларны күреп килергә, аннан Салтыкка эни янына сугылырга булдым. (Аның үлүен белмим бит әле.)

Тегермән тавына житеп, аска авыл өстенә карагач, моржалардан күтәрелгән төтеннәрне, урамда йөргән кешеләрне күргәч, күңелем әллә нишләп китте дә, тез буыным йомшарып, тизрәк утырдым. Шул утырудан бик озак кузгалмыйча авылга карап тордым. Үзем туган йортны күзләрем белән бик озак эзләсәм дә таба алмадым. Ачлык елда, күрәсең, аны сүтеп якканнардыр. Урыны бар, йорты юк. Бакчабыз күренә. Бакча — зур истәлек. Анда әтинең яраткан алмагачы бар. Бүген барысын да карап йөрермен.

Тегермән тавыннан йөгерә-йөгерә авылга таба төшеп киттем. Очраган кешеләргә сәлам бирәм. Сәламемне алалар да артымнан карап калалар. Танымыйлар. Мин бит инде хәзер ботымда ыштан тормый торган арык малай түгел, ә житеп килә торган егет. Ятим дип, тавык күз дип тормыйсың икән, үсәсең икән... Күләгәдәге агач та үсә, чандыр була, нәзек була, шулай да еллар үтә-үтә зур агачка әйләнә. Өс-баш та шәһәрчә — костюм, ботинка... Галстук та тагып жибәргән... Капчыгымда житди китаплар... Мин Казанга укырга китәргә әзерләнеп йөрим. Авыл кешеләре танымыйлар хәзер инде мине.

— Кем соң син? — дип сораучыларга: — Түбән очның Зарифулла малае, — дип жавап бирәм.

— И, Ибраһим, синмени? Әле син исәнмени? Сине үлгән дип сөйләгәннәр иде бит... — дип, ике кулларын берьюлы биреп күрешәләр.

Кичен үзебезнең очка төшеп киттем. Гөлнисаны күрәсем килә. Зур кыз булгандыр инде ул. Бүрәнәдә кызларның моңлы гына итеп киндер тукмаклаулары ишетелә. Мин шул якка таба борылам.

Кояш баешы чия төсле кып-кызыл. Шәфәкъ ялкыны ярты күкне элеп алган. Тагын да өстәрәк, лимон сарысы төсле сары яктылык эчендә, йодрык зурлыгында Зөһрә йолдыз чекерәеп янып тора...

Тузаны басылган, кичке дым төшкән урам буйлап салмак кына атлыйм. Баш очымда, малай чактагы кебек, ярканатлар айкала. Мин кызлар киндер тукмаклаган тавышка турылап барам. Гөлниса, минем яшьлек дустым, шундадыр кебек тоела миңа...

Көзли Казанга укырга киттем.

...Үтте күп еллар... Гөлнисаның инде әллә ничә баласы бар. Житкән кызлары, малайлары. Менә мин тагын авыл урамында йөрим. Бу минем туган авылым Карамал. Кулларымны картларча артка куеп, әкрен генә барам. Җәйге матур кич. Багана башларында электр лампалары кабынды. Кино башлана. Баядан бирле клуб алдында кайнашкан яшьләр кинога кереп киттеләр.

Каршымда әлеге мин яшь чакта кабына торган йодрык хәтле якты йолдыз тагын чәчрәп кабынды. Бу матур йолдызга кайчандыр минем эти дә, мөгаен, карап торгандыр, эни дә, күрше Җәлил абзый да... Менә хәзер мин дә, нәкъ безнең авыл өстендә кабына торган шушы якты йолдызга карый-карый, югары очка таба әкрен генә менеп барам. Миннән соң да бу күркәм йолдызга сокланып карап торучылар күп булыр әле...

Мөхәммәт Садри

Булган икән көч тә үзеңдә

Булган икән көч тә үзеңдә,
Бергә йөргән чакта Казанда,
Төзелешкә һәм цехка барганда,
Васильевода шигырь язганда,

Гади җырчы, әйбәт дус идең,
Бик чамалы идең буйга да,
Шундый батыр булырсың дип, Муса,
Кермәгән син ул чак уйга да.

Яшьләр белән — комсомолец идең,
Бала белән — бала җанлы син,
Эшче белән — эшче һәм киңәшче,
Шагыйрь белән — кайнар канлы син.

Әсирлектә син кол булып түгел,
Данко булып алга баргансың,
Богауланган аяк-кулың белән
Фашистларга дәһшәт салгансың.

Син кояш та, ай да түгел идең,
Ут чәчмәдең көләч йөзең дә;
Һәммәбез күк гади кеше идең,
Булган икән көч тә үзеңдә.

Рәшит Гәрәй

Уйланган минутларда

Унике юл шигырь яздым

Унике юл шигырь яздым,
Унике төнем үтте.
Унике юл шигырь яздым,
Унике кайгым бетте.

Дуслар ни дияр? — Шул сорау
Йөрәкне кысып тора.
Унике юллык шатлыгым
Бер читтә посып тора.

Ятсына дәү хисләр белән
Кул биреп күрешергә...
Шул шатлыкны дуслар белән
Әзер мин бүлешергә.

Әткәм киңәше

Әткәм минем җырчы булмаган,
Тик ул миңа бер җыр өйрәткән:
— Кешеләргә дигән яхшылык
Шытып чыга, улым, йөрәктән.

Тапламыйча сакла син аны
Авыр юллар аша үткәндә.
Өлешенә тигән кайгыңны
Суза күрмә берүк бүтәнгә...

Кайгыларга азмы юлыктым?!
Йөзләремә чыкты сарысы...
Бакчаларда сафлык... яшеллек...
Башкаларга калсын анысы.

Буразналар

Буразналар, йомшак буразналар...
Тигез булып ерак сузыла.
Әйтерсең лә барып төташалар
Без очасы Галәм юлына.

Хыялымда туган уй-теләккә
Инде шундый ышанып жителгән:

Спутниклар старт алыр төсле
Әнә теге басу читеннән.

Җир куенында үскән Андрияннар...
Галәмне бит шулар кичкәннәр.
Җиргә кайткан чакта, суга түгел,
Буразналы кырга төшкәннәр.

Күгәрченнәр гөлдер-гөлдер...

Күгәрченнәр гөлдер-гөлдер,
Гөрләргә кушкан кемдер...
Пар күгәрчен оясында
Пар бала туган көндер.

Күгәрченнәр гөлдер-гөлдер,
Телләре йомшак телдер.
Күгәрчен теледәй хатта
Сөюләренне белдер.

Күгәрченнәр гөлдер-гөлдер,
Кунган җирләре гөлдер.
Күгәрченнәр моңын тыңлап
Узадыр ялгыз гомер.

Җаныма тынгылык бирми

Җаныма тынгылык бирми
Шау-шулы көннәр уе.
Йолдызлар белән әрләшеп
Чыгамын төннәр буе.

— Сезгә дә үпкәләрлек шул:
Кадер юк сездән җиргә.
Күбегезнең яктылыгы
Аңа бик соңлап килә.

Җансыз күзәтчеләр булып
Йөзәсез күгебездә...
Эх, җирнең кайгысын бүлеп
Бирергә үзегезгә!

Фотографны көтеп

Малай чакта төшкән рәсемеңне
Рәхәттер бит, дисең, карарга.
Альбомымнан аны табарсың, дип,
Мин теләмим сине алдарга.

Бигрәк читтә диеп, фотографлар
Авылыбызга безнең килмәгән.
Рәсемнәргә төшеп йөрер өчен
Үзебезгә дә вакыт тимәгән.

Сабан тоткасына ябышып үскән
Малайны соң ничек күрергә?..
Фотографны эзләп, ул әле дә
Йөридер күк кырлар түрендә.

Көннәрем...

Уйнаган көннәрем бар,
Уйланган көннәрем бар.
Татлы йокымнан сискәнеп
Уянган төннәрем бар.

Җырлаган көннәрем бар,
Елаган көннәрем бар.
Бозлы яңгырлар астында
Чыланган көннәрем бар.

Сөенгән көннәрем бар,
Көенгән көннәрем бар.
Чәчәк булып, күнелләргә
Сибелгән көннәрем бар...

Үз бәхетең белән

Башка чыгу начар йоламыни:
Дустыбызга бура күтәрдек...
Күптән түгел аның бәби туен
Һәм өй туен бергә үткәрдек.

Бокалларсыз табын китек була,
Бик түгәрәк булды бу табын.
Эчмәсәң дә бераз исерерсен,
Тынлый-тынлый дуслар котлавын.

Йорт үзе дә телгә килде кебек:
— Матур семья — тормыш, ил яме.
Әткәң бәхете калсын төп нигездә,
Үз бәхетең белән кил, яме!

Я, шуннан соң...

Очраштык та, никтер оялдык без,
Я, шуннан соң, шуннан ни булган?
Кешеләрдән качып, бер-беребезгә
Гөлләр җыеп бирдек болыннан.

Кавыштык та, кабат аерылыштык,
Я, шуннан соң, шуннан ни булган?..
Гүя күпер генә җимерелмәгән,
Әйтерсең лә дөнья убылган.

Безне хәзер тагын бергә, диләр,
Я, шуннан соң, шуннан ни булган?
Олы хисләр дулкын кузгаткан да,
Кер кунардай хисләр юылган.

Әнкәм уятуга...

Озын юлдан кайтып ял иткәндә,
Кышкы төннәр килә таманга...
Изрәп йокласам да мин төш күрдем,
Ак чәчәкләр күрдем аланда.

Шундый күпләр... Җыеп бетермәслек
Айлар-еллар буе җыйсаң да.
Бу табигать шулай тәүге тапкыр
Гашыйк булган, ахры, җиһанга.

Төшемдә дә тынгы белмәс икән:
Күнелем тагын шашты, жилкенде...
Әнкәм уятуга, өй түремдә
Чирәм шытып чыгар шикелле.

Учаклар

Кырларда көз ае — октябрь...
Төннәрен каранғы бу айда.
Учаклар... Нәкъ шул ук учаклар
Җемелди салкынча тугайда.

Әйтерсең, якканнар аларны
Ерактан кызыгып карарга.
Көндезен беркем дә күрмәгән,
Игътибар итмәгән аларга.

Учаклар... Нәкъ шул ук учаклар...
Көнең ни аларга, төнең ни.
Тик шунысы, аларның яктысы
Көндезен ерактан күренми.

Күргәнем бар...

Күргәнем бар челләдән соң
Актарылып давыл килгәнне...
Шул давылда әгәр яшен уты
Яраласа япь-яшь имәнне, —

Тау читендә үскән каеннарның
Керфекләре яшькә чылана.
Юатырга теләп, һәркайсының
Чәчләреннән сыйпый Җир-ана.

Язмыш миңа яман кулын салса,
Син дә шулай үксер идеңме?
...Каеннарга кайгы килмәсен дип,
Имәннәргә куям инемне.

Бер уйласаң...

Шагыйрьләр дә китә берәм-берәм,
Гомерлеккә килми беркем дә.
Некрологлар тора күренгәләп
Газетаның соңгы битендә:

— Җыр дип янды, җырга багышлады
Ул үзенең бөтен тормышын.
Безнең сафта калган җырларыннан
Тояр күңел аның сулышын.

Бер уйласаң, дусны мактаганда,
Әй, бигрәк тә тыйнак инде без.
Үзе исән чакта шул ук сүзне
Авыз тутырып әйтә белмибез.

—✦—

Яшьлегемне эзлим

Әхсән Баянов

Лирик повесть[1]

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

* * *

Ул елны мәктәпләрдә, техникумнарда, барлык югары уку йортларында укулар беренче октябрьдан башланды. Укытучылар һәм студентлар авылда эшләсен, колхозчыларга ярдәм итсен өчен бугай. Комбайннар кырда ура алмый башлаганчы үз вазифамны үти биргәнгә күрә, мин укырга китәргә соңга калган идем. Без Уфага килеп төшкәндә октябрьның яртысы житкән иде инде. Хәзер мина шундук Свердловскига китәргә кирәк. Бер үзем. Күнегелмәгән юл, чит шәһәр... Мине билгесезлек куркыта. Моннан ике ай элек бары хыял белән генә эш ителгән, конкрет яклары, мөмкинлекләр уйлап житкерелмәгән икән. Хәзер мәсьәлә реаль куела: укырга керү генә түгел, яшисе бар. Стипендия — 125 сум, ул еллар акчасы белән бер капчык бәрәңге дигән сүз. Шул акчага бер ай буе торып кара син! Уфада гына булса консерваториясе, ул вакытта азмы-күпме азык-төлек авылдан да жибәргәләрләр иде... Һич булмаса, үзенә дә кайтып килергә була, ара ерак түгел. Ә тегеннән, Свердловскидан... Менә сина хыял һәм менә сина чынбарлык... Менә бит, алдагыны ни дәрәжәдә күрә алганбыз! Аз гына булса да алга карау өчен дә күпмедер яшәргә кирәк икән ләбаса. Бу «ачышымны» Ленага да әйттем. Аның исә, киресенчә, күңеле күтәрелеп кенә китте.

— Ә ник? Сина именно консерватория дигәнмени? Кер геолого-разведочныйга! Ей-богу, начар түгел. Күз алдыңа китер: таулар, урманнар, елгалар кичеп, без синең белән жирнең миллион еллар яшереп яткырган серләрен ачабыз, сәяхәт итәбез... Бу — үзе музыка! Без синең белән бергә булабыз. Хәзер дә минем белән каласың... Мин шулай телим... Күр дә тор, бергәләп бөтен кыенлыкларны жиңеп чыгачакбыз.

---

[1] Дәвамы. Башы 1 санда.

...Еллар аша карыйм.

Иртә.

Станциянең тынычрак почмаклары буйлап ике яшь кеше атлый. Егетнең аркасында — футляр, бер кулында чемодан. Кыз аны икенче буш кулыннан култыклаган:

— Син анда нишләрсең минсез? Бер үзең?

— Белмим.

Көн уртасы.

Алар бер үк урында унар тапкыр булганнардыр инде. Ләкин һаман йөриләр. Икесенең дә баш июле.

— Ташлап китмә мине!

Кич. Утлар кабынган инде.

— Мин бит сине шулкадәр яратам.

— Әйе, мин сиңа ышанам.

— Ташлап китмә мәхәббәтеңне!

Каядыр баручы поездларны күзләре белән озатып тордылар-тордылар да шәһәргә илтә торган трамвай тукталышына киттеләр.

Аларның берсе — мин, икенчесе — Лена.

Үзебезгә ул көнне дә әлегечә читтән карый алган булсам, мин, әлбәттә, поездга утырган булыр идем, теләсә нинди авырлыклар каршы килсә дә, боз яуса да. Ләкин мин алай эшли алмадым. Кая таба барганымны да аңламыйча, Лена артыннан иярдем. Үз гомеремдә, ин зур хата, беркайчан да төзәтелә алмаслык хата эшләгәнемне белми идем шул әле мин.

* * *

Яна көн туды. Мина тагын әллә ничек күнелсез булып китте — бер дә каласы килми Уфада... Үземне үзем юатырга керештем:

— Свердловскида яшәп булмаячагы — ап-ачык. Ә монда кечкенә булса да өметең кала; бәлки әле нәрсә дә булса килеп чыгар? Шул соңгы өметне дә югалтып булмый бит.

Ике көннән мин парта арасында утырам: геология-разведка техникумында.

Күнел тынычланып, ныклап укый башларга гына калды, дип уйларга мөмкин иде. Юк. Монда «алдан күрү сәләте» белән безнең бернинди мөнәсәбәт юклыгы тагын бер кат ачыкланды. Уку урыны гына түгел, шәһәрдә тору урыны да кирәк икән, тулай торак дигән нәрсә... Бу техникумда ул юк — һәм мин, шундый урыны булган техникум сайлап, бер атна вакыт эчендә, авиация техникумына урнаштым. (Ул елларда техникумнарда һәм вузларда бернинди конкурс юк, һәр жирдә укучылар житми, шуңа күрә, күченеп йөрү мөмкинлеге зур иде.)

Техникумда уку рус телендә бара, безнең кебек татар мәктәбен бетергән кеше өчен, бигрәк тә ул елларлагы авыл мәктәпләре биргән белем белән, ерак китү кыен иде... Икеле белән өчлеләр тирәсендә буталып барам... Укытучылар сөйләгәндә күп нәрсә аңлашылмый, кабатлап аңлатырга, ни өчендер, бик теләмиләр... Вакыт житкерә алмыйлардыр инде. Ике-өч ай узгач, өйдән килгән запас беткәч, экономика дигән аяусыз нәрсә дә кыса башлады. Кыскычның ике жәбе көннән-көн мине һаман катырак элэктерә бара. Ленаның исә укырга сәләте юк икән, бер айдан соң, бер учрежденигә техник секретарь булып эшкә урнашты...

Техникум. Яп-якты зур аудиториядә дәрес бара. Алдагы парталарның берсендә утырам. Укытучы абый тактага мисаллар яза (ул чакта студентларда дәреслекләр юк иде) — «квадрат тамыр алу»... Үземчә тырышып-тырышып «птичка» өстенә тамыр алу сызыгы сузам; хәзер анын астына саннар кирәк...

Шул эш белән мәшгуль булып утырганда җилкәне кытыкладылар. Артыма борылган идем, бер малай кулга язу тоттырды. Укыйм:

«Вы прекрасный молодой человек. Жаль, что я сижу не рядом с Вами.

Валя».

Мин башны артка, Валяга таба борган идем, бөтен группа шул якка төбәлде. Сизгәннәр булса кирәк. Укытучы да мин эшләгән арада хат килгәнне өстәл яныннан күзәтеп торган, мөгаен. Ул шунда ук минем фамилияне атагач, торып бастым.

— Бүген дәрестән соң завучка керегез. ХА — 13 группасына күчерсен үзегезне.

Кызлар шулай тынгы бирмиләр иде безгә ул елларда, дефицит идек шул...

...Бу көннәр күңелдә иң караңгы һәм салкын, пычрак һәм шыксыз көннәр булып калган... Ябыгуның соңгы дәрәҗәсенә җиткән идем. Ә бармак буыннары, каз аягындагы кызыл-кучкыл буыннар сыман булып, шешенгәннәр. Кешеләрдән сорашып белдем, монысы — яшәү урынының һәрвакыт салкын булуыннан килә икән... йоклый торган җир дә, укый торган җир дә салкын, урамга чыксаң — бозлы җил... Ачлык дигән нәрсә үзе өчләтә арттыра суыкны! Күпме түзә алырмын икән мондый хәлдә? Бер семестр үтте, икенчесе башланды... Февраль исә тагын да шәфкатьсезрәк килде...

Дәрестән чыккач та, көн саен диярлек, үземнең бердәнбер яраткан урыныма — җәй көне консерваториягә имтихан биргән йорт янына ашыгам. Анда балалар өчен музыка мәктәбе, рояль тавышы. Мин сәгатьләр буе аның тавышын тыңларга яратам. Ул тавышлар миңа таныш булмаган ерак шәһәр, андагы әкияттәге төсле сарай — консерватория хакында сөйлиләр. Агыйдел болыннарын, аннан... Фәһимәне күз алдына китерәләр.

Нишләп шулай? Нинди хәлдә мин? — Аңламыйм.

Хәтерлим, тулай тораКта авылдан килгән бәрәңгене ашарлык хәлгә китереп булмасмы дип жәфа чиктем... Юлда килгәндә бәрәңгене туңдырганнар. Кайсыдыр «салкын суда эретсәң ашарлык була» дигән иде. Шул сүзне тыңлап, бер чиләккә салкын су ала-ала бер капчык бәрәңгене көн буе укырга бармыйча эреттем. Боз булып каткан бәрәңгене салкын суда болгатканда, бармаклар берни тоймас булып күшектеләр: әрнүгә чыдарлык түгел... Соңыннан электр плиткасына куеп пешереп караган идем, дуңгыз каешы кебек... Бүтән нәрсә калмагач, шуны ашыйсың... әмма барыбер туйдырмый... Күл әрни, йөрәк әрни, ашказаны акылны томалар хәлдә газаплый. Тукта, тагын берәр кастрюль пешереп карыйм, монысы рәтлерәк, йомшаграк пешмәсме? Тагын бәрәңге әрчеп (салкын суда туң бәрәңгенең кабыгын күл белән генә төшереп була) плиткага куйган идем, ишектән комендант килеп керде... Исәнлек-саулык сорашуы шул булгандыр: туп-туры килеп, плитканы тартып алды да чыгып та китте.

— Техникумда каласың килсә, соңгысы булсын!

Нишләп күрми калдым соң әле, нишләп бикләнеп яндырмадым?

Электр энергиясе җитми, шуңа күрә плитка барын сиздермәскә кирәк иде... Җитмәсә, үз плиткам түгел, иясенә ничек жавап бирермен! Бөтен дөньясына төкерәсе иде шушы минутта... Башым иеп, кастрюль тулы бәрәңгегә карап утырам. Кемдер ишек какты. Эндәшмим. Ишек ачылды да шикелле, күтәрелеп карамыйм. Мине бернәрсә дә кызыксындырмый бу минутта. Башта тик бер сорау: нишләргә? Аяк тавышлары якынлаша. Карыйм — Лена. Хәлне аңлаудан булса кирәк, күзләрендә вәсемсызлык очкыннары юк бүген.

— Хәзер нишлибез инде? — диде ул, тынычландырырга тырышу тоны белән.

— Мин авылга китәргә булдым.

Ләкин бу сүз аңа ошамады. Сәбәбен бәлки үзе дә аңламыйчадыр көлеп җибәрде:

— Тапкансың выход! Җүләр!

— Нишләргә киңәш итәр идең?

— Әйдә, чыгыйк әле бу төрмәдән. Монда минем башка күңелле идея килми. Урамда йөрик, кинога керик... Берәр нәрсә уйлап чыгарырга кирәк.

Миңа, әлбәттә, барыбер. Чыктык. Кино карадык. Инде мин аны өенә озатып барам. Безнең яннан гына өр-яңа, озын торыклы җиңел машина узып китте. Мондый машиналар шәһәрдә сирәк очрый.

— Минем абый, өйгә кайта! — диде Лена, мактануын яшермичә. — Мондый машиналар шәһәрдә өчәү генә. Бервакыт син дә шундый машинада йөрерсең әле.

Кайгымны онытып, рәхәтләнеп көлеп җибәрдем.

— Син дә шундый зур кеше булачаксың. Минем абый кебек.

— Кара, сиңнән көлкеле сүзләр дә чыга икән!

— Ә мин сиңа чынлап әйтәм. Мин сизеп торам, сиңдә әллә нәрсә бар... Нәкъ минем абыйдагыча... әйтеп аңлатып булмый аны. Менә зур кешеләр сиңең кебек булалар.

— Укуларын ташлыйлармы?

— Һаман үз сүзе... мин чынлап сөйләшәм... син укыячаксың...

— Авылда техникум ачсалар.

— Ә син монда укыячаксың... Беләсеңме ничек? Техникумның ике курсын бетерәсең... Аннан җаен табачакбыз, менә күрерсең — институтка... Институт бетергәч, сиңа абый помогать итәчәк... Әйтәм бит, зур кеше булачаксың син...

— Җүләр син, Лена.

— Кайсыбыз җүләрдер, карарбыз әле.

— Соң, институт дисең син, техникумнан китәргә торганда.

— Ә син китмисең ич. Юк, китәргә җыенганың да юк синең. Без озакламый синең белән бергә тора башлыйбыз. Мин эшлим, син — укыйсың. Бергә булгач җитә ул, абыйлар да читкә какмас...

Менә нәрсә турында уйлый икән ул! Кич дәвамында беренче тапкыр мин аңа игътибар белән карадым. Башында мех бүрек, кыйммәт якалы пальто... Өстенә ап-ак кар яуган. Чын мәгънәсендәге шәһәр кешесе. Яшь, чибәр... Үземә карыйм: малахай бүрек, кара тышлы гади тун, аякта — пима. Шушы байлыгы, чибәрлеге белән башкаларны да карата алыр иде Лена. Ә ул минем белән, ярлы студент белән тормыш кормакчы! Ник кирәк икән аңа болай итү? Моны Ленаның үзенә дә әйтәм. Ә ул һич икеләнмичә болай ди:

— Әгәр мин сиңа ышанмасам, болай эшләмәс идем. Ә мин беләм, синең көченне сизәм... Күрерсең, сиңнән кеше чыгачак. Нинди генә кеше әле! Син үзең дә шуны телисең ич!

Мин елмаеп кулбашларымны җыерам.

— Белмим. Әйтә алмыйм.

— Җүләр син! Я, килеп җиттек. Бик матур итеп кысып кочакла әле мине. Менә шулай. Хәзер... — Ул кинәт минем баштан кочаклый, — хәзер бик каты суырып үп!..

Кар һаман ява. Безнең яннан гына кемнәндер аяк тавышлары шыгырдап уза. Узса узсын инде...

— Бар, кит. Смотри, әйтмичә, авылга качасы булма. Шимбә көнне сәгать җидегә почтага кил. Точный решение белән кил. Ишетәсеңме?

* * *

Вакыт инде соң булса да, тулай торакка кайтасы килми. Килмит янына кереп чыгыйм эле, нишләп ята икән. Ул да «студент» — кышкы алты айлык курста. Аны бетереп чыккан кешеләрне МТС директоры итеп куялар. Ләкин Килмитнең уку шулай ук әйбәт бармый. Ана да җиңел түгел, бар булганы — башлангыч белем генә. Ә курсларда фәннәр катлаулы — агротехника, бухгалтерия... конкрет экономика... Ул үзе миңа бу хакта сөйләми, аның белән бер квартирада яшәгән иптәше ычкындыргалый.

Килмит өйдә иде. Лена белән булган сөйләшүне аңа җиткерү өчен иң җайлы форсат. Телгә сүз килеп, берничә мәртәбә авыз да ачкан идем, тик ничектер тел бәйләнә, уңайсыз. Аның усаллыгын беләм, я эт итеп сүгеп ташлар. Әллә тиргәмәс, киңәш кенә бирерме? Юк, тагын тукталам.

— Ну, апай, укулар шәп барамы?

— Шунда, уртача.

— Аңлыйсынмы соң сөйләгәннәрен.

— Әзрәк.

— Русча кыендыр инде ул. Мә, өйрән, сүзлек сиңа. Истәлек булсын.

Ул миңа калын гына китап тоттырды һәм, каядыр ашыга иде бугай, җыена башлады. Бүтән берни әйтмәде, сорашмады. Күңелдәгене күңелдә бикләп, чыгып киттем.

Киңәшләшерлек бүтән бер кеше юк. Димәк, минем үземә уйларга кирәк, бик нык уйларга.

Миңа унҗиде яшь. Зур кешеләр төсле йөрим. Сугыш чоры безне тиз олыгайтып җибәрде. Ләкин мин чынлыкта һаман сабый, башта бик күп: «Ни өчен?»нәр бутала, һәркайсына җавап табарга кирәк, таба алмыйм. Ах, киңәшерлек зур кеше шулкадәр кирәк иде миңа ул вакытларда!

Сорау:

— Сиңа закон белән укырга хокук бирелгән. Син шуннан файдаланып укырга килден. Ләкин ничек укырга? Стипендия — ун көнгә җитәрлек. Ә калган көннәрне син ничек яшәргә тиеш? Өйдән ярдәм юк, карт әни һәм миннән дә кечкенәрәк балалар, алар үзләре миннән ярдәм көтәләр. Олы туганнар фронтта, аларда синнән зуррак кайгы — ил кайгысы. Син ничек укырга тиеш?

Җавап:

— Сугыш! Хокукыңны ул юкка чыгарды.

Бу чыннан да шулай. Аңлыйм. Ләкин миңа аңлату кирәкми.

Мин дөньяга килдем: җир — минеке, вакыт — минеке. Ул миңа бер генә тапкыр бирелгән. Ә сез аны ни өчен миннән тартып алдыгыз? Ни өчен?! Кем китереп чыгарды бу сугышны? Кем? Миңа аерым исемнәр кирәкми, Кешелек, мин синнән сорыйм! Менә мин дөньяга килдем, синнән сорыйм: миңа үсү, кеше булу өчен мөмкинлек бир! Кайда ул? Ах, син миңа моны бирә алмыйсың, син көчсез, сине әллә нинди исемнәр белән йөртелгән әллә нинди каршылыклар хәлдән тайдырган, мин сине аңлыйм, ләкин барыбер тынычлана алмыйм, чөнки мин җиргә ике тапкыр килә алмаячакмын. Мин туганмын, димәк, минем яшәргә хокукым бар... Бир минем шушы хокукымны! Ә сәдака миңа кирәк түгел... Булдыра алмыйсың? Көчең җитми? Ул вакытта ник син мине тудырдың? Ни өчен? Син миңа бөтенесен соңыннан, тынычлыкта кайтарып бирермен дисеңме? Ә елларны, югалган елларны, яшьлегемне минем кайтарып бирә алырсыңмы? Кайтара алсаң, мин сине гафу итәрмен...

Сорау:

— Бу — яраксыз, эгоцентризм фәлсәфәсе дисезме? Ә миңа, шулай да, ниш ләргә?

Җавап:

— ?

Атлыйм. Шәһәр уртасына җиттем инде. Монда әллә нинди шау-шулар яңгырарга тиеш иде. Ләкин аларның бүген берсе дә ишетелми миңа. Минем колакта — авыл тынлыгы, күзләремдә — авыл табигате. Урамда яз түгел, көз, томанлы, шомлы көз. Миңа унҗиде яшь түгел, ә ун яшь. Менә бер көн. Мин урманда, әрәмәлекләрдә йөрим. Балан жыеп йөрим. Бер үзем. Базы болынына җиткәч, авылга кайтырга кирәклеген хәтеремә төшердем. Күпмедер баргач, мин елга ярына, биек ярга килеп чыкканмын. Чак кына атласаң... Артыма борылып карыйм, ераклата, тагын да биегрәк урында, карт каен силуэты. Акыл белән уйласаң, авыл шул якта булырга тиеш. Ярдан сикереп булмый, шул каенга табан атлыйм. Мин юнәлешләрне бутадым, каенга таба бару — авылдан тагын да ераккарак читләшү төсле тоела. Бераз баргач, тагы кире якка борылам. Барам, барам, каршыда — тагы елга, ә аның аръягында Түбән Череккүл авылы. Димәк, мин ялгышканмын икән. Адашканмын. Мин тагы каенга таба, тик тагы кирегә китәм кебек, борылам, тагы елгага таба, тагын чит авыл. Шулай күпмедер буталып йөргәннән соң, бервакыт уй керә: юнәлешләр үзләре буталгандыр... Һәм мин бөтенесенә үчләшеп, кире як дип исәпләнгән якка ахыргача барырга хәл итәм. Барам. Каен яныма житәм. Узам. Күрәм, минем алда — үзебезнең авыл. Юнәлеш төшенчәсе кинәт үзгәрде дә китте.

Гажәп сәер адашу бу — юнәлеш буталу!

Бүген дә мин үчләшергә, кире якка китәргә тиештер, бәлки... Бәлки, кайдадыр мине туган авылым кебек якын максатым, үз дөньям көтә торгандыр.

* * *

Берничә көн үткәч, Лена хәбәр китерде: кайсыдыр бер шәһәрдән аның туган тиешле бер апасы кайткан. Элек ире белән торган квартираларында, ике бүлмәле әйбәт квартирада, хәзер башка семья яши, ди. Ниндидер закон нигезендә, ул шушы квартирасын кайтарырга хокуклы. Йөреп-йөреп караган апасы, тик эш чыгара алмаган. Ә Лена тотынса... ул аны башкарып чыга да чыга инде. Ничек итеп эшли торгандыр, мин анысы белән кызыксынмадым; булдыра алгач, карасын инде үзе дидем. Без аның белән кайчан да булса әнә шул квартирада торырга тиеш икән. Өчәүләп була инде, апасы дүрт куллап риза, ди, тик бүлмәләрне генә алырга ярдәм итәсе икән.

Чыннан да, ай чамасы вакыт эчендә Лена бу эшне әйләндереп тә чыгарды. Әмма теге семьянын өйне ташлап чыгасы килми. Аңлашыла, билгеле, кыш өстеннән кем чыгып китсен! Гомумән, кыш көне кешене квартирадан чыгару тәртибе юк бугай, әле март ае гына. Шулай да Лена җаен тапкан! Сере — үзендә. Соңыннан алар апасы белән милициягә мөрәҗәгать иткәннәр. Милиция катнаша хәзер... Бер көнне мин дә анда булырга, ярдәм итәргә тиеш булып чыктым.

Лена белән икәүләп килеп тә життек. Зур гына агач өй, артык күптән дә салынмаган ахрысы, бүрәнәләре иске түгел. Капка төбендә безне бер хатын көтеп тора иде. Кыска гына, сары гына, юан гына хатын.

— Танышыгыз, Сәмига апа.

— Шушы буламыни инде киявебез?

— Булачак киявегез, — дип төзәтергә ашыкты Лена.

— Бик әйбәт, бик шәп. Дөрес эшлисез. Яшь гомер, чәчкә вакыт, әрәм итмәгез, рәхәтен күреп калыгыз. Менә квартирага гына кереп ур-

нашыйк әле. Менә дигән итеп тормыш корып жибәрербез. Мин әниегез урынында булырмын. Идәнен юармын, суын ташырмын. Бәбиегез булса, карармын дигәндәй...

— Сәмига апа, син нәрсә? — диде Лена кызарып.

Сәмига апа дигәнебез телгә беткән нәрсә икән. Шуидук тагын тезеп китте:

— Нинди ояты бар инде аның, менә кызык. Дөнья булгач, бәбие дә булыр инде анын. Сездән генә калмаган.

Тагын нәрсәләр сөйләп ташлаган булыр иде Сәмига апа, белмим, ләкин безгә артык тынлап торырга туры килмәде, урам почмагыннан милиционер күренгәч, ул үзе тынды. Милиционерның шинель каешына таккан пистолеты да бар иде.

Ачык капкадан өйгә уздык. Бер ишектән ике семья йөри икән, аны ачып кергәч, тар гына коридорга тагы ике ишек чыга. Берсе уңда, берсе — сулда. Без уң як ишектән кердек.

— Исәнмесез! — дип, башлап милиционер сәлам бирде.

Җавап кайтаручы булмады. Хужа кеше ишек янындагы өстәлдә, бәрәнге ашап утыра торган жиреннән чак кына кузгалып куйды да, безгә усал караш ташлап, орчык төбе хәтле генә бәрәңгеләрен әрчи бирде. Буйга бәләкәй, юантык, кинчә битле, зур гына авызлы ир кеше. Икенче якта алты-жиде яшьләрдәге ике кыз бала, бүредән курыккан колыннар шикелле, әниләре янына сыендылар. Әниләре, идән юган жиреннән туктап, башын күтәрде, аннары бүреләргә шөмерәеп караган ябык атны хәтерләтеп, арткарак чигенеп куйды. Мунчаласын идәнгә ыргытып, итәкләрен рәтләде, кызларын кочаклап, хәрәкәтсез калды. Аның күзләрендә гажәпләнү катыш тынгысыз сорау, чакырылмаган кунакларның максатын сизү, нәфрәт, ачыну, өзгәләнү — барысы бергә тупланып, әйтерсең, аңа үзен яклау коралы булып әверелгән дә ул безне кисәтә, чигенергә, аннары ишектән үк чыгып китәргә боера. Кызлары ике яктан кысып кочаклаган хәлдә, аналарыннан ялварып сорый, тизрәк бу баскынчыларны куып чыгарырга өнди. Балалар! Балалар да бөтенесен аңлый, сизә! Тик алар йөзендә нәфрәт юк. Алар әле кешеләрнең нинди катылыкларга сәләтле икәнлекләрен белмиләр. Аларда безне куып чыгарырга тырышу юк. Алар үзләрендә әле көч сизмиләр... Аларда бары бер генә хис — курку... Ә хужа үзе, безнең кергәнне бөтенләй сизмәгән исәпләргә тырышып, һаман шул орчык төбе хәтле бәрәңгеләрен әрчеп авызына каба. Ах, бу бәрәңгеләр! Учреждениеләрдә, завод-фабрикаларда, уку йортларында ул чакта аларны һәр төргәктә, һәр өстәл астында очратырга мөмкин иде. Әле дә ярый шул бәрәңге бар! Минем тулай торактa калган бәрәңге... Юк, минем үй читкәрәк китте бугай. Менә абзый тора бит синең каршында. Хәле бәлки синекеннән чак кына яхшырактыр... Юк, аның семьясы бар, син — бер үзең, мөгаен синең хәл аныкыннан жиңелрәктер. Бәлки... Ләкин монда мәсьәлә болай куелмаган, хәзер син килдең, теләсәң теләмәсәң дә син — оккупант...

Синнән риҗалык, фикер сораучы юк хәзер, алданрак үйларга кирәк иде! Ә хужа, әйтерсең, безне күрми. Гүя шул юл белән — без килгәнне инкарь итү юлы белән — мәсьәлә хәл ителә. Юк, хәл ителми, ул аны мөгаен үзе дә сизә, ул өйдә тору вакытын шулай минутларга, секундларга булса да суза, озынайта. Тып-тын... беркем кыймылдамый. Чүлмәктән бәрәңге алганда чыккан ишетелер-ишетелмәс чыпылдау, бәрәңге чәйнәгәндәге күңелсез чәпелдәү... Тагын күпмегә сузылыр бу шомлы тынлык? Бәлки минга, бөтен дөньясына төкереп чыгып китәргәдер? Юк, бүтән уйланырга вакыт калмады. Тынлыкны Сәмига апа үзе:

— Кара син боларны, әйтерсең ки, безне күрмиләр. — Ул бу сүзне милиционерга карап әйтте.

Тегесе, нишлисең, минга кушылган дигәндәй, теләр-теләмәс кенә сүз башлады:

— Сезгә, гражданин Шаһиәхметов, квартираны бушатырга кушылган идеме?

Җавап юк. Бәрәңге чәйнәү, чүлмәктән бәрәңге кармалап эзләү...

— Мин сезгә әйтәм, гражданин... Ничә көн срок бирелгән иде?

Җавап юк. Милиционерның яңгыравыклы тавышы кабатлана:

— Сезгә ике атна срок биргәннәр... Квартира табу өчен. Тыңламагансыз, сез чит кешеләр квартирасында торасыз. Сезгә вакытлыча биреп торганнар, бик рәхмәт әйтеп яшәгәнсез, теге вакытта договорга кул да куйгансыз, ә хәзер, чыгарга кушкач, буйсынмыйсыз. Мин сезгә официаль төстә боерам, хәзер үк бушатыгыз квартираны.

Тагын баягы тынлык, хәвефле, давыл алды тынлыгы. Милиционерның тавышы хәзер кискенләште:

— Ишетәсезме, кемгә әйтәләр? Корал күтәрергәме сезгә? Яхшылык белән тыңлагыз. Ну? Хәзер үк!

Шуны ишеткәч, хатын җан әчесе белән чыелдап җибәрде:

— Кеше талаучылар, көпә-көндез кеше талаучылар! Кая китик! Кая китик без шушы семья белән, кем кертсен безне фатирга? Үзең кертәсеңме? Илтеп куй алайса безне үз өеңә. — Үзе елый, үзе бертуктаусыз сөйли, аңа балалар кушылып, әче тавыш белән кычкырып елый...

— Әни, әни! Әни! — Һаман шул бер сүз. Нәкъ теге вакытта, ояларын туздырып, мин күккә чөйгән гаепсез кош балалары төсле...

— Сезгә квартира табып бирергә мин не обязан.

— Син нәрсәгә генә әбәзен? Кеше куарга, кеше кыйнаргамы?

Идәндә кинәт нәрсәнеңдер шакылдап түгелү тавышыннан сискәнеп, үйдан айнып китсәм, күрәм: милиционер хуҗа янына килгән, хуҗа хатын иренә суга дип белеп, аңа ярдәмгә ыргылганда ялгыш чиләккә абынган икән. Су шаулап түгелгәч, хатын чак кына егылып китмичә калды. Бөтен әрнүе жыелудан булса кирәк, мунчала белән милиционерга кизәнде. Шунда гына ир кеше торып басты:

— Сәйдә! Нишлисең?.. Туктал!

Хатын ачу белән мунчаласын юеш идәнгә бәрде дә тагын үксеп-үксеп еларга тотынды:

— Кадалып кына китегез, жир йотсын сезне! Йотар да аллаһе боерса... йотмый калмас...

— Гражданин Шаһиәхметов, соңгы тапкыр кисәтәм, хәзер үк бушатыгыз өйне... — милиционер хуҗаның бер кулыннан эләктереп алды, тегесе кычкырырга теләп:

— Кыйный алмассың, мин сиңа хатын-кыз түгел. — Ә үзе, чүлмәген эләктереп ишеккә якынлашты.

— Ярдәм итегез аларга, — диде милиционер Сәмигага, бераз йомшарган, чыннан да ярдәм итәргә теләгән кеше тоны белән, — әйберләрен чыгарышыгыз. — Ә үзе һаман ир кешене чыгарырга азапланды.

Тегесе башта өстәлгә ябышты, аннары ишек яңагына ябышты, аннан да ычкынырга мәжбүр булды, коридорга чыккан чакта нәрсәгәдер абынып һаман әле кулында тоткан чүлмәген төшереп жибәрде: бу өйдәге соңгы ризыгы, соңгы өмете коридор идәненә чәчелде.

Буш чиләкне тоткан, ике баласын житәкләгән хәлдә үкси-үкси хатын да ишеккә юнәлде. Бүлмәдә хәзер без дә милиционер...

— Калганын үзегез карагыз! — диде ул.

Сәмига ханым өй буйлап бөтерелеп йөри. Чыгарып ташларга әйбер эзли, таба алмый, өйдә аңа эш күп түгел, чөнки киемнәрне чыгарып ташлагач, өстәлне өстерәп куйгач, вак-вак кына өч дүрт әржә калды. Анысын да тиз тотты Сәмига ханым. Аннары идән уртасына басты да бөсренә таянды:

— Без монда жан кертербез әле... Торганнар да бит, хәерчеләр —

ел буе торганнар! Рәхмәт сезгә, милиционер иптәш, кунакка килеп чыгыгыз бер-ике көннән. Без чак кына жыештырыйк, урнашыйк та...

— Үзегез карарсыз. Квартираны сезгә тапшырам! — диде дә милиционер чыгып китте.

— Бар, Лена, син идәннәрне сөртеп жибәр. Күршедән алып тор бидрә. Кичкә үзебезнекеләрне китерербез. Бер дә исегез китмәсен, ожмах ясыйбыз әле без бу өйдә. Мин утын ягын карап керим әле, берәр нәрсә әмәллик бүгенгә... Утынын да кайтартасы булыр. Анысы — ирләр эше инде аның... — ул миңа карап куйды да чыгып китте.

Тәрәзә яңагына сөялеп, уйга калдым. Нишләп болай килеп чыкты соң әле? Дөрес, бу йортта элегрәк ире белән Сәмига ханым торган. Ире заводта эшләгән. Йорт — шул заводныкы. Ире армиягә алынгач, хатыны да, аңа ияреп, ул хезмәт иткән шәһәргә күчкән. Вакытлыча, килешү белән, шушы семьяны калдырганнар... Сәмига ханымның, закон буенча, үз квартирасына кайтып урнашырга хакы бар. Ләкин кыш өстеннән ул бу кешеләрне куып чыгара алмый. Чыннан да, куып чыгарырга йөрсә дә, ул аны булдыра алмаган. Ә Лена тотынгач... Лена ничек башкарды икән бу операцияне? Билгеле, аның абыйсы мондый гына эштә ярдәм итә алырлык кеше. Тик ул бит — дәүләт эшлеклесе. Мондый вак интригага ничек катнашсын?! Мөгаен, абыйсының авторитетына таянып, Лена башка кешеләр аркылы оештырган моны... «Гражданин Шаһиәхметов»ның кайбер нәрсәләрне аңлавы да, үзен якларга сәләте дә чамалы, күрәсең. Шуның аркасында... Миңа ул, ничектер куян хәлендә шикелле тоелды. Андый куяннар күбрәк булса, бүрегә — иркенлек...

Куян дигәннән, күз алдына бер вакыйга килеп басты. Безнең авылда тотылган куянны теш белән сую гадәте бар, зур егетлеккә исәпләнә бу. Монарчы андый батырлыкка минем ирешмәвемне мыскыл итәләр: «Жәлләйсең син, булмай суннән», дип көләләр. Һәм мин аларга сүз бирдем... Жае да чыкты. Гадәттәгечә мылтык асып, эт ияртеп, көннәрдән бер көнне бер иптәш малай белән куянга чыгып киттек. Жилсез. Йомшак кар явып киткән. Шактый калын яуган: басуда боттан кар. Кыр әйләнәбез. Базы елгасы тирәсенә, болынга киләбез. Анда кар тагын да тирәнрәк, нинди зур чокырлар жир белән тигезләнгән, кер дә чум... Күрәм, минем эт шундый чокырларның берсенә төшеп тә китте, бер куян аның алдыннан өскә таба атылып та чапты. Мин — куян артыннан. Куян, әллә гарип, әллә куркудан, беркая кача алмый, эт куа үзен, мин куам һәм... куянны тере килеш тотып та алдык. Хәзер үлтәнче суеп калырга кирәк бит инде. Кесәләрне капшыйм, актарып карыйм, пәке — юк.

— Ә син теш белән, теш белән! — ди иптәш малай.

Келт итеп искә төште: «Менә сиңа батырлыгыңны, каты күнелле легеңне исбат итәргә жай!» Озак уйлап тормастан...

Бераздан үзем үк сискәнеп киттем. Куян бик аз гына селкенеп ятты да тынды... Минем йөрәк өзелеп төшкәндәй булды. Ниндидер тавыш үртәгәндәй тоелды: «Кызганасың, кызганасың! Барыбер батыр түгел син!»

Мин үземне бу юлы да әнә шул хәлдә итеп тойдым.

Әйе, заманы шундый, сугыш... Хәзер мин дә әйтәм, шәфкатьсез заман... Кемнәрнедер рәнжетергә туры килә. Үзеңне тотып ашамасыннар өчен, куяннан, мәчедән генә булса да көчлерәк булырга кирәк... Менә синең кулга тагын бер куян килеп эләкте — гражданин Шаһиәхметов... Син нишләргә тиеш?

Хатын-кыз, икесе ике яктан бөтерелеп, өй эше эшләп йөриләр. Лена идәнне әйбәтләп юып чыкты, тегесе мичкә якты.

— Менә өй дә жылына хәзер, — дип сөйләнә Сәмига ханым, — күнел дә күтәрелеп китәр, эчләргә жылы керер... Син, Әнис энем, бүген бер-

кая да китмәссең инде, шушында йокларсың... Югыйсә, теге нәмәрсә куып чыгарыр безне...

— Китмәбез апа, китмәбез, — дип юата аны Лена минем өчен.

Инде мина да эш кушылды: Сәмига ханым белән икәүләп ерак түгел бер жирдән өстәл һәм урындыклар, тагын кайбер вак-төяк алып кайтырга тиешбез икән. Бәләкәй чана белән алып та кайттык. Өчебезгә бер кровать табылды. Өлкәнрәк кеше анда үзе ятар инде, безгә идән дә ярар.

Менә өстәлгә кайнар бәрәңге килеп утырды. Юк, бу юлы тун бәрәңге түгел, орчык төбе хәтле дә түгел, күзгә күренерлек, әйбәт бәрәңге — урталай ярып, кешечә, авылдагыча пешерелгән. Парлары чыгып тора... Ашап-эчкәч чыннан да күңел бераз тыныч лангандай тоелып китте. Тәрәзә янына килеп, дәреслек укый башладым.

Күпме утырганмындыр, бер мәлне ишек артында кемнеңдер сүгенүе, дөп-дөп баскан аяк тавышлары ишетелде. Китаптан аерылырга, тавышка колак салырга туры килде. Теге абзый бит, Шаһиәхмәтов... Озак та көттермәде, ишекне киереп ачты да, кыргыйларча акыра-акыра, кулларын бутарга кереште.

— Кем әле, нинди батырлар мине куып чыгардылар? Хәзер мин сезнең үзегезне адәм көлкесе итеп чыгарам. Марш моннан, хәзер үк үкчә күтәрегез минем өемнән. Кемнәр бар монда? Сыпырыгыз бөтенегез!

Лена куркып минем күлбашка сыенды. Сәмига ханым, чыелдап жибәрде:

— Әнис, үтерә бит, үтерә!

Карыйм, абзый бераз төшереп алган икән. Сизелә, бик күп эләкмәгән, кыюланып алыр өчен генә салган булырга тиеш. Кулында андый-мондый нәрсә күренми. Гәүдәгә миннән шактый бәләкәй, көч ягы да, күреп торам, минем белән чагыштырырлык түгел. Шуңа күрә тыныч лыгым югалмады һәм кулга нәрсә булса да эләктерергә ашыкмадым. Бәлки мин аңа бер сүз дә әйтмәгән булыр идем, тузыныр-тузыныр иде дә чыгып китәр иде. Бәлки үзен квартирада үк калдырып чыгар идем. Ләкин монда — хатын-кыз, монда — Лена... Әгәр мин бу исереккә бер сүз дә әйтмәсәм, аларның миннән күл селтәүләре, булдыксыз, жебегән, куркак бәндә дип нәтижә чыгарулары бар. Егетлек дәрәҗәсен сакларгa кирәк мондый чакта. Шулай туры килә. Һәм мин, йөземә усаллык чыгармыйча гына, тыныч кына ишеккә табарак атлап, әйбәт кенә аңлата башладым:

— Син, абзый кеше, болай тавыш куптарып йөрмә инде, яхшы түгел.

Минем кызмауны куркудан, көчсезлектән дип белепме, агай тагы да тупасрак акырынды:

— Нәрсә, курыктыңмы? Шулай шул, мин маленький да удаленький.

Мина үзенең мактануы белән бигрәк тә кызганыч тоелды бу кеше. Көчсез кеше һәрвакыт шулай мактанучан, үзен тел белән юатучан була бит. Ишек янына килдем дә, уң кулымнан тотып (әһә, мускул — шактый нык икән әле, ул хәтле бетереп ташларлык түгел) каердым да читкә этәрдем. Ишекне шап итеп ябып бикләп куйдым. Тынычланырга ниятләп Лена янына, кроватька утырдым. Әмма теге яктагы Сәмига ханым тынычлана алмыйча, һаман сөйләнүендә булды:

— Үтерә икән, харап кына итә икән!

Хужа кеше тузынуын, ямьсез сүзләр белән сүгенүен ишек артында дәвам иттерде:

— Сез уйлагансыздыр, куып чыгардык та тыныч гомер итәрбез дип. Ник кергәнегезгә үкенерлек итәм әле мин сезне. Каберегездә дә тыныч ятмаслык итәм.

— Әнис, ни карыйсың, ни жаның белән түзәсең! — Бүлмә эчендә шулай чыелдыйлар. Тыштан кеше ишекне тарта... Ныклабрак тарткан иде, ишек бавы шартлап сынды да агай чак артына әйләнеп төшми калды. Инде миндә дә ачу кузгалды, санга сукмавына, куркытырга уйлавына женем чыкты. Ишектән атылып кергән иде — мин аның муенына салмак кына берне кундырып та алдым. «Кунак» «ык» итеп беразга гына тынып торды да, баягыдан да яман үкереп, туп-туры минем өскә ыргылды. Мин чигенеп куйдым, иелдем, һәм — бар гәүдәм белән аңа атылдым. Тавыш тынды... Күтәрелеп карасам: абзый кеше туп-туры басып, шаккаткандай тик тора. Аннары ул бераз гына нәрсә эшләптер маташты да тышкы ишеккә таба ук атлады һәм шуның белән аяк тавышы бөтенләй тынды.

Өстеннән авыр йөк төшкәндәй сулап, Лена миңа «молодец!» дигәндәй сокланулы караш төбәде. Тегесе исә, карап кына калмады, мактау сүзләре үк яудырды:

— Менә ичмасам — егет!.. Мондый ир белән яшәү дә рәхәттер... минеке — бер жебегән иде шунда. Чиратсыз эпи генә дә ала белмәс иде. Торыр иде чиратында, торыр иде... Аның алдыннан бер нәмәгә яраксыз хатыннар чират бозып үзләренә дигәннәрен алып китәләр, ә ул тора да тора. Шундый йомшак адәм иде...

— Сезнең ирегез үлдеме?

— Юк, фронтта.

— «Иде» дип сөйләшәсез...

— Фронттагын белмисең инде...

Ханымның төсендә үз иренә карата нинди дә булса якынлык, сагыну, һич югында, ихтирам итү галәмәте күрмәгәч, үземә таныш түгел кешегә кызгану хисе тугандай булды. Менә мин, кемнәргәдер үчләшеп, шушы кешеләр тәртибе буенча яшәячәкмен инде... Күз алдында әле генә тавышсыз-тынсыз чыгып киткән кеше... аның белән бергә жансыз куян... Кемдер үзенең кушу-алу кагыйдәсе шикелле үк гади фәлсәфәсен кабатлый: «Көчсезләрне рәнжетүдән курыкма, үзеңне кимсетерләр». Нинди гади, ләкин аңлау өчен никадәр кыен! Кемнәрнеңдер яшәү принциплары, холыклары, гадәтләре... Бәхет турындагы төшенчәләре, өй жиһазлары, ниһаять, белемнәре, культура дәрәҗәләре!.. Коточкыч! Бер кереп чумсаң, әйләнеп чыгармын димә.

Дөнья минем өчен икегә бүленгән: моннан берничә көн элек сызыкның бер ягында торсам, хәзер исә менә икенче ягында... Хәер, әле башы гына, күз күрер, бәлки бүген генә ямьсез тоелгандыр. Карап карыйк, түзеп карыйк, бүтән жиргә барыбер юл юк ич! Тынычлан, ипташ, һәм сөйгәнең күзләренә кара: алар сине яратып очкынланалар, киләчәк бәхет турында хыялланалар, мөгаен... Сине яраткан күзләр... Ә син аны үпкәләтмәкче буласың...

Ике-өч көннән ул иркәләнеп синең муенына асылыначак та әйтәчәк:

— Без синең белән шундый әйбәт яши башларбыз! Хәзер туйга әзерләник инде.

— Туй? Ниткән туй?

— Без кемнән ким?.. — Ул синең икеләнүеңне сизеп, тынычландырырга тотыныр. — Ярый, туй булмас, ну, якын кешеләр белән жыелып танышу... Аларның сиңа карата фикерләре, синең аларга карата впечатлениең нинди булыр. Киләчәк турында уйласак, шунсыз булмас бит? Син үзең ничек уйлыйсың?

Ә син үзең бу хакта башыңа да китермәгәнсең.

— Туганнар, дус-ишләр белән...

— Әйе, мәжбүри... без караклар түгел ич, в конце-концов, кемнән куркырга?

Эш зурга китүе мөмкин. Ләкин син аннан да курыкмыйсың хәзер. Әмма унайсыз яклар бар. Алдан ук шуны күрмичә мөмкин түгел: кунакка күбесе бай, йогынтылы, культуралы, авылча әйтсәк, затлы киенгән кешеләр җыелачак. Ә син алар арасында якалары ук изелә башлаган, төсе киткән иске гимнастеркадан утырсаң? Қием — кешене публикага тәкъдим итүче реклама... Әгәр рекламасы ук начәр булса, сатып алучылар товарның дәрәҗәсе дә шундый гына икәнне билгели алмыйлармыни! Хужа Насретдин бик бай бер мәҗлескә чакырылгач, шуңа рәхмәт йөзеннән затлы чапан чабуын ашка тыгып: «Аша, чапаным, аша», дип сыйлавын юкка гына сөйләп йөрмиләр ич. Халыкта гомумән киемгә игътибар итмәскә тырышу бар, ләкин тормышта башкачарак килеп чыга. Һәрхәлдә, озатканда акылга карап озатсалар, каршы алганда, киемгә карап каршылыйлар. Бәлки, бераз ямьсездер, килешәсебез килмидер, ләкин бу — хакыйкать һәм мин аны аңлыйм. Минем бу хактагы борчылуны сизгән кебек, Лена бер көнне:

— Иптәш Бадигин, сез ничек уйлыйсыз, костюм сатып алсак...

— Костюм? Минем акчам юк.

— Син һаман үзең турында гына. Монда мин дә бар ич, синең иң якын дустың.

— Сиңа салынырга, мине син кем дип беләсең?

— Ярар алайса, монысын калдырып торабыз. Шулай да син очрашуга готовый тор.

Әзер тор, дигәнне мин үземчә аңладым: келәй табып баянның мехларын рәтләдем. Моңарчы вакыт тими торган иде бит.

Бүлмәдә без икәү. Баян тавышын ишетүгә күршеләр керде. Соклану сүзләре ишетәм. Халыкның үз күңеленнән чыккан, ләкин миндә һәрберсе дистәләп вариант алган мажор ладтагы көйләр, аннары салмак бию көйләре, аннары өермәле ритм, аннары бөтен нечкә ашкынулары белән атаклы «Карабай»... Соңынтын авыр чорның үз тавышы: «Су буйлап»... Нәрсә генә уйнамыйм — күңелдә барыбер ниндидер канәгатьсезлек: сизәм, төзәлсә дә баян элекке кебек түгел... Шул ачудан шып тукталып, баянны кроватька ыргыттым. Тыңлаучылар, аз гына гажәпләнделәр бугай, ләкин күзләрендәге күренер-күренмәс яшьләрне сөртә-сөртә, авыр сулап, таралдылар, бер сүз әйтмәделәр. Минем йөрәкне авырттырган әче канәгатьсезлек хисен, ахры, сизмәделәр.

Әйе, элек күңелне иркәләгән моңнарны мин баян телләреннән тапмадым. Күпме эзләдем, күпме тырыштым — юк алар. Фәһимәгә булган беренче тойгыларым кабынган чакта, Лена белән беренче очрашулар вакытында яңгыраган моңнарны баян чыгара алмый хәзер. Телләрен тикшереп карадым — әйбәт кебек, тыпны да күп чыгармый... Ә тавыш... чит тавышлар, чиелдәүләр бөтен системаны үзгәртә әллә...

Ләкин хикмәт баянда түгел, хикмәт үземдә бугай. Шунысы куркынычлы да аның. Яшьлегемне, мәхәббәтемне, киләчәкнең иң якты көннәрен баглаган музыка. Кайчандыр бөтен жанымны үзенеке иткән Бетховен — инде читләште бугай миннән. Читләште. Читләште!

Ленага сөйләп карадым, гажәпләнә...

— Элеккедән һич начар яңгырамый, каян уйлап чыгарасың жыен чүп-чарны?..

Ул сизми, ул, димәк, башка кеше, ана барыбер! Димәк, жаннар белән без — чит. Менә нинди ачыш!

Шундый уйлар белән атналар уза тордым. Апрель азаклары житте. Күнел, ничектер, ныклап авылга каера башлады. Бәлки, чыннан да, кайтып китәргәдер?

Киңәшләшер өчен тагын Сафуан абзыйга бардым. Бөтен икеләнүләремне, шикләнүләремне сөйләп бирдем.

— Өйләнмәгәнсендер бит? — диде ул, шикләнгәндәй итеп.

— Юк та...

— Калганы чепуха. Лена бай ул, файдаланып кал, соңыннан карарсың тагы.

Аптыраудан, бәхәскә көч житмәүдән бер сүз әйтә алмадым. Ул миңа тагын нәрсә дә булса әйтер шикелле иде, шуны көттем. Ә ул өстәлдә таралып яткан китапларын җыя, тагын каядыр китәргә әзерләнә. Башында бөтенләй икенче төрле уйлар, ахрысы. Менә ул кровать астыннан чемоданнарын чыгарды:

— Мин озакламый кайтып китәм, бу авыррак әйберләрне озата торырга кирәк, авылдан килгәннәр, — диде.

— Уку беттемени инде сезнең?

— Калды шунда ун-унбиш көн.

— Кайткач кем буласың инде?

— Анысы бездән тормый, кая кирәк — шунда куярлар, заманы шундый, сайлана торган түгел.

— Кая да булса кайтасың ич.

— Шул, үзебезнең колхозга, анда көтәләр, эш шактый таркалган. Чәчүләрен дә рәтләп башлый алмаганнар... Миңа туры килер инде, кем бар тагын.

— Озакламый мин дә кайтам.

Килмит кырыс күзләрен миңа төбәде.

— Ә синең өчен кем укыр?

Тагын җавап бирмәдем. Шунда ул үзе өстәде:

— Һәркемнең үз эше, укыйсың икән, укы. Лутчы килмәскә иде бәтенләй. Мин сине жибәрмәскә дә тырышкан идем. Бер нәрсә уйласаң, сине бит тыя торган түгел.

— Менә хәзер укымам инде, синекечә...

Сафуан абзый бу юлы эшеннән туктап, гажәпләнгән күзләрен миннән алмыйча, өстәл янына килде. Сүземне аңларга жыена төсле иде ул. Кыш буена беренче кат. Күңелемдә ана карата ниндидер салкынлык укмаша башлаган иде, шул бозлы төенне чишеп ташлар кебек иде ул бу минутта. Югыйсә, алты ай диярлек вакыт эчендә, бер шәһәрдә торган хәлдә, минем ничек укуым, нинди кыенлыклар кичерүем турында бер генә тапкыр да сорашмады, кызыксынмады бит. Сизәм, холкы шундый аның — бөтен авыл халкы турында берьюлы кайгырта ала, ә бер кешегә игътибары, йөрәк жылысы житми, хәтта иң якын кешесенә дә. Вакыт житмәүдән түгел, болай, әллә ничек...

* * *

Алдан билгеләп куелган көн беркая да күчә алмый... Син дә чигенә алмыйсың. Күпер шартлатылган. Теләсәң теләмәсәң дә — алга барырга, үзеңне анда көткәннәр белән очрашырга тиешсең. Башка юл юк... Ленаның туганнары, дуслары белән очрашыр көн дә житте. Лена белән язмыш кушылачагы яки кушылмаячагы, ихтимал, шушы көнгә бәйләнгәндер.

Сәбәбен ачык хәтерләмим, миңа ул көнне нишләптер соңрак килергә туры килде. Мәжлес тәмам жыелып беткән, «гаепле кешене» юксына башлаганнар иде. Ишекне ачуга, Лена каршыга йөгереп килеп, төймәләремне ычкындыра да башлады.

— Кот алынды... Кайда йөрисең шушындый көнне... Менә бу бүлмәгә кереп тиз генә өстеңне алыштыр.

— Башта юынырга кирәктер ич...

— Кара инде ансын, пожалуйста, тизрәк... санга санап килгәннәр... нинди зур кешеләр... — һәм ул ашыгып кунаклар жыелган бүлмәгә китте.

Мин күршеләргә кереп (бу көн хакына алар безгә бер бүлмәләрен арендага биргәннәр) юынып кына бетергән идем, тагы Лена килеп житте.

— Хәзер монда кил инде менә. — Шкафтан плечикларга рәтләп куелган күлмәк һәм костюм чыгарды. — Күрәсеңме? Министрлар гына кия торган костюм!

— Ух, син...

— Күп сөйләнмә!

Көчләп диярлек күлмәкне салдырды. Майкага текәлеп карады.

— Каралган икән майкаң... Үзең дә инде, әйтсәң телең каламыни? Юган булыр идек... Ну, ярый, ки шуның өстенә генә.

Шактый каралган майка өстеннән өр-яңа ак күлмәк киеп куйгач, эчтән ни киелгәне беленерлек түгел иде. Иң мөһиме тышкы як! Капкара галстук та тагып куйдык. Кызганычка каршы, ул да, мин дә бәйли белмибез икән, аны Лена, залга кереп, кемнәндер төенләтеп чыкты. Аннары чалбар, ялтырап торган яңа түфли, пиджак... ул аларны бүгенге көн өчен кемнәндер алып торган... Лена жилтерәтеп мине көзге янына китереп бастырды:

— Яле, карале, таныйсыңмы үзеңне?

— Юк, танымыйм. Бу — мин түгел...

Ул мине култыклады да залга алып кереп китте: «Ни булса — шул булыр», — йөрәк дөпелдәп тибә, әйтерсең, мәжлескә түгел, суярга алып баралар.

Алдарак утыручылар белән кул биреп исәнләштем. Гажәп дәрәҗәдә чибәр һәм солидный кешегә күл бирдем.

— Абый! — дип таныштырды Лена.

Тәннәрем эсселе-суыклы булып китте.

— Апа! — дип таныштырды Лена абыйсы янындагы үзе кебек үк матур, нечкә гәүдәле сары хатын белән. Абыйсының иптәше икән. Нинди культуралы кешеләр! Сөйләшүләре, үзләрен тотулары бөтенләй безнекечә түгел, әллә ничек, тәкәббер дә түгел, үзләре тыйнак, шул ук вакытта, дәрәҗәләрен онытып жибәрмәүләре дә сизелеп тора.

Тагын кемнәрнедер шулай таныштырды Лена. Бераз ераграк утыручыларга сузыла башлаган идем, колагыма пышылдады:

— Житәр! Жыелган мәжлестә күл биреп күрешмиләр! — дип туктатты.

Безне озынча өстәлнең икенче ягына — абый булачак кешеләр каршына утырттылар. Күңелдән куркыныч шик узды: әллә туйга әйләндерәләр инде бу очрашуны...

Минем тирәдә генә утырган хатын ипи үрелеп алган унайга иренең колагына пышылдады:

— Нинди яшь малайны харап иткәннәр!

«Яшь малай» дигәнне ошатмыйча, усал карап куйдым. Кыз күзләргә килгән кешегә — малай!.. «Харап иткәннәр?» Ничек? Әллә алар чынлап та туй дип уйлыйлармы?

— Мәжлесне башлыйбыз, туганнар! — диде авызы колагына житкән Сәмига апа. — Кем дә булса беренче сүз әйтсә... Мин үзем тел белмим...

Шушындый күп сөйләшә торган апаның тел юклыктан зарлануы мәзәк тоелды да елмаерга мәжбүр булдым.

— Ата урынындагы кеше сөйләсен!

— Әйе, шуннан башлана инде ул! — диештеләр мәжлестәгеләр.

— Шулай ул, туганнар, тегендә кешеләр кан түгә, һәлак була... Ә монда яшьләр... — дип сүз башлаган иде Ленаның абыйсы, кемдер:

— Гаепләмәгез инде яшьләрне, мондый чакта! — дип каршы төште.

— Юк, яшьләрне тиргәрлек эш күрмим мин. Аларның намуслары чиста, нидән куркырга? Киресенчә, бик символлы хәл бу. Безнең гаскәрләр тегендә Берлин капкасын дөбердәтәләр. Монда — мәхәббәт. Димәк, тормыш логикасы шундый. Тормыш туктамый, ул дәвам итә, ул жиңәчәк... Үлемне яшәү жиңәчәк. Беренче тостны менә шул сүз

белән, шуны истә тотып эчәргә телә идем мин. Һәр төрле нәрсәнең яшәве, җиңүе өчен!

Гөрләтеп кул чаптылар.

— Әйдәгез, күтәрдек, кунаклар, — диде Сәмига апа да, колагынача елмаеп.

Беренче тосттан соң, гадәттәгечә, ашый-ашый сөйләшү башлана: кайсылары көннәрнең бер дә жылынмавыннан зарлана, кемдер соңгы яңалыкларны хәтерләтеп куя. Шулай бераз утыргач, Ленаның абыйсы белән апасы торып бастылар:

— Кунаклар, бик нык гафу үтенәбез, безнең заседание буласы... Бармыйча ярамый, сез күңелсезләнмичә генә дәвам итәрсез инде. Мин ышанам, әйбәт башланган эш — әйбәт бетәр.

Бөтенесе аягүрә басып, аларны озата чыктылар:

— Бик вакытсыз булды! Мәжлесебезнең яме китәр инде! — диештеләр.

— Нишлисең, эш кешесе, казенный кеше... булмыйдыр шул.

— Гаепләштән булмасын, кунаклар, бик матур гына утыра бирегез.

— Бигайбә!

Коридорда тукталган идек, күрше бүлмәдән Шаһиәхмәтов чыкканын күрдем дә тәннәрем чымырдап куйды. Тагын кызмача. Ул һаман шушы күршеләрдә тора икән әле, ике семья күпме балалар белән сыешканнар... Җитмәсә, мәжлес ясарга безгә бер бүлмәләрен дә биреп торганнар. Бар бит кинә күңелле, яхшы кешеләр. Ә без?.. Әгәр син көчле икән, сиңа кинә күңелле булу жиңел. Кинә күңеллелек күрсәтү көчсезләр өчен кыен. Әгәр көчсез кеше олы жанлылык күрсәтсә, бу — аның өчен батырлык. Ихтирам итәргә кирәк аны. Ә без?..

Шаһиәхмәтов безне генә күргән иде, китәсе жиреннән борылып, тагы акырына башлады:

— Ә-ә! Сезмени әле бу? Безне куып чыгарып, хәзер бәйрәм итәсезме? Молодцы! Кыланып калыгыз, озак бара алмассыз, кеше каны эчеп ерак китеп бүлмый ул. Белеп торыгыз!

Кайберәүләр тынычландырырга тырышса да, бу аны тагын да котыртты гына:

— Сез барыгыз бер яклы конишне, әллә белмәгән дип беләсезме? Беләбез, бик яхшы белеп торабыз. Бүген ашаганыгызны яңадан чыгартырбыз әле. Канәчкечләр! Ерткычлар!

Менә кешене инди хәлгә калдырдык. Ә Ленаның абыйсы, безнең намусны «чиста» диде. Хәзер аңлагандыр инде... Шуна күрәдер, чыраен караңгыланып, тиз генә ишеккә таба юнәлде. Урамга чыгарга мөмкинлек туудан файдаланып, без дә ияртә чыктык. Анда машина көтә икән, тегеләр тиз генә машинага утырдылар да выжлатып китеп тә бардылар. Калдык. Безнең арттан Шаһиәхмәтов та чыгып житте:

— Убырлар, мәгез, үземне дә тотып ашагыз! Жәл түгел! Мәгез!

Ярый әле бер хәерлесе аны култыклап кай якка дыр озата китте. Тик ул анда да күздән югалганчы акыруын белде:

— Ашагыз мине, рәхәтләнегез, туярсыз!

Бу каләрле дә кыргыйлыкны мин беренче тапкыр күрә идем. Ул миңа шулай тәэсир итте: кичәнең бөтен яме (бәлки, ул ямь булмагандыр да) челпәрәмә килде. Шулай да өйдәгеләрнең моңа бер дә исләре китмәгән икән, алар ашау-эчүләрен беләләр. Безне, шатлыклары эчләренә сыймагандай, кочакларын жәеп каршыладылар:

— А-я-а! Яшьләр керде, яшьләр! Штраф! Валлаһи штраф!

Штраф чыннан да бик кирәк иде. Лена белән рюмкалар чәкештергәч, мин йотлыга-йотлыга эчеп жибәрдем, тиз генә утырдым да, ачуны тыялмыйча, баянны сыздырдым:

— Эх!

Сөйләшүләр җанлана төште, шау-шу, җыр купты.

— Эх, егетебез гармоньчы икән ләбаса! Әйттер әйдә, җәмәгать, баламишкин көенә!.. Безнең болай утыруга бөтен дуслар сөенә.

— Их, безнең болай утырудан дошман гына көенә.

«Сезнең арбага утырылган икән, әйдә, сезнеңчә булсын, мәгез, сезгә «Баламишкин!» — дим эчтән генә.

— Их-ма!

— Әйттереп кал, сиптереп кал... Әйдә!

Күпмедер шулай акырышкач, бию көенә күчтем.

— Әйдә, бас әле!

— И-их!..

Кемдер сызгырып куя, кемдер аяк дөпелдәтә, ата улны, ана кызны белми диләр мондый чакта...

— Кунаклар, тагын берәрне рәхим итеп җибәрегез әле!

— Их, безнең Сәмига кодачабыз! Илла уңган да инде.

— Әллә яшь хатынлыкка рәхим иттерәсеңме, кем, Габделбари?

— Әбәү, жир бит, ни сөйлисең, агай-эне башың белән, — дип кычкырды Сәмига апа.

«Монда агае-энесе калмады инде, бөтенесе мәтәлде», — дияем килде.

Көй туктады. Тагын бер-ике терит аракы күтәрделәр. Шуннан соң, сулу алырга, кайсы кая таралышты. Сизәм, хәмер дигәнең минем дә башка киткән икән, өстәвенә, арылган да бугай. Эчтәге әрнү дә... Мин, башымны баян өстенә салып, оеп киткәндәй булдым. Бүлмә кинәт тынып калды, шылт иткән тавыш та юк. Ишетәм, ике-өч хатын-кыз һәм ир кеше, минем барлыгымны исәпкә алмыйча, Лена белән безнең хакта сөйләшә башладылар. Мине исерек дип беләләр әллә?!

Хатын-кыз тавышы, гөбедән чыккан төсле калын тавыш:

— Бер-ике көн элек кенә күргән идем бу егетне. Впечатление создавать итмәгән иде. Нинди чибәр егет икән, киенеп җибәргәч!

Ирләр тавышы, тамак кырасыны китерә торган гыжгылдык сопрано:

— Каян алды икән, шундый кыйммәтле костюм?!

Гөбе тавышы:

— Кызык син, каян алсын, абыйлары соң!

Ир кеше тавышы — сопрано:

— Егете табылгач, костюмын гына табарлар...

Гөбе тавышы:

— Егет тә башлы икән чукынган... Нинди нәселне карамакчы бит, бер дә миңа өйләнми...

Ир кеше тавышы:

— Менә күр дә тор, бик зур начальник булачак бу малай, күрерсең... Министр булгач, ишек шакып кына керә башларбыз әле.

— Акыллы егет!

— Акыллы егет!

— «Милый друг!»

Дөресен әйтим, «Милый друг» дигән сүзнең мәгънәсен, Мопассаннын хатын-кызлар аркылы карьера ясаучы бер герое икәнен мин бишалты елдан соң, шул әсәрне укыгач кына белдем. Ул вакытта үзем турында нинди кимсеткеч сүзләр әйтелгәнен ныклап сизмәгән идем. Шулай да нәтижәгә килә алдым. «Юк, болай ярамый, моңа чик куярга кирәк». Салмак кына башны күтәрдем дә тегеләрнең күзләренә карадым: тулы гәүдәле ирдәүкә, купец хатыннарына тартым хатын. Ябык кына, озын ир. Шырантай. Мин аларның күзләренә туп-туры карап, өсләренә баргандай, салмак кына атлый бирдем. Алар янында чибәр генә бер кыз да булган икән, ул куркуыннан кычкырып ук җибәрде.

— Ой! Ой!

Әйтерсең, кемдер кагылган, ялгыш аягына баскан.

Алар бер-берсенә нидер әйтергә телиләр, тик мин бар, тыелып тора-лар... Тыелмагыз, тыелма! Ин мөһимен, ин тиешлесен, ин дөресен әйтегез! Рәхмәт сезгә! Яшәсен гайбәтчеләр!

Каударланып бая чишенгән бүлмәгә килдем. Лена шул тирәдә — коридорда кемнәрнеңдер күнелен күрергә тырыша: ирле-хатынлы, үпкәләшкәннәр бугай...

Көзге янына килеп бастым. Анда мина чак кына таныш бер егет басып тора, өстендә бостон костюм, яшь, чибәр... Кемнәрдер бу кешене кич буе минем исем белән атадылар. Ләкин бу — мин түгел. Бу — алдакчы, кара йөз! Ул үзен дә, Ленаны да алдамакчы була... Бу — бөтенләй башка кеше, жир бит!

Нервланып костюмны салып ыргыттым, күлмәкне салдым... Аннары чайкала-чайкала үз киемнәремне кидем дә тагын көзге каршына килдем: менә монысы — мин! Искиткеч шәп йолкыш! Бу — бөтенләй башка!.. Һәм мин менә шушысын артыграк күрәм!

Чыгып барганда коридор почмагында торучылар сагаеп, миңа ымлап, нәрсәдер пышылдаштылар. Лена йөгереп килде:

— Әнис, ничек аңларга моны? Син акылдан язгансың!

— Әйе, акылдан... язганмын.

— Катырак эчкән, яткырыгыз урын жәеп! — диде кайсыдыр.

Ул арада бөтен мәжлес халкы минем янга жыелды. Бая баш өстемдә сөйләшкән ир белән хатын да килеп баскан, үзләренә үзләре ышанмыйча, күзләрен чыт-чыт йомалар: төш түгелме, янәсе. Юк, төш түгел бу, күрегез, төш түгел!

— Мине исерек дип уйласагыз — ялгышасыз. Мин акылдан да язмаган. Бая сезнең белән утырган кеше мин түгел, ул бөтенләй бүтән иде! Ә мин — бу өйгә ялгыш килеп эләккән кеше. Гафу итегез, тыныч-лыгызны урлап китсәм, ачуланмагыз.

— Әнис!

Өскә үземнең кара телогрейкамны кия башлаган идем, Лена жилнән эләктереп алды:

— Саташма, монда син генә түгел. Мин дә бар...

Мин айнып киткәндәй булдым. Әллә бая исерек идемме? Юк, исерек түгел, мин бая ярсыган идем, Ленаның бу сүзе минем телогрейканы гына түгел, бөтен шашынуны бер селтәнү белән салдырып ташлады. Ләкин мин үз акылымда, Ленаны рәнжетергә кирәкмәгәнен аңлыйм. Аның бернинди гаебе юк. Ул бөтенесен яхшы булсын дип, аңа да, миңа да киләчәк ясау өчен дип шулай эшләде. Тик бер нәрсәне генә: минем кем икәнне, мондый нәрсәгә сәләтсез икәнне генә аңлап житкермәде.

— Лена, син миңа ачуланма, — дидем мин тыныч тавыш белән, — тик мин бу йортта бүтән бер минут та кала алмыйм. Калыр идем, булдыра алмыйм, гафу ит мине, мин сине рәнжетергә теләмәгән идем.

— Исереклеге начар икән шул!

— Нигә эчәргә инде, үзен-үзе тоталмагач!

— Аек бит ул!

— Әнис!

Тышкы ишекне ябып чыгып киткәндә, үз артымда мин әнә шул сүзләрне ишеттем. Кинәт күнелне тагын авыртгырып әллә нинди ярсыну чолгап алды, бөтен дөнья ниндидер ямьсез тавыш белән чыелдаган төсле...

* * *

Житте, шунда туктальсын!

Бүтән бу хакта сүз кузгатасым, искә аласым килми, бу истәлекләр мине кимсетәләр, кеше буларак дәрәжәмне төшерәләр.

Менә мин кайчандыр үзем утырткан бакчада... Июль төне, шундый тыныч, рәхәт һәм моңсу июль төне! Монда бөтенесе жанны иркәли, мин тик лирик рәхәтлек эчендә онытылырга телим, аннан аерылырга теләмим.

Алмагачлар... алар инде алма бирәләр. Теләсәң, өлгереп житмәсә дә, барыбер тәм кергән, өз дә кап, әчкелтем, ләкин татлы тәм тел очын кытыклап бөтен тәнгә ләззәт биреп йөгерер. Алмагачлар! Нәрсә ул? Мин күзләремне бер ачам, бер йомам, йоклап китәргә, үткәндәге лабиринттан котылырга, тынычта калырга телим... Ләкин... Күзләремә шәүлә күренә кебек. Кемдер әнә теге алмагач төбендә басып тора шикелле. Кем ул? Таныйсыңмы, юкмы? Төсмерлә, төсмерлә... Калын чәчләре артка таралган, кара гимнастеркага каеш буылган, аягында итекләр... Йөзендә генә түгел, гәүдәсенең бөтен торышында һәр минут ташып чыгарга торган, шул ук вакытта яшерен бунтарьлык!.. Таныдыңмы, бу син иң! Юк, түгел, мең кабат түгел, мин аны күрергә теләмим, ул... Кара шәүлә, югал, калдыр мине, син минем өчен чит, мин сине танымыйм... баш тартам, шулай хөкем итәм! Ишетәсеңме?

Шәүлә якынрак килде, шомырт куаклары башланган төшкә, минем каршыга килеп басты:

Таныйсың, бу — мин, синең шәүләң, үткәнең, синең яшьлегең! Мин утырткан бакчада ял итәсең, ә үземне күрергә теләмисең, тиргисең, хөкем итәсең... Кунак кеше рәхмәт әйтә белергә тиеш. Әйе, мин — бар. Телисеңме, теләмисеңме, барыбер, син мине беркая да куя алмыйсың.

— Ах, әйе, димәк, синең яхшы якларың да булган. Әмма син кит моннан, сине күрсәм, күзләремә яшь килә... Мин сине күрә алмыйм, син мине харап итә яздың, исеңдәме, бөтен язмышымны имгәтә яздың.

— Имгәтә генә язмадым, бөтенләй һәлак итә яздым. Тик син әле исән икән, жирдә яшисең икән, син барыбер кемгәдер бурычлы.

— Бурычлы. Ләкин сина түгел.

— Ә мин нишли ала идем соң? Мин кемгә кирәк идем?

Күземне ачам, шәүлә югала, күзләремне йомсам, ул тагын каршыма килеп баса... Сүзләре ишетелә: тыныч төндә йомшак тембрлы тавыш, баш өстемдә, яфрак шавы белән кушылып, салмак кына яңгырый. Күзләремне ачам, күккә, йолдызларга карыйм. Һавадагы иң якты йолдыз... ул инде минеке түгел, минем андый йолдызым юк, мин аны югалттым.

Үткәннәр шәүләсе... Ай-яй озак эзәрлекләделәр алар мине! Соңыннан да...

* * *

1945 елның 9 мае... Бу көн соңыннан күпме кинокартиналарда сурәтләнмәде, күпме китапларда язылмады... Алар барысы да дөрес. Мин бары шуны гына өсти алам:

Базар шаулый. Кулымда ярты килограмм икмәк. Ул кичә кичтән бирле тамакны кытыклап, күңелне күпме генә үртәсә дә, мин аңа карамадым, сакладым. Әгәр ашасам, туачак көнемне ашап бетерермен кебек тоелды. Хәзер аны сатармын да тагын берничә көнгә карточка белән икмәк алырга акчалы булырмын.

Яп-якты иртә. Язгы нур ниндидер яңалык вәгъдә иткәндәй, ялыккан тәнгә хәл керткәндәй тоелды. Кайдадыр якында гына инде ничә ел буе көткән сүз ишетелде: «Сугыш беткән!» Безгә таныш кочаклашулар, кычкырышулар!.. Күңелгә чыкмаслык урнашып калган бер агай.

Белмим, ни өчен килгәндер ул базарга, нишләп йөргәндер. Ике аяксыз. Тәгәрмәчле такта өстендә утырган килеш, куллары белән жирне этеп, үрмәләп йөри. «Сугыш беткән!» дигән сүзне ишетүгә ул шундук кычкыра да башлады. Әйләнчек шикелле бөтерелә-бөтерелә кычкыра: «Беткән, сугыш беткән!..»

Бөтен бер базар шаулый, э мин бернәрсә дә ишетмим, беркемне күрмим. Бөтен аңым шул кешенең сөенечена кушылып киткән. Шатлык! Ай, бу шатлык!

Кемнеңдер эндәшүен сиздем. Янымда математика укытучысы — үземнән дә ябыграк бер абый басып тора иде.

— Күпме сорыйсың ипиенә? — диде ул.

Ипи кайгысы калган идеме соң ул вакытта. Сугыш беткән! Хәзер бер нәрсә дә кирәкми.

— Акча бирмәгез, абый, болай гына алыгыз, — дидем мин, ана ипине сузып, — сугыш беткән!

Укытучым бу хәбәрне инде ишеткән булган, күрәсең, артык үзгәрмәде. Миңа гына ишетелерлек итеп:

— Юк әле, сугыш бетеп житмәгән, — диде дә кесәмә күпмедер акча салды. Мин аның артыннан аптырап карап калдым. Баягы аяксыз кешегә карадым. Ул хәзер бөтен базар буйлап тәгәрәп йөри. «Сугыш беткән!» Бөтен шау-шуны аралап күңелгә уй керә: «Юк әле, бетеп житмәгән».

Ләкин бәйрәм, искиткеч зур бәйрәм. Танышларым атна буе мине көн саен мәжлескә чакыралар, мин уйнаганга кушылып жырлыйлар, биләр, күңел ачалар.

Тик шатлыклы минутларда да күз алдына әлеге агай килеп баса, кайндыр таныш сүзләр ишетелә: «Бетеп житмәгән»...

Станция.

Эшелоннар. Аларда солдатлар, танклар...

«Сугыш бетеп житмәгән...»

Ә минем килешәсе килми бу сүз белән. Үземне көчләп ышандырам: беткән! Хәзер инде элекке максатларны яңартырга мөмкин, кайбер эшләрне яңадан башларга.

Поездлар, поездлар. Пассажир поездлары. Алар миңа кирәкми, аларга түләргә акчам юк минем. Товар йөртә торган — ташкүмер, цемент, агач төялгән вагоннар — минем урыным шуларда. Жаен тап та — хәерле юл!

Төнге поезд мине кайдыр очырта. Кая?

Уйлана торгач төшендем: яшерен, үземнән дә яшерен диярлек серем бар икән ләбаса! Консерватория! Әйтерсең, анда мине көтәләр. Әйтерсең, хәзер яз түгел, э мин юлга чыгарга тиеш булган көз. Әйтерсең, кичәге көнне бүген эзләргә барам, әйтерсең...

Әйе, мин ярым шашынган хәлдә узган көнне куып барам... хатамны төзәтмәкче булам.

Бәлки, хәзер миңа азы да житә торгандыр, барлык теләкләрем тупланган шул изге йортны тышкы яктан гына булса да туйганчы бер карап торасым киләдер. Ишек төбенә барып егылсам да, бәлки, минем ин зур бәхетем шулдыр...

Таң энгер-менгере. Салкынча жил исә. Станциядә поезд тора. Километрга сузылган озын состав буферлары бер-берсенә бәрелә дә баштан ахырга таба металл тавышлары шынгырдап йөгерә. Брамматларга сигнал бу... милиция күргәнче, вагоннарның берсенә сикер... Сигналга буйсынып, буш, ачык вагонга мин дә утырам. Ул арада артымнан чайкала-чайкала ике кеше менде. Поезд кузгалуга, алар минем янга килеп тә життеләр. Поезд барышын тизләтә... «Юлдашларым» салып алган икән, телләре көрмәкләнә. Килеп житүгә, берсе өстемдәге телогрейка итәген капшап карады:

— Ничек уйлыйсын Митя, минем фуфайкамы бу? Әллә ошаган гынамы?

— Юк, ошамаган, синең фуфайкаң үзе инде бу! — ди икенче исерек һәм төймәләрне ычкындыра да башлый.

Мин аны бөтен гаудам белән бәрелеп этеп жибәрәм дә читкә тайпы-

лам, сикермәкче булам, әмма күрәм: поезд шактый тизләп өлгергән... Уйлап торырга вакыт юк, һәм... юл читенә ыргылам... Бернинди авырту юк, шундук икенче вагонга сикерәм... Монысында тыныч, беркем дә юк, будкага утырып оерга да мөмкин...

Таң атты. Сәфәр тагын дәвам итте: вагон түбәсендә...

Зуррак станцияләрдә эш харап, теләсә кайсы вагоннан, сыбызгыларын чырылдата-чырылдата, минем кебек юлчыларны чүплиләр. Тагын шундыйрак станциягә жителде. Поезд туктау белән, кире якка төшеп, алгарак сыпырдым. Монда эләкмәсәң дә, яңадан утырырга жай табылмаячак, поезд кузгалганчы милиция һәм тимер юл эшчеләре сагалап кына тора. Бераз жәяүләп китүен хәерлерәк... Юлда йөгереп утырасың... Тәжрибә бар инде: поезд әкренрәк барырга тиешле жирне чамалый алсаң, кыен түгел. Бу юлы мин ике-өч километр ары киттем, поездны яшел үлән арасына утырып көттем. Монда тимер юл тигез жирдә, биек түгел, вагонга ябышу жайлы булырга тиеш. Поездның тизлеге генә ничек туры килер.

Ерактан паровоз дөпелдәве ишетелде, йөрәк үзе дә дөпелдәп куйды... «Утырып булса ярар иде», дигән уй ярсытып, ашкындырып тора. Әгәр монда, ачык яланда, төн кунарга калсаң!

Паровоз пошкыра-пошкыра килә... Чын чабуы белән чаба. Кемнәрнедер куркытып, кемнәрнедер кисәтеп, бөтен көченә кычкыртып куя. Бу тизлек белән килгәндә, димәк, утыру хакында хыялланырга да ярамый. Төтеннәрен тузгытып чапкан шул поездга карап, бер секунд эчендә катгый карарга килдем: ничек кенә булса да утырырга! Әйтерсең, каядыр ашыгам, әйтерсең, мине кайдадыр көтәләр, әйтерсең, барыбер түгел, әйтерсең... Күз алдыннан вагоннар жемелдәп уза башлады... Поезд чаба, аның артыннан мин чабам. Мине вагоннар уза тора, жай юк... Үземне үзем белештермәс дәрәжәдә ярсыйм, һәм чапкан атның ничек ярсыганын аңлап алам. Бу вакытта вагонга бәрелеп изелү, тәгәрмәчләр астында өзгәләнеп калу мөмкинлеге дә куркытмый, әйтерсең, курку дигән нәрсә минем өчен бөтенләй юк. Һәм... мин ыргылам... Юк, подножкага эләгә алмадым, тормоз янындагы бер тимергә эләгеп, асылынып калдым... Кул хәзер, менә хәзер ычкыныр да... бөтенесе бетте. Бармаклар тимергә чытырдап ябышканнар. Мин тагын кеше ышанмаслык ыргылыш ясап, буферлар өстенә күкрәк белән ятам һәм гәүдә авырлыгының аскы якка тартуын сизеп, бер секундта «беттем» дигән уй белән шашам. Икенче секундта: «Нәкъ үзем теләгәнчә» дигән уй килүен сизәм дә тыныч лангандай булам. Тагын бер секунд... Нәрсә уйлаганымны инде белмим, хайваный бер талпыныш, теренен үлемнән саклану инстинкты белән, турникта атынган шикелле башны алга, аякларны артка ыргытам. Һәм күкрәк буфер өстендә тигез урнаша... Менә инде корсак белән ятам... Һәм поезднын коточкыч тизлек белән баруын, буферлар кинәт бәрелешсә, тагын тәгәрмәчләр астына очачагымны сизәм. Ләкин бу хәл мине тагын һич тә куркытмый икән. Башка сәер бер фикер килә: «Батырлык дигәннәре әллә шушымы соң?» Әйе, аны, барыннан да элек, куркудан өстенлек дип исәпләсәң, шушы була торгандыр инде батырлык. Теләсә нинди куркыныч янасын, мин аңа бирелмим, минем өчен үлем куркыныч түгел, мина барыбер.

Мин тагын бер кат жан әчесе белән талпындым да бер аякны буфер өстенә куя алдым, һәм... үземне ат өстендә итеп хис иттем. Димәк, мина үлем кагылмый узды. Икенче бер секундтта уй тагын искегә кайтты: нәрсә эшләдем, батырлык эшләдемме мин? Әйе, батырлык, ләкин, ләкин... аның эчтәлеге юк... Ул беркемгә кирәкми, чөнки аннан һичнинди файда юк, кешеләргә дә, үзенә дә. Бу тик гади өметсезлектән туган шашыну... Ә батырлык ул өметсезлектән түгел, өмет зур булудан, шул хәрәкәтнең кешеләргә нәрсәдер китерәчәген сизүдән, алар алдында бурычыңны аңлаудан һәм шуны үтәү омтылышыннан килә. Шуна күрә

үтәлеш хәлендә үк рухи канәгатьләнү китерә, шатлык китерә, бәхет китерә. Сиңнән бу куркыныч эшне беркем дә сорамады, көтмәде, шуңа күрә беркем дә белми дә калды. Һәм шуңа күрә ул сиңа дан да китермәде, шатлык та. Жәниңә рәхәтлек түгел, ниндидер бушлык, ризасызлык, әченү генә калдырды...

Поезд пошкыра-пошкыра чаба да чаба. Юлның, әйтерсең, чиге юк. Ул миңа көн саен яңа танышлар китерә. Свердловскига якынлашып килгәндә, кечкенә станцияләрнең берсендә, үзем кебек үк яшь егет белән очраштым. ФЗӨ укучысы — кара бушлаты һәм фуражкасы күрсәтеп тора. Авылга кайтып бара икән.

Без аның белән бик тиз дуслаштык. Аерылышасы килмәгәнгә, аңа үзем белән Свердловскига барырга, соңыннан үзебезнең якка икәүләп кайтырга тәкъдим иттем. Свердловскига ни өчен баруымны әйткәч, дустымның никадәр гажәпләнүен күрсәгез иде! Шулай да ул ризалашты, чираттагы поездларның берсенә, вагон түбәсенә утырдык. Иптәшем артта, мин жилкәне алга куеп, ана карап барам, ул — миңа. Дөньяда ниндидер урын, үз урыныбызны табу хакында сөйләшәбез. Аркага салкын жил бәрә, муенны бөкшәйтеп, телогрейканы башка үк күтәреп куям. Болай жылырак тоела.

Поезд чаба да чаба. Әйтерсең, ул — тормышның үзе. Кемнәрнендер монда үз эшләре, үз вазифалары бар. Машинист поездны алып бара, берәү — паровоз миченә күмер тутыра, ут өсти, кемнәрдер йөкләрне саклый... Ә без... вагон түбәсендә — законсыз йөк... Егылып калсак, безне беркем дә юксынмас, сизмәс иде.

Уйланып барган жирдән, кинәт, юлдашым әче тавыш белән кычкырып, минем өскә ташланды:

— Иел!

Күз ачып йомган арада мине кочаклап яткырды. Кинәт мин үземне төпсез коега төшеп киткәндәй хис иттем, тирә-як дөм-караңгы, борынга төтен кереп тончыктыра: ютәллим, үрсәләнәм. Юлдашым шуны сизеп миңа эндәшә. Аның тавышы жир астыннан килгән кебек:

— Башыңны яшер, куфайкаң эченә! Капла!

Бу — тоннель икән, гыйфрит авызы төсле. Моннан өч-дүрт минут кына элек шул авыздагы тимер-бетон ныгытмага бәрелеп, минем баш поезд астына тәгәрәргә тиеш булган, ә очраклы дустым аны саклап калды. Бары бер секунд... Әгәр шул секунд булмаса... Кеше гомере! Нинди очраклы гына хәл икәнсең син!

Иртәнге сәгать уннар тирәсендә поезд ниндидер тау тезмәләре итәгенә урнашкан бер станциягә туктады. Бәлки, безнең файдагадыр. Тамакка капмаганга инде тәүлектән ашкан, якын-тирәдә, бәлки, нәрсә булса да табарбыз. Кесәдәге вак-төяк акчаларны жыйнап, базарга барып килергә булдык. Юлдашымның кулында чемодан, ана күренеп йөрергә ярамый — хәзер әләктерәләр. Ә мине сизмәскә мөмкинлек — кулда бер әйбер дә юк. Поездның кузгалырга ният барлыгы сизелми. Киттем базар эзләп. Тимер юл буйлап чакрым чамасы жир атлагач, сулга тайпылдым. Чыннан да базарга охшаган бер урын бар, шунда икебезгә икешәр пәрәмәч, бәрәнге пәрәмәче алдым да иптәшем янына ашыктым. Ул ачыккан, минем килеп житүне минуты белән көтә. Алдарак, тимер юл буенда күзгә ике кеше чалынды. Аллы-артлы киләләр. Берсенең кулында чемодан, кечерәк буйлы... Икенчесе милиционер түгелме соң? Якынлаша төшкәч, алдагы кешенең кара бушлаты, ФЗӨ фуражкасы аермачык күренде. Шул бит, минем юлдашым! Эләккән малай!

Ул үзе дә мин килгәнне күреп алды. Артка борылып сыпырсаң, милиционерның игътибарын гына жәлеп итәрсең һәм качып та котыла алмассың. Аннары юлдаш егетемнең дә пәрәмәчне бирмәскә теләде дип алмассың. Аларга каршы атлыйм. Кулда пәрәмәчләр... Иптәшикләнүе бар бит. Аларга каршы атлыйм. Кулда пәрәмәчләр... Иптә-

шем аларны күреп алды. Тәүлек буе ризык капмаган кешенең күзләре пәрәмәчкә ничек өзелеп каравын кем аңламас! Ничә генә метр — үз пәрәмәчләре, ә ул аларны ашый алмый, ымсынудан бары тик төкерекләрен генә йотып куя һәм муен мускуллары нәрсәдер ашагандагы кебек хәрәкәтләнә. Бер-ике генә адым... Бу минутта мин: «Мә пәрәмәчләреңне!» дип әндәшергә әзер идем, тик ул, үзе минем белән бөтенләй таныш түгел кеше сыман, карашын читкә борды. Мин, нәрсә эшләргә белми аптырап, адымнарымны акрынайттым. Милиционер шикләнмәде, илтифатсыз гына карап узды. Киттеләр. Шул вакыт әле генә аерылышкан юлдашымның тамагын кытыклаган ачлыкны жинеп, иптәшлек тугрылыгына хыянәт итмәвен, ике пәрәмәч өчен очраклы иптәшен дә үз артыннан ияртмәвен уйлап, иң яхшы дусны югалткан төсле, ачынып куйдым. Икенче көнне үзем дә икенче бер милиционер кулына капкач һәм мине каядыр юл тотучы пассажир поездына кертеп бикләгәч кенә, бу ачыну кимегән кебек булды: «Хәзер инде мин үзем дә аннан яхшырак хәлдә түгел». Ләкин без поездда, каядыр барабыз.

Тәүлек ярымнан (ябылучылар егерме-утызлап кеше жыелган иде) кайсыдыр бер шәһәргә китереп төшерделәр. Тимер юл милициясендә допрос алдылар да, икенче болай буталып йөрмәскә киңәш итеп, чыгарып та жибәрделәр. Шәһәргә чыккач карасам, ис китте: мине яңадан Уфага китереп ташлаганнар...

Әйе, узган көнне бер ычкындырсаң, аны яңадан куып житәрмен димә икән. Теләсә нинди тизлекләр дә ярдәм итә алмый мондый чакта.

Консерватория!

Мин аның йортын гына да, тышкы ягын гына да күрә алмадым. Ишек төбенә барып егылырга дигән теләгем генә дә үтәлмәслек зур максат булып калды хәзер. Дөнья! Инде мин нишләргә тиеш? Әйтегез, мин нишләргә тиеш хәзер, кем әйтә ала? Кем?

Адашулар төрлечә була. Мин аларны күп күргәнмен икән. Менә тагын бер очрак күнелгә килде. Миңа унсигез түгел, нибары өч яшь!

Кояшлы якты көн. Көянтә-чиләк алып апам суга китте. Мин аның белән барырга телим, көт дип кычкырам, су буен карыйсым, дөнья күрәсем килә. Тик апам мине аңламый, бала адымына барырга, жәфаланырга теләми. Монда да мин кирелек эшләп ташлаган, күрәсен. Апам китсә, мин дә калмаганмын, саз юлы буйлап, тирес буяны узып, урманга юл тотканмын. Чишмә ягына түгел, бөтенләй икенче якка... Томанлы гына хәтерлим, ул вакытта урманның эчендәрәк ниндидер участок киртәләр белән уратылып алынган иде, мин шуның эчендә булып чыктым. Урап йөрим, ары китәм, бире киләм — кая барсам да шул киртәгә килеп чыгам. Минем башта, ничектер, өйгә кайту омтылышы да юк; каядыр барырга, куркыныч жирдә калмаска тырышу инстинкты буенча гына үрсәләнеп йөгерәм... Йөгерәм, атлыйм, елыйм... Менә күк күкри, яшен, яңгыр... Урман эче гел су... Ә мин һаман йөрим... Күпме йөрелгәнен соңыннан үземә әйттеләр: төшлектән кояш батканчы. Кояш баткач, өйдә мин юклыгы беленгәч, әни эзли чыккан... Бәхетемә каршы, шушы урманга килгән. Ерактан ыңгырашкан, елауга охшаган тавыш ишетеп, минем янга ашыккан. Ә мин киртәгә сөялгән дә, хәлдән таеп, елау тавышын бер көйгә кабатлап тик торам икән. Әни мине кулына алгач, шунда ук йокыга киткәнмен...

Мине анда әнием коткарды. Ә хәзер? Кем эзләр мине?

* * *

Атна буе югалып торуымны Сафуан абзый да (ул кайтып китәргә өлгермәгән икән) һәм Лена да сизмәгәннәр иде.

— Я герой, — диде Сафуан абзый, мине күргәч, — укулар ничек бара?

— Укулар? Әйбәт.

— Чынлапмы? Ярый. Югыйсә, мин начар хәбәр ишеткән идем, Лена белән...

— Юк андый нәрсә.

— Паспортыңны пычраттыңмы?

— Юк, намусны гына...

Ул мина, бу нинди кулга тотып булмый торган әйберләр турында сөйлисең дигәндәй, сәерсенеп карады.

— Намусны гына булгач, ничево, — диде ул, шаяртып, — намустан чалбар тегеп булмый. — Һәм шактый таушалган өс-башыма күз төшерде. Бүтән бернәрсә дә сорамады.

— Мин иртәгә авылга китәм, — диде ул.

— Ярый, әйбәт кайтып жит, Сафуан абзый. — Ул мине югалткан идеме бу чакта, мин аныны — белмим.

Ленаны музыка мәктәбе янында очраттым. Дәресрәге, рояль тавышы тынлап моңаеп тора идем, үзе килеп чыкты. Ул да ямансу иде. Мин гафу үтенгәч кенә йөзе ачылды.

— Безгә туганнар белән очрашу-мазар дип баш катырырга иртә, — дидем мин, — безнең арада нәрсә икән, әйдә, сынап карыйк. Мәхәббәт булса, ул үз юлын табар.

Шулай сүз куештык. Элеккедән сирәгрәк булса да, тагын очраша башладык.

Соңыннан Лена, ни сәбәптәндер, тагын да сирәгрәк күренә башлады. Бер көнне житкерделәр: ул Зөфәр Миңнеханов дигән баянчы белән чуала, диделәр. Бар икән хәлләр, анысы да баянчы... Лена, синең гадәттә бу, ышанам...

Күзәтә башладым — мина моны үз күзем белән күрү кирәк иде.

Бер көнне, андый-мондый хәл чыга калса дип, бик әйбәт сугыша белә торган иптәшемне алып, Леналар квартирасы турына килдек. Моннан ярты гына сәгать элек аларга теге Зөфәр дигәннәре кереп киткәнен күргән идем. Ул кире чыкканда, без аларны каршылаячакбыз...

Инде караңгы да иде... Ә болар чыкмыйлар да чыкмыйлар. Бер вакыт шул квартира хужасының кызы узып китте. Ул мине таныды, билгеле... Онытканмын икән, Лена ул вакыт инде башка квартирада яши иде. Сәмига апасы аны куып чыгарган. Без көттек, ярты төнгә хәтле көткәнбездер, ләкин болар чыкмадылар.

Икенче көнне консультациядән соң (хәзер техникумда имтиханнар башлана) туп-туры Леналар квартирасына чаптым. Квартира хужасы — яшь кенә апа — ялгызы гына иде. Аннан кичәге хәлне сораштырам. Өй эчендә менә нәрсә булган. Апаның кызы безнең өй тирәсендә йөрүебезгә бик гажәпләнгән. Өйгә кергәч, шундук төшенеп алган: анда, Лена белән әңгәмә корып, кылыч борынлы чандыр бер кеше утыра икән! Менә ничек! Хәзер урамга чыксалар, алардан нәрсә каласы билгесез, яшьләрнең (безнең була инде) акыл юк, харап булулары бар. Лена белән бу кешене түгел, безне кызганалар икән: кызып, ялгышып куюлары бар... Бөтен тормыш юк өчен бозылуы мөмкин. Әнисе белән шулай киңәшеп, теге кешегә үз бүлмәләрендә урын жәеп биргәннәр...

Бу көннән соң Лена белән бүтән очрашу, сөйләшү булмас инде дисәм, ул икенче көнне үк техникум капкасы янында мине көтеп тора. Күрмәгәнгә салышып узып китмәкче идем, ул кулымнан эләктерде дә, мине үзенә каты гына тартып, берни булмагандай, йөземә төбәлде. Мин кызгалдым, аны калдырып киттем. Ул, куып житеп, мине култыклады, селтәп атаргамы дигән идем, арттан бергә укыган иптәшләрнең күзәтүен сизеп, тындым һәм... тагын, дус кешеләрчә, тыныч атладык. Шактый вакыт сүзсез барылды.

— Әйдә монда сөйләшик, — диде Лена, бу юлы гаепле тавыш белән, һәм шәһәр бакчасына ымлады.

— Нәрсә хакында?
— Бар сөйлиселәр... Керик әле, соңгы тапкыр.
Соңгы тапкыр дигәч, тынладым. Кердек. Тып-тыныч бер почмакка килдек. Ул утырды, мин басып торам.
— Әйт әле, Әнис, әгәр теге көнне без сезнең каршыга чыксак, син миңа кул күтәрә алыр идеңме?
Мин нәрсә әйтергә белмичә аптырабрак калдым. Чөнки нәрсә килеп чыгасын без алдан ул хәтле конкрет планлаштырмаган идек бит.
— Белмим, — дидем мин, салкын гына.
— Шулай да... тәки кыйнар идеңме?
— Нишләп мин? Анда мин генә түгел ич...
— Ә-әх, менә ничек... синең иптәшең!
— Ул — каты куллы... аның белән сугышып караганым бар.
— Ни сөйлисең син!
— Кала малайлары өйрәтә!..
— Ә теге кешене нишләтер идегез? Анысын син?
— Мөгаен.
— Рәхмәт, дөресен сөйләгән өчен...
— Кеше сугышканда да честный булырга тиеш...
— Анысы сезнең төшенчә.
— Беттеме? Мөмкинме миңа китәргә?
Лена, ничек, килешмәдекмени әле дигәндәй, гажәпләнде. Мин аның күзләрендә нәрсәдәндер уңайсызлану, үкенү сизгәндәй булдым. Анын төсе үзгәрде. Мин инде араны өзәргә бик вакыт икәнен, кызыгы китә башлавын аңлатам. Ә ул риза түгел. Мин аңа ачуланмыйча гына әйтәм:
— Тапкансың ич, теге артистны... матур гына итеп йөр инде, миңа комачаулама.
— Мин сиңа комачаулыйм?
— Әйе.
Лена, әрнүен яшермичә, бөтен гәүдәсе белән бөреште, кулларын ирененә китерде, баш бармагын үрсәләнеп тешләде. Сүзне озакка сузмас өчен, китә башладым, ә ул кинәт әче итеп кычкырып жибәрде:
— Китмә!
Мин, ни булды икән дип, аңа борылгач, ул өстәргә ашыкты:
— Тагын бер минутка!..
Һәм ул мине кочаклап алды. Мин аның кулларын ычкындырам, ул тагын кочаклый, мин тагын читкә этәм... Ул кулларын миннән ычкындырмаска тырыша... Менә ул, хәле киткәндәй, алга шуып, жиргә егылды һәм, тезләремне кочаклап, үксергә тотынды. Ни хикмәттер, кеше еласа, кызганудан минем йөрәк сызлый һәм, кем генә булмасын, мин аны юата башлыйм, сүзен тыңларга, теләген үтәргә тырышам. Үземә кыенлык китерә торган эш булса да анынча эшлим. Ә бу юлы аның үксүе кызгану уятмады, ачуны гына китерде. Менә ул, бөтен хатын-кыз затын кимсетеп, минем аяк астында ауный. Бәлки, шуның өчен нәфрәт кузгалгандыр? Кешелек дәрәжәсе турында төшенчәсе булмаган кешеләрне гомерем буе күралмадым мин! Минем өчен моннан да зур түбәнлек юк, андый кешеләрдән һәртөрле эшәкелекне көтәргә мөмкин... Эчтә жыелган ачуны тыярга тырышып, кырыс кына әйттем:
— Тор!
— Гафу ит, Әнис!
Менә тагы! Минем гафу итүем ник кирәк инде аңа, ул шуна мохтажмы? Чынлыкта ул гаеплеме? Безнең аралар бозылганга шактый инде, мин аны үзем ташлап киттем, моннан соң ни теләсә — шуны эшләргә хакы бар кешенең. Ниһаять, гомумән ирекле.
— Минем сиңа ачуланганым юк.

— Ялганлама, күреп торам, син минем белән беркайчан да болай сөйләшкәнең юк иде.

— Тор, сөйләшәсең килсә...

Ул теләр-теләмәс күтәрелде, башы июле, үзе һаман үкси, күзләрен сөртә. Башка уй килә: «Ә Фәһимә болай эшләмәс иде. Ул бөтенләй моңа охшамаган!»

Күз яшенең минем алда дәрәҗәсе юк, мина кичерешләр кыйммәт. Ышанычлы мәхәббәт яшьләре оялчан була, аларны күрсәтмәскә тырышалар. Күрсәтәләр икән, мин сагаям: монда ниндидер сер, максат яшеренмиме? Әлбәттә инде, кеше үз-үзен белештермәс дәрәҗәдә ярсыган булмаса...

— Бу кадәр каты күнелле икәненне башыма китермәдем.

— Сиңа ни кирәк миннән, Лена?

— Син кирәк! Бүтән бернәрсә кирәкми... Син минем янда булсаң, шул житкән... Туйдырсам, атнага, айга бер очрашсак, шул житкән. Мәхәббәт димим, анысын таләп итмим, юкны таләп итеп булмый... Мин очрашу гына таләп итәм, сорыйм.

Ул миннән берни дә таләп итми... моңысы яңалык... Моңарчы бөтен нәрсәне тормышларыбызны бәйләүгә корган кеше... Үзгәреш бар, димәк. Мондый хәлдә мин кешене ихтирам итә алам. Аннары...

— Бүгенгә житәр, иртәгә сөйләшербез, — дидем мин, йомшак тонга күчеп.

Лена үзе генә булдыра ала торганча иркә елмаеп, көзге болыт аша кинәт ай яктырган төсле ачылып, карап куйды. Килешүнең, сүздә булмаса да, чынлыкта инде хәл ителгәнлеген ул, әлбәттә, сизә иде.

* * *

Техникум. Мин бүген аны калдырып, авылга китәргә тиеш. Ишек төбендә, вахтер өстәлендә хатлар. Узып барган һәр кеше шуннан үз фамилиясен эзли. Мин дә шулай эшлим. Хат юк, ләкин записка бар. Почерк буенча шундук таныйм — Лена язуы:

«Әнис!

Минем хәл начар. Бүгеннән соң теләсән дә, бик теләсән дә күрә алмавың ихтимал. Соңыннан үкенерлек булмасын дисәң, бүген кич минем янга килми калма.

Соңгы кабат үтенәм.

Лена».

Бүлмәгә дә кереп тормастан, аның янына чаптым. Ул хәзер Тукай урамында үзе генә аерым бер бүлмәдә тора иде. Эшләгән жиреннән биргәннәр.

Ишек шакыйм. Эндәшүче юк. Өйдә түгелдер, ахырсы, бераз иртәрәк килгәнмендер. Бераз урамда йөрергә кирәк.

Бер сәгатьтән тагын килдем. Тагын ишек бикле.

Инде кич житте. Караңгыланды. Сәгать уннар булгандыр. Тагын килдем. Ишек ачылды.

Лена!

Мин аны бу кыяфәтендә беренче тапкыр күрәм! Шундый агарынган, йөзе көл шикелле. Сәламәтлек, көрлек, көч сирпелеп торган йөзләре — күм-күк булып көйгән. Басып торырлык та хәле булмагандыр, ахырсы, ул бер кулы белән тезләренә таянган, икенчесе белән ишек янагына тотынган. Идәндә ниндидер чүпрәкләр аунап ята, алар астыннан кан агып чыккан.

— Нишләден син, Лена?!

— Жаным дим, сорама, чап тизрәк скорый помощька. Тизрәк, зинһар дим!

Мондый чакта бәхәсләшүнең кыйбатка төшүе мөмкин. Мең төрле

шиккә төшеп, тышка атылдым. Нәрсә бу? Үзенә-үзе кул салганмы? Ни өчен? Ни өчен?

Ярый әле ашыгыч ярдәм ерак түгел, шул ук урамда. Беренче сүзем:

— Анда... бер хатын-кыз белән бәхетсезлек!

Эшнең нәрсәдә икәнен сораштыралар, мин бернәрсә белмим, шулай да барырга булдылар.

Мин яңадан Лена янына чаптым. Бу юлы ул идәндәге чүп-чарны жыйган, караватында авыртудан газап чигеп утыра.

— Ничек? — диде ул мине күрүгә үк.

Нечкә, жиз тавышы тагын да нечкәрә төшкән, янып торган азгын күзләр тонык ланган, сүрелгән. Алардан хәзер хәлсезлек, курку сирпелә.

— Нәрсә булды? Нишләдең син? — димен тагын, аптыраудан түзә алмыйча.

— Соңыннан, Әнис!.. Иртәгә син монда килерсең. Ачкыч күршеләрдә булыр. Сорарсың.

— Ник?

— Соңыннан. Аңларсың.

Ул арада ишек шакыдылар: врач һәм сестра — ике хатын-кыз. Алар керүгә Лена тагын миңа эндәште:

— Килми калма, харап итә күрмә. Ишеттеңме? Гомергә онытмам. Ә хәзер чык.

— Ни булды сезгә? — дип сорады врач.

— Хәзер, ул чыгып китсен инде, — диде Лена мине күрсәтеп. Аннары тагын миңа карады, — бар, тизрәк, акыллы бул.

Мин ишекне ябуга, алар нәрсә хакындадыр сөйләшә дә башладылар. Ә мин, акылдан язган кеше шикелле, нәрсә эшләргә түгел, нәрсә уйларга да белмичә, капка төбендә тукталдым. Машина янында.

Өч-дүрт минут та үтмәгәндер, Ленаны житәкләп алып та чыктылар. Машина янында мине күргәч, Лена куркынып эндәште:

— Син нишлисең монда? Нишләп китмәдең?

— Сине, андый-мондый хәлдә, каян эзләргә? Ничек табарга?

— Мин сине үзем табармын! — диде ул машинага күтәрелгәндә.

Шап итеп машина ишеге ябылды. Мотор гүләргә тотынды һәм машина күз ачып йомганчы күздән югалды.

Аңлый һәм аңлата алмаслык табышмак чишелмичә, мине төн буе диярлек йоклатмыйча газаплады. Шуна күрә соң торылды, мин уянганда бүлмәдә беркем дә калмаган иде диярлек: кайсы юынырга, кайсы аска — ашханәгә таралышкан. Тиз-тиз юынып, ипи капкалагач та Лена квартирасына ашыктым.

Сезнең чит кеше өенә үзе юкта кергәнегез бармы? Бик сәер һәм катлаулы хис билн анда күнелне. Кеше дөньясына керүең аермачык сизелеп тора. Бөтенесе монда синең иркендә, сина кеше үз өен, юк, өен генә түгел, үз тормышын, үз күнелен ышанып калдырган. Син бу дөньяда үзеңне ничек тотарсың? Ышанычны аклый алырсынмы, әллә бөтен нәрсәне таркатырга, куелган нәрсәләрнең тәртибен бозарлык саксыз кыланырга жөрьәт итәрсеңме? Мин шундыйларны беләм, алар чит бүлмәдә көн-төн эчәргә, урам кунакларын чакырып алар белән кәеф-сафа сөрергә — хужага тиешле ихтирамны таптарга мөмкиннәр. Мин Лена бүлмәсендә, нәрсәгә карарга, нигә тотынырга белмичә, шактый вакыт хәрәкәтсез тордым. Сизәм, бу дөньяга минем ихтирамым бар икән. Чит дөнья, тик ул миңа таныш, якын...

Идән чип-чиста, карават матур, пөхтә жыелган, ике урындык, һәркайсы үз урынында... Аларда күбесенчә без икәү утырабыз, бәлки икенче урындык минем өчен генә куелгандыр. Анда миннән башка утыручылар да булды, билгеле. Ниһаять, күзем өстәлгә төште. Анда да бер кәгазь кисәгеннән башка берни юк. Кай арада өлгергән ул болай жыештырырга? Хәлсез килеш...

Кәгазьне карыйм... Юк, бу кәгазь генә түгел икән, бу — документ, йөрәк документы... Күрәсең, ул авыру хәлдә түгел, ә элегрәк язылган. Йотлыга-йотлыга укырга керешәм, әйтерсең мин укымыйм, әйтерсең бүлмәдә аның үз тавышы, үлем килүе ихтимал чакта да курыкмаган батыр тавышы ишетелә:

«Кадерле дустым!

Минем өчен синнән дә якын кеше юк икән. Мин шуны бүген генә белдем. Гажәп. Уйлап утырдым: кемгә яза алыр идем мин бу хатны? Юк, мондый серне синнән башкага әйтерлек түгел, мин аны бары сина гына әйтә алам икән.

Әнис!

Мин сине моңарчы борчымам, сиздермәм дигән идем. Вакыты житкәч, бөтенләй икенче төрле хәл ителде. Үзеннән-үзе... Уйлый торгач аңладым, моны синнән яшерү файдасыз. Бигрәк тә — минем исән калмау мөмкинлегең уйласаң. Ниһаять, син үзеңә кагылган нәрсәне, үзең «гаепле» эшне белергә тиештер ләбаса! Сина әйтергә батырчылык итми йөргән нәрсә шул — менә өч ай инде мин үз эчемдә синең мәхәббәтеңне, синнән күчкән тере бәхетемне, син бүләк иткән үкенечле бәхетсезлекне күтәреп йөрдем. Синең ул хакта уйламавыңны, уйларга да теләмәвеңне сизгәнгә күрә, син болай да читләшергә, ташларга җай эзләгәнгә күрә генә әйтми түзгәнмендер мин моны. Менә хәзер белдең инде. Син нәрсә уйларсың, нәрсәләр кичерерсең? Юк, күз алдына китерерлек хәлдә түгел мин. Син мине тиргәячәксең. Мин сине бары шул хәлдә күрәм.

Менә мин вәгъдәмдә торам. Хәтерлисеңдер: син бернидән курыкма, мин сина тагылмам, комачауламам дигән идем. Болай булгач, син миңа артык үпкәләмәссең, тиешле бәямне бирерсең, ихтирам итәрсең. Шулай бит? Хәзер инде моңа исәп тотар өчен минем бөтен нигезем бар. Әгәр исән калсам, син мине элеккегә караганда ныграк яратырсың дигән өмет туды миндә.

Күрәсең, мин кечкенә булса да тәвәккәллеккә барам. Законга каршы эш, жинаять эшлим — врач икәнлеге дә шик астындагы бер кешегә үземнең гомеремне тапшырам, ул миңа ниндидер дару бирергә тиеш... Әгәр файдасы тимәсә, үзе шушы бүлмәдә операция ясарга тиеш.

Миңа бу куркыныч та түгел. Барыбер түгелмени? Бөтенесе мәхәббәт хакына. Таләп итсәң, моннан катлаулырак һәм кыенракларны да кичерә алыр идем.

Хуш, дустым!

Булган начарлыкларымны гафу ит. Синең катылыкларны мин көнендә үк кичерә бардым...

Лена.

21 май, 1945 ел».

Мәхәббәт һәм жинаять.

Анда Лена һәм мин катнашкан.

Бәлки...

Менә бу урындыкта башкаларның да утыруын Лена үзе дә әйтергә мәжбүр булган иде. Шулай булгач, әлеге хатның миңа язылырга тиеш булганлыгына ничек ышанып бетим? Ничек? Тик кара шикне мин куарга тиеш, куарга, куарга!

Ни булса да, бүген безне бәйләп торган бөтен нәрсә юкка чыкты. Бүтәнчә болай дәвам итә алмый, югыйсә бер фажига тагын да зурракларын китереп чыгарырга мөмкин. Үзең терелгәч мин моны, әлбәттә, әйтәчәкмен сина.

Мин бу бүлмәдә хәзер артык тора алмыйм. Лена, монда синең тормышың, мин монда бүтәнчә кала алмыйм, ишетәсеңме? Бу дөнья минем өчен түзү мөмкинлеге калмаган дәрәҗәдә тынычсыз, һавасы агулы диярсем килми, телем бармый, тик мин сулый торган түгел. Монысы —

хакыйкать. Синең дөньян... Менә мин хәзер йозакны алдым, чылтыратып бикләдем һәм мин аны, бәлки, беркайчан да ачып кермәячәкмен.

Бу ишек, бу йозак минем өчен бикле торсыннар. Килештекме?

Менә шулай.

Ә ачкыч? Кемгә калдырыйм? Аны ташлап китәргә ярамый, һәр хәлдә, мин алай булдыра алмыйм. Аны Ленаның үзенә, үз кулына гына тапшырырга мөмкин. Гомерлек үкенеч булуы бар. Эх, Лена, Лена!

Ачкычны кесәгә салганда кулга ниндидер кәгазь эләкте: пароход билеты икән. Мин китәргә тиеш идем бит. Ерактан гудок тавышлары ишетелә, пароход тавышы...

Мин Ленаны эзлим, таба алмыйм. Кайтса, керә алмыйча тилмермәсен дип, көн саен өенә киләм. Дүртенче көнне ул өйдә иде. Исән! Шушы минутта минем ничек сөенгәнне белсәгез! Бөтенесен онытып, кочаклап алдым һәм берничә минуттан шуна үзем дә гажәпләндем.

— Син ничек керден? Ачкыч каян алдың?

— Үзем белән иде берсе.

Кесәдән ачкыч алып аңа суздым.

* * *

Тулай тораккa кайтып әйберләрне алдым да баскычтан йөгерә-атлый төшеп киттем. Шәһәр белән бәйләнеш өзелгән, Лена белән соңгы сүзләр сөйләшелгән. Аста, вахтер ишеге янына житәрәк, бер кыз туктатты. Чем-кара чәчләренә модалы прическа ясаткан, озын, төз — гомумән дөрес гәүдәле чибәр генә рус кызы, занятие вакытында язу жибәргән кыз. Аннан соң аның белән сөйләшә-сөйләшә чират торганыбыз бар. Тик, елга якын вакыт узса да, аңлашу мөмкинлеге тумады. Сәбәбе ачык — йөрәк буш түгел, анда бүтәннәр. Менә шул кыз туктатты мине чыгып барганда.

— Мөмкинме сине бер минутка?

— Мөмкин. Исәнме, Валя.

— Мин синең белән сөйләшергә теләгән идем.

«Ни хакта?» дигән юләр сорау чак кына ычкынмады. Бу сүз белән мин аны мыскыл итәчәк идем. Ул да, мин дә беләбез нәрсә турында сүз булуы мөмкин икәнлеген. Аңлаганымны, сөйләшергә үземнең дә ихтимал баш тартмаска тиешлегемне, үкенүемне төскә һәм тонга чыгарырга тиеш таптым. Бер дә юкка ник кешене рәнжетергә.

— Валя, бездән берни дә чыкмый.

— Ник соң? — дип эндәште ул һәм кулымдагы чемоданга кагылды.

— Мин китәм, Валя...

— Ә ни өчен?

— Мин монда кала алмыйм.

— Ник?

— Сәбәпләрен болай гына әйтеп бетererлек түгел, Валя.

— Ә соңыннан?

— Соңыннан консерваториягә. Бүтән шәһәргә.

Аңлыйм, ул мине китмәскә, калырга үгетли, ачык әйтмичә, читләтеп кенә, күзләре белән генә. Ләкин ул минем нинди кыенлык белән яшәвемне башына да китерми. Ул — шәһәр кызы, матур киенә, хәлләре бөтенләй икенче.

— Хуш, Валентина, мин сине онытмам.

— Яңадан килсән, мине күрерсен...

Һәм ул саубуллашырга кулын сузды. Кулларының йомшаклыгы мина, ни өчендер, Фәһимәне хәтерләтте.

Техникум, анда узган кыска вакыт шул очраклы кыз кыяфәтендә сәтләп калды шикелле.

ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

* * *

Мин авылга кайтам. Әржәсенә унлап кеше төягән калтырча-автомашина шалтырый-шалтырый сикәлтәле юллар буйлап чаба. Авыллар — ямансу һәм хәлсез авыллар — артка шуышалар.

Авыллар...

Сугыш вакытында безнең бу авыллар өстенә бомбалар төшмәде, снарядлар яумады. Ә шулай да карагыз сез теге өйләрне: алар нинди кечерәеп калганнар, имгәнешкәннәр, таякка калганнар. Бомбалар, снарядлар... безгә күренмәделәр, аларның күзгә күренми торганнары яуды безнең өскә. Фронтта яраланган кешеләр үзләре кебек үк инвалид йортларга кайттылар... Күзләре сүнә барган әниләре, аталары, әнеләре, сеңелләре янына.

Сугыш беткән көнне укытучым дөрес әйткән икән: халык монда хәзер дә авыр сугыш кичерә, зур сугыш — ачлык, ялангачлыкка каршы. Бу сугыш бәлки тегесеннән һич ким түгел, ачлык белән сугышудан да кыен сугыш булмый, монда романтика юк, батырларны монда данга күммиләр, эндәшмиләр... ә эндәшмәү — үзе иң каты җәза. Ышанмасагыз, әнә тәрәзәләренә, ишекләренә такта кадакланган, түбәләре жимерелгән, түшәм өсләренә үлән үскән теге өйләрдән сорагыз. Эндәшмәүнең нинди явыз көчләр белән бәйләнгәнен алар сөйләрләр, бөтен дөньяга ишеттерерлек итеп сөйләрләр...

Кичке карангы төшкәндә грузовик безне таныш авылга алып керде. Килмит шушында эшли. Өйләренең дә кайда икәнен чамалыйм. Күнел әллә ничек жилкенеп китте дә кайчандыр бу авыл өстендә әйләнеп йөргән көйләрне уйный башладым. Машина тиз бармый, шофер үзе дә тынлый, ахрысы. Ул чакларда авыл жирендә баян тавышы — экияттән килгән төслерәк иде шул.

Авыл кешеләре, тәрәзәләрдән карап, безне озатып калалар.

Хәтерлим, ул чакта композитор Заһир Исмәгыйловның «Көтәм сине» исемле җыры яңа гына чыккан һәм күнелләрдә матур яңгыраш ала башлаган иде. Иске урамнарда шул яңа көй яңа өмет шикелле таралып калды. Соңыннан көйнең авыл халкы күнелендә онытылмас хисләр кузгатуы хакында миңа кабат-кабат сөйләделәр.

Ул төнне Сафуан абзый да урыныннан торган:

— Хатын, Әнис уйнавы!..

Ишкар авылы. Миңа бик якын бер кеше... Ул ишетәме икән? Бәлки, ул да шушы авылдадыр, кунакка кайткандыр, бәлки, ул да уянгандыр, мине таныгандыр... Мин бит ул ишетсен өчен дә уйныйм, ул тынласын өчен! Хәтерли торгандыр: үзебез генә белгән, аның өчен туган, ана багышланган көйләр. Мин аның янына кайтам! Фәһимә! Нәрсә әйтер? Мин аның күзләренә ничек карармын?

Ишкар калды.

Автомашина бер борылмада туктады. Мин, аннан төшеп, үзебезнең авылга жәяүләп кайттым. Бер кулда иске такта чемодан, икенчесендә баян салынган футляр иде.

Бүтән вакытта мине Шарик исемле этебез каршылый иде, бу юлы ул да күренмәде. Беренче булып каршылаячак дустымны бүреләр алып киткән иде.

Менә шулай, мин чак кына биеккәрәк менмәкче идем, әмма беренче югарылыктан ук егылып төштем. Мондый чакта һәрвакыт туган жиргә егыласын, аннан да ышанычлы урын юк. Соңгы чик... Күккә ашкан таулар арасындагы якты, йомшак үзәнлек төсле. Моннан соң да ничә кабат кайттым мин бу жиргә, ничә кабат егылдым... Туган жир!

Иртән иртүк әни минем өчен мунча якты. Былтыргы миллек белән бик каты чабынгач, юынгач, юл тузаны, ел буе жыелган кер өстән төшкән шикелле булды. Кечерәеп калган өй түшәменә баш бәрелмәсен дип, күрка-күрка гына атлап, хәлдән китеп, кайчандыр үзем йоклый торган караватка утырып, мендәргә сөялдем. Бу хәлдә мин үземне инде бөтен чүп-чардан арынган, чистарынган яңа кеше төсле хис иттем. Дөресрәге, шундый булуымны теләдем.

Минем хәлне белергә керүче беренче кеше Хәмит булды. Онытмый, ташламый, менә ичмасам дуслык. Шулай булырга тиеш ул...

Ярый, мин аны күрүемә шат, билгеле. Тик миңа бүтәннәр дә кирәк. Миңа бер кешене тиз арада күрергә кирәк. Ансыз дөнья каранғы.

...Югары Яркәй авылы. Район үзәге.

Ул шушы урамнардан йөри.

Көн кичкә авышкан. Ул хәзер өйдә булырга тиеш. Кечкенә генә өй. Тәбәнәгрәк кенә жилкапка. Якында гына хатын-кызлар сөйләшкәне ишетелә. Кулларны капка өстенә куеп, эчкә карыйм.

— Әлә́й, Әнис!

Фәһимә тавышы! Әнә ул — аксыл-яшькелт күлмәктән, толымнары, чигә чәчләре... Әллә кечерәеп, ябыгып киткән инде. Тик күрәм: ул тагын да чибәрләнгән, элеккедән дә мең-мең кабат гүзәлрәк... Күзләрендә елмаю, сөенеч очкынлана, тик үзе... карчыгадан куркып әнисенә елышкан чеби төсле, ипташ кызы артына елыша. Ә тегесе ярым пышылдап:

— Синең Әнисме?

— Әйе...

Монда, димәк, минем исемем ят түгел икән әле... Бераз эчкә жылы кергәнен сизеп, мөмкин кадәр игътибарлы эндәшергә тырыштым:

— Капка ачмыйсызмыни инде, шулай итеп?

— Ачаргамы, юкмы дип торабыз әле, — дип тиз генә элэктереп алды ипташ кызы һәм Фәһимәгә карады. — Ярар, килгән кунакны кире жибәрү килешмәс. Кертәсеңме, Фәһимә?

— Керсен алайса, — диде Фәһимә үзенең көчсез, нәзек тавышы белән һәм елмаеп куйды.

Күл биреп исәнләштек. Күзләр, таныш күзләр элекке мәхәббәт белән карыйлар, тик бу күзләрдә ничектер үз итү юк кебек, ул, никадәр яратса да, миңа инде элекке кебек ышанмас... Тел белән әйтә алмаслык тирәндә яшерелгән читсенү... Йөрәгендәге ин изге, иң саф почмагы барыбер минеке түгел хәзер... Мин моны күрми кала алмадым.

Аннан аерылгач булган хәлләрнең барысын да сөйләп бирдем. Алдарга көчем житмәде, намусым житмәде. Гафу итсә, чынлап гафу итсен, әмма безгә ялган катнашмасын.

(Ахыры бар.)

—✦—

Рафаил Төхфәтуллин

ПАРЧАЛАР

Пыяла ватыгы һәм асылташ

Биек бер тау сыртында, бик күренекле урында, ниндидер пыяла ватыгы ята, ә арырак, ком-балчык арасында, затлы асылташ ята икән.

Шулай туры килгән ки, пыяла ватыгына көнозын кояш карый, кояш нуры төшә дә, пыяла ватыгыбыз күзләрне камаштырып ялтырый, кешеләр аңа һәрвакыт сокланып карап үтәләр икән.

Ә асылташ ком-балчык арасында ята, аның затлы нурлары берәүнең дә күзенә чагылмый.

Мактанмаган көне юк икән пыяла ватыгының:

— Бигрәк мескен син, асылташ. Кеше күзенә күренердәй нурың да юк, бу дөньяда җүнле генә урының да юк. Ятасың шунда ком астында мүкләнеп. Ә мине, күр, ничек нур чәчәм! Бу дөньядагы урыным да иң күренекле төштә минем!

— Һмм... Үз урыныңмикән соң ул? — ди асылташ. — Үзең түгел, шул урыныңгына балкый түгел микән соң?

— Чү-чү! Син минем урынга өметеңне сузма! — ди пыяла ватыгы. — Мине бу урынымда берәү дә алыштыра алмый.

— Мин дә хәзергә нәкъ үз урынымда, — ди асылташ. — Биредә мин кояштан һәм олы тау күкрәгеннән үземә чын нурлар җыям. Килер вакыты, мин дә балкырмын.

Һәм ул вакыт җиткән.

Көннәрдән бер көнне, кеше бу биек тау сыртына да менеп җиткән. Менеп җитүгә, әлбәттә, иң элек пыяла ватыгына үрелгән. Аннары, чын-чынлап эзли торгач, асылташны да табып алган.

Кеше асылташтан искиткеч гүзәл нурлар чәчүче йолдыз ясаган. Бу йолдыз хәзер дә иң зур мәйданнарның берсендә, иң биек манарада, кешеләрне сокландырып балкып тора.

Ә пыяла ватыгын кеше ваклап төйгән дә, тагын ниндидер ком-ташлар кушып, үзенең коралларын үткерли торган кайрак ясаган.

Асылташ белән пыяла ватыгы, әнә шулай, үзләренең чын урыннарына утырганнар.

Ике көймә

Ике көймә, инешләр-елгалар буйлап, олы диңгезгә җитү өчен, юлга җыенганнар.

— Юк, мин үзем генә юлга чыкмыйм, мин үземә ипташкә ишкәкләр дә алам, — дигән көймәләрнең берсе.

— Һи, кирәге бар иде, — дигән икенче көймә. — Мин агым уңаена рәхәтләнеп үзем генә йөзәчәкмен. Ишкәкләр мине, үгетли-өйрәтә, гел алга куаламый торсыннар әле. Ялгыз башым — тыныч күңелем.

Шулай итеп, юлга чыкканнар булар — ишкәкле көймә һәм ишкәксез көймә. Шуннан соң...

Хәер, шуннан соң ни булганы болай да сизелә бугай. Агым уңае белән генә агып барып олы диңгезгә җитүчеләрне минем дә һичвакыт күргәнем юк.

Яшьлек сере

Ике кыз туган, үсеп буйга җиткәч, укып чыгып кулларына дипломнар алгач, икесе илнең ике ягына эшкә киткәннәр. Аралар ерак булгангамы, әллә эшләре-мәшәкатьләре күп булгангамыдыр, бик озак очрашмый торганнар булар.

Бервакыт, очрашсалар, икесенең дә күзләренә, иң беренче, менә нәрсә ташланган: сеңелесе һаман да яшь, һаман да чибәр, ә апасы шактый картая төшкән.

Күпмедер еллардан соң, тагын очрашканнар алар. Һәм тагын шул ук хәл: сеңелесе һаман да яшь, һаман да чибәр, ә апасы тагы да картаебрак киткән.

— Һич картая белмисең син, сеңелем, — дигән апасы, сокланып. — Гел яшәрә, тагы да чибәрләнә генә барасың.

Моны ишетүгә, сеңелесе, бик шатланып, апасын кочаклап алган.

— Апа, бу сүзләреңә белән син миңа бер серне әйтеп бирдең бит. Моңарчы мин үзем дә аңламый йөргән серне әйттең дә бирдең.

— Нинди сер ул, сеңелем? Бәлки, миңа да ачарсың?

— Ачам, апа, ачам. Ачмыйммы соң!.. Әйт әле, апа, эшкә килгәч яки дусларың-танышларың очраганда, сиңа, иң беренче, нәрсә диләр?

— Нәрсә дисеннәр... «Картаебрак киткәнсең әле», диләр, «ябыга төшкәнсең, әллә авырыйсыңмы?», диләр.

— Менә шул шул, апа. Ә миңа эшкә килсәм дә, дусларым-танышларым очраса да гел: «Яшәреп киткәнсең әле син», диләр, «көннән-көн чибәрләнә барасың», диләр. Шуңа күрә картлык минем күңелемә якын да килә алмый. Кешеләрнең шул яхшы сүзләре саклый икән ич мине картаюдан. Их, апа, яшьлекнең бу гап-гади серен дөньядагы барлык, барлык кешеләр дә тизрәк кенә белсеннәр иде!

—✦—

Балаларга укыгыз

Шәүкәт Галиев

Пәрәмәч...

Бүген минем туган көн,
Бәйрәм була торган көн.
Сорады әни иртән:
— Нәрсә пешерим икән?

— Пәрәмәч, — диде әти,
— Бәлеш, — диде дәү әни.

Э мин киттем камырга,
Ашханәдән алырга.
Әнкәй кисәтте мине:
— Кайтканда ашык, — диде, —
Чыкмасын ташып! — диде.

Карадым камыр алгач,
Сатучы үлчәп салгач —
Бидоным тулыр-тулмас,
Ташымас, берни булмас!

Гәҗитләр карый-карый,
Морожный ялый-ялый,
Киттем кайтыр укайга,
Утырдым трамвайга.

Шулай кайтып килгәндә,
Капкач төште идәнгә.
Күрәм шунда: агарып
Камыр чыга кабарып!
Тиз генә этәм-төртәм,
Савыт эченә кертәм.
Э камыр гүя тере —
Килә дә чыга кире!
Ул үзе шундый үзле,
Үзе үзле, үзсүзле,
Бик басып тутырсаң да,
Өстенә утырсаң да,
Мөмкин түгел тыярга,
Уйламый да сыярга...

Булса да беретым жәл,
Калмады бүтән әмәл, —
Салдым камырны өзеп...
Ул чыга һаман сөзеп!

Пиджакта да, чалбарда
Кесәләр тулы бар да...
Анда да бит кабара!
Мин тотындым чабарга...

Бар җирдән камыр ташып,
Торам ишектә басып.

Әйтә алмыйча берни
Бот чабып куйды әни.
— Пәрә-мә-әч!.. — диде әти,
— Бә-ә-әлеш!.. — диде дәү әни.

Тилгән килгән шәһәргә

Авылда очкан тилгән,
Басуда очкан тилгән,
Оча торгачтын тилгән,
Шәһәргә очып килгән.
Бик күп йортларны күргән,
Түбәсе күккә тигән:
— Бәбкәләр күптер, дигән,
Чебешләр күптер, дигән.

Оча тилгән эчкәрәк,
Күренми бит һич тә рәт —
Йортлар йортка тоташкан,
Урамнары гел таштан,
Юк чирәм үскән төшләр,
Бәбкәләр һәм чебешләр...

Кәеф тәмам кырылып,
Китим дисә борылып,
Бер бәбкә күрә комда,
Атылып төшә шунда,
Эләктерә дә ала,
Күккә менеп югала,
Кешеләр күрми кала...

Тоя ул менгән шәпкә —
Бик каты бит бу бәбкә!..
Яхшылабрак караса,
Ул алданган лабаса!
Әй, ачуланган тилгән:
— Пластмасса ич бу! — дигән.

Табын янында

Иртә белән табында
Әткәй әйтте тагын да:
— Юньләп ашарсың микән,
Коймый башларсың микән?
Ахры, синең күкләргә
Тавык кирәк чүпләргә!

Э инде төш чагында
Мактап куйды табында:
— Өстәл яның чиста, ди,
Ашарга син оста, ди...

Чак кына көлми калдым —
Хәйләмне белми калды,
Тавыкны күрми калды!

Хәйләкәр курчак

Гөлкәй белән Гөлбикә
Чыршы бәйрәмен көтә.
Гөлкәй зуррак — ул апа,
Сеңелесенә аңлата:
— Чыршыларга эленер
Тәмле-тәмле конфет, — ди, —
Явып торыр һавадан
Төрле-төрле конфетти!

Гөлбикә тыңлап ята,
Курчагына аңлата:
— Чыршыларга эленер
Төрле-төрле конфетти,
Явып торыр һавадан
Тәмле-тәмле конфет! — ди.

Курчагы дәшми, тынлый,
Кузгаткан иде — «җылый».
— Нәрсә булган, ник җылый?
— Хәзер үк конфет сорый!

«Сәгать йоткансың!»

Кафия халат кия:
— Мин врач булдым! — дия.
Каршысына бастыра,
Авызыңны ачтыра.
Иелә дә чак кына,
Суламасаң, «Сула!» дип,
Суласаң, «Сулама!» дип,
Күкрәкне тыңлап тора.

Тукта, ник курыккан соң,
Уенны онытқан соң?
— Тек-тек йөри эчендә,
Син,— ди,— сәгать йоткансың!?

Кайнар шугалак

Тимераякта шуарга
Чыктым мин тротуарга.
Кешеләр эссе диләр,
Кешеләр әлсериләр,
Зонтик тотып йөриләр.
Мин барам җил уйнатып,
Кулларны атып-атып.
Ялан аяк малайлар
Минем белән ярыша.
Күлмәк салып чапса да,
Алар миннән калыша.
Беләм җитәлмәсләрен —
Җитез тәгәрмәчләрем!

Борау-сорау

Сорамадым соравын,
Алдым бабай боравын.

Нинди файда эшләсе,
Кайда, нәрсә тишәсе?

...Күреп җирдә ятканны,
Тиштем шома тактаны.
Ә аннары — капканы:
Кем уйган ишек, диеп,
Җайлы соң ничек, диеп,
Йөрерләр бал кортлары,
Бакчада бит йортлары.

...Җиләс һава керсен дип,
Өф-өф итеп өрсен дип,
Өчне тиштем бишеккә,
Бишне тиштем ишеккә.

Инде тагын нишләсе,
Кая тишек тишәсе?
Бигрәк нык икән мичкә,
Көчкә җиткердем эчкә.
Сиптереп торгач шулай,
Су алырга бик унай.

Борауны борам, борам,
Борам, остара барам!
Боравымны кулдан алып,
Колакны борды бабам...
Сезгә бирәм сорауны —
Ник алды ул борауны?

Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел

Латыйф Гомәров

УЛ ЗУР ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ ИДЕ

1919 елның ахырыннан алып 1927 елның апрель аена кадәр Галимҗан Ибраһимов Казанда төрле жаваплы эшләрдә эшләде. Партия мәктәбендә, командирлар курсларында, татар коммунистлар университетында укытучылык итте. Мәгариф комиссариаты коллегиясе члены һәм Гыйльми үзәк председателе булып эшләде; «Безнең юл» журналы редколлегиясе председателе, «Мәгариф» журналы редколлегиясе члены, Крайны өйрәнү бюросы председателе вазифаларын үтәде. Шулардан тыш, партиянең Өлкә Комитеты карары буенча, башка төрле комиссияләргә дә тартыла иде ул.

Мин ул вакытта партиянең Татарстан Өлкә Комитетында матбугат бүлеге мөдире булып эшли идем. Эш буенча рәсми очрашулар белән бергә, миңа Галимҗан Ибраһимов белән Ленин әсәрләрен татар теленә тәржемә итеп чыгару комиссиясендә эшләргә дә туры килде.

Ул елларда Г. Ибраһимов бик зур дәрт белән эшләде. 1924 елдагы бер очрашу минем хәтердә тирән эз калдырган. Бер көнне ул үзенең Өлкә Комитеты матбугат бүлегенә килүе турында телефоннан шәлтыратты һәм, озак көттермичә, килеп тә керде. Бүлмәгә кереп, кул биреп исәнләшкәч, эшләпәсен, җәйге пальтосын салды да чәчләрен тарап алды. Күңеле бик күтәренке иде. Хәл-әхвәл сорашкач, эшкә керешкәнче, ничектер үзе турында сөйләп китте. Яшь вакытларында, дәртле, жегәрле булуына карамастан, канат жәеп эшләргә мөмкинлек булмаганын әйтте. Мәдрәсәдән куылуын, Киев төрмәсендә ятуын исенә төшереп, анда булган вакыйгаларны сөйләп алды. Революциядән соң төрле агымнар һәм төрле партияләр арасында үзенең дөрес юлны ничек эзләвен, аны бары большевиклар партиясендә, аның программасында һәм тактикасында гына тапканлыгын әйтте:

— Беләсезме, — диде ул, — минем большевиклар партиясенә рәсми рәвештә керүемә, аның сафында торып эшли башлавыма Владимир Ильич Ленинның тәэсире бик зур булды. 1918 елда, Мулланур Вахитов Кызыл Армия батальоны белән Казанга, ак чехларга каршы сугышка киткәч, мин Ленинда приемда булдым. Ана үземнең үткән юлымны һәм политик карашларымны сөйләп бирдем. Владимир Ильич мине бик игътибар белән тыңлады да: «Эшләгез», диде. Беләсезме, Латыйф ияптәш, менә бу бер сүз, беренче карашта бик гади генә булып күренсә дә, бөтен язмышымны хәл итте. Димәк, Владимир Ильич миңа ышана, мин үземнең практик эшемдә аның политикасын, ул төзегән партия политикасын дәвам иттерәм, дип уйладым. Аның яныннан канатланып чыгып киттем. Менә бит ул бер сүз!..

Аннары без Ленин әсәрләрен татарчага тәржемә итү планы турында сөйләшүгә күчтек. Бу комиссиядә Галимҗан ага бик тырышып эшләде. Ул эшне уңышлы рәвештә башкарып чыгу өчен, Ленин әсәрләренең эчтәлеген яхшы белергә кирәк иде. Галимҗан ага аларны үз вакытында басылып чыккан берен укып барган булса кирәк, яхшы белә, Ленинның кайсы әсәрләрендә нинди мәсьәлә турында сүз баруын да хәтерли иде. Кыскасы, комиссиянең бик лаеклы председателе булды ул...

Билгеле булганча, хәзерге «Казан утлары» журналы элек «Безнең юл» исеме белән чыга иде. Аның жаваплы редакторы Галимҗан Ибраһимов булды. Бер көнне (1926 елның башында булырга кирәк) Галимҗан ага, партия Өлкә Комитетының матбугат бүлегенә килеп, журналның эчтәлегеннән канәгать булмавы һәм аның тиражының кечкенәлеге турында сөйләде:

— Язучылар һәм бер төркем журналистлар журналы гына түгел бит ул, бөтен республика журналы, партия журналы! Алай гына да түгел, бөтен Советлар Союзындагы татарлар өчен чыгарыла торган бердәнбер әдәби, иҗтимагый һәм политик журнал. Аңа бик нык игътибар итәргә кирәк. Партия Өлкә Комитетының журналга игътибары җитәрлек түгел, партия оешмалары төрле журналларны алдыралар, әмма алар арасында «Безнең юл» юк, — диде ул.

Бу турыда ул борчылып сөйләде, хәтта ачулана язды. Аннары бу мәсьәлә 1926 елның 25 январенда матбугат бүлеге коллегиясендә каралды. Анда Галимжан ага «Безнең юл» турында доклад ясады, аның эчтәлеген яхшырту, материаль хәлен ныгыту, журналны партия членнары арасында күбрәк тарату мәсьәләләрен алга куйды. Утырышка чакырылган иптәшләр дә (Гомәр Галиев, Фатих Сәйфи, Шәрәф Фәхретдинов, Сәлах Атнагулов, Фәтхи Бурнаш һ. б.) Г. Ибраһимов фикерләрен якладылар, күп кенә яхшы тәкъдимнәр керттеләр. Соңыннан карар кабул ителде, партиянең район оешмаларына журналга игътибарны көчәйтү турында Өлкә Комитетының беренче секретаре иптәш Морозов имзасы белән хат җибәрелде һәм башка чаралар күрелде. Журналның яңа редколлегиясе билгеләнде, аның составына Галимжан Ибраһимов, Гомәр Галиев һәм Гаяз Максудов кертелде (Партархив, ф. 15, д. 459, л. 79).

Галимжан Ибраһимов һәрвакыт яшь язучылар, яшь әдипләр әзерләүгә, аларны өстүрга, пролетариат идеологиясе рухында тәрбия итүгә зур әһәмият бирә иде. Ул елларда яшь язучылар арасындагы «футуризм», «имажинизм», «символизм» кебек әдәби агымнарның булуына, «Сулф», «Октябрь» исемнәрендә йөри торган төркемнәрнең килеп чыгуына бик нык борчыла һәм шул уңай белән партиянең Өлкә Комитеты матбугат бүлегендә үткәрелә торган киңәшмәләрдә актив катнаша, зарарлы агымнарга каршы кискен чыгышлар ясый иде. 1927 ел башларында ул Өлкә Комитетының матбугат бүлегенә түбәндәге язуны җибәрде:

«ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ МАТБУГАТ БҮЛЕГЕНӘ

«Татар әдәбияты җәмгыяте» турында

Бу хактагы заявлением буенча, мәсьәлә 1927 елның 25 гыйнварда үткән җыелышта каралырга тиеш булса да, кичеккән иде. Үтенәмен якын арада каравыгызны. Чөнки эшкә башларга кирәк. Бу хакта минем әзерләгән докладым һәм җәмгыятьнең нигез моментлары турында язылган уставым тәкъдим кылынадыр.

Гыйнвар, 26».

Галимҗан Ибраһимов.

(Партархив, ф. 15, д. 465, л. 55.)

Г. Ибраһимовның шушы язуы уңае белән 1927 елның 9 февралендә матбугат бүлегендә махсус киңәшмә үткәрелде. Бу киңәшмәдә Г. Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш, Галимҗан Нәгъмәти һәм башкалар катнаштылар. Г. Ибраһимов рус телендә «Об ассоциации татарских литераторов» («Татар әдипләренең ассоциациясе турында») дигән доклад ясады. Докладында ул татар язучыларының иҗатлары, аларның политик карашлары, әдәбияттә тоткан урыннары турында сөйләде. Соңгы елларда яшь һәм карт язучылар арасында төрле агымнарның көчәюен, бу мәсьәләдә әлегә чаклы бер ныклы оешманың булмавын, «Октябрь», «Сулф» һәм башка шундый түгәрәкләрнең килеп чыгуын, ләкин аларның озак яши алмауларын күрсәтеп үтте. Иҗатлары белән Совет властена хезмәт итүче барлык карт һәм яшь язучыларны, нинди формаль төркемгә керүләренә карамастан, барысын бер әдәби оешмага туплап, бу оешмага һәм матди һәм мәгънәви ярдәм итәргә кирәклекне әйтте. Аның фикеренчә, бу оешмага бер Татарстан язучылары гына түгел, бәлки Советлар Россиясендәге барлык татар язучылары керергә тиеш иде.

— Бу оешма, — диде Г. Ибраһимов, — төрле әдәбиятларны һәм әдәбияттагы төрле агымнарны өйрәнергә, башка оешмалар белән бәйләнештә булырга, юридик шәхес буларак, әдәби әсәрләр бастырып чыгару хокукы белән файдаланырга, ләкин пролетариат идеологиясе нигезеннән чыкмаска тиеш.

Бу турыда озак фикер алышканнан соң, тиешле карар әзерләү өчен, комиссия төзелде һәм аны җыю эше Галимҗан агага тапшырылды.

Әдипнең тырышлыгы нәтиҗәсез калмады. Соңыннан, ул авырып Кырымга киткәч, татар совет Язучылары оешмасы төзелде һәм 1932 елның маенача, ягъни партия Үзәк Комитетының әдәби оешмалар турындагы карары чыкканчыга кадәр яшәде.

Г. Сафиуллин,

Советлар Союзы Герое, запастагы генерал-лейтенант.

Совет Армиясе гаскәрләренең көчле һөҗүмен тоткарлау өчен, немец-фашист командованиесе Днепрга зур өмет бәгләде: ягъни, бу «Көнчыгыш валы» фашист гаскәрләрен һәлакәттән саклап калырга тиеш иде.

Тәҗрибәле инженерлар җитәкчелегендә фашистлар елганың уң як ярын нык ныгыту буенча зур эшләр башкардылар. Гитлер һәм аның ставкасы елганың киңлеген дә, күп сулы, тирән булуын да, су өсте уч төбе кебек күренеп торган, ныгытылган тик ярын да — барысын да исәпкә алып, шундый зур су киртәсен үтү өчен, совет гаскәрләренә бик озак вакыт кирәк булачак, дип уй йөртте. Болардан тыш, дошман уенча, совет гаскәрләренең зур тизлек белән һөҗүм итеп килүләре нәтиҗәсендә, елганы кичү кирәк-яраклары бик ераста артта калган булырга тиеш иде. Безнең гаскәрләр Днепрны кичү мәшәкатьләре белән үткәргән вакыт эчендә, дошман чигенгәндә таркалган гаскәрләрен тәртипкә китерергә, тулыландырырга, яңа пехота, танк, авиация берләшмәләрен туплларга исәп тотты һәм, алар ярдәмендә совет гаскәрләрен озак вакытка тоткарлап, үзе Англия һәм Америка белән сепарат солых договоры төзәргә уйлады.

Әмма дошманның исәбе барып чыкмады: сентябрь ахырында совет гаскәрләре җиде йөз километр киңлектәге арада Днепрга килеп җитте. Үзәк фронт гаскәрләре, Десна елгасын кичеп, 22 сентябрьдә Припять елгасы тамагы турысында Днепрга чыктылар. Ә Воронеж фронты гаскәрләре Переяславль-Хмельницк районында 21 сентябрьдә Днепрга килеп җиттеләр. Армия генералы И. С. Конев командалыгындагы Дала фронты армияләре дошманның 16 дивизиядән торган көчле группировкасын туздырып, Полтава шәһәрен азат иттеләр. Кременчуггтан көньяк-көнчыгыштарак 130 километр киңлектә Днепр ярына барып җиттеләр. Көньяк-көнбатыш фронты гаскәрләре 22 сентябрьдә Днепропетровск белән Запорожье арасында дошманны елганың уң ягына алып ташладылар.

Генерал М. С. Шумиловның 7 нче гвардия армиясе корпуслары Перевалочная белән Орель елгасы арасындагы 30 километрлы фронтта Днепр ярына җитте. Бу армиянең үзәгендә, төп удар юнәлешендә, составында 72 нче һәм 81 нче гвардия дивизияләре булган безнең 25 нче укчы корпус хәрәкәт итә иде.

Корпусның Днепрга чыгуы сугышчыларда зур күңел күтәренкелеге тудырды. Бер сәгать тын алганнан соң, кичүгә әзерләнергә керештек. Кичү кирәк-яракларының килеп җитүен көтеп тормадык, подразделениеләрдә берәүләр такталар, ишекләр, башка төрле агач-могачны — кыскасы, ни туры килсә, шуны әзерләделәр, икенчеләре алардан җиңелчә саллар әмәлләделәр, өченчеләре балыкчы көймәләре эзләп китте.

Елганың сул ягында һаман миналар шартлый, пулеметлар такылдый иде әле. Утрауларга ныгып урнашкан дошман гарнизоннары белән көчле сугыш дәвам итә иде. Шуна да карамастан, инженер-полковник К. П. Соколов белән корпусның разведка бүлеге начальнигы майор И. А. Воронцов яр буена киттеләр.

— Елгага килү юлларын, туплану һәм кичү урыннарын үз күзебез белән тикшерик, бәлки, бүген үк разведчикларны уң як ярга күчерергә мөмкин булыр, — диде анда китәр алдыннан Воронцов.

Корпусның штаб начальнигы полковник А. Д. Овсянников барлык мәсьәләләрне урыннарда хәл итәргә күнеккән, югарыдан күрсәтмә көтәргә яратмый иде. Үзенең ярдәмчеләренә штабны урнаштыру һәм маскировкалау буенча бәерыклар биргәч, ул

72 нче гвардия дивизиясенә китеп барды. Бер сәгатьтән соң инде ул миңа яр буеннан шатлыклы хәбәр жибәрде.

— «Восточный» утравы алынды. Әсирләр дә бар. Утрауга телефон урнаштырыдды, прямой буенча сөйләшергә мөмкин. Әгәр дә сез каршы килмәсәгез, сезгә һәм 72 нче дивизия командирына күзәтү пунктын биредә әзерләргә булдым. Утраудан уң як яр, андагы курганнар, Барадаевка авылы яхшы күренә. Дошман үзе күренми, ләкин ерактан 150 миллиметрлы батареядән утрауларга атуын дәвам итә,— дип язган иде ул үзенең донесениесендә.

Мин штаб начальнигы тәкъдимен хупладым. Ул вакытта инде 81 нче гвардия дивизиясенең разведка отряды, Днепрның беренче тармагын кичеп, «Западный» утравына урнашкан һәм уң як ярны каплап торучы дошман белән сугыш алып бара иде.

Минем замполит, полковник Алексей Петрович Колесник, политбүлекнең башка работниклары белән, полкларда эш алып бардылар, партия һәм комсомол жыелышлары үткәрделәр, Днепрны кичү һәм плацдарм яулап алу буенча алда торган бурычларны сугышчыларга аңлаттылар.

Кичке 5 кә корпусның тыл хезмәтен күрсәтүчеләре, медсанбатлары да билгеләнгән урынга килеп житте.

Корпусның артиллерия командующие полковник Журавлев һәм аның күл астындагы офицерлар артиллерия частьларының урнашуларын тикшерделәр. 19 сәгатьтә полковник Журавлев миңа укчы полклар белән бары тик полк артиллерия һәм миномет батареяләре генә килеп житүен хәбәр итте. Аның исәпләве буенча, дивизия артиллерия полклары һәм безнең карамакка бирелгән 263 нче һәм 290 нчы аерым миномет полклары бер сәгатьтән соң гына килеп житәргә һәм Яңа Орлик районына урнашырга тиеш иде.

Мин ана иртәнгә кадәр дивизия һәм корпус артиллерия группалары өештыру мөмкинлекләре, артиллерия полкларын снарядлар белән тәэмин итү чаралары турында уйланырга, әгәр дивизияләр Днепрны һөжүм итеп барган унайга кичә алсалар, артиллерия әзерлеге графигы төзергә һәм барысы турында да хәбәр итәргә куштым.

— Армия командующие боларның барысы турында да кызыксыныр. Доклад әзер булсын,— дидем мин аңа.

— Иртәнгә әзер булыр,— диде полковник.

Мин, замполит Колесникны эзләп, 81 нче гвардия дивизиясенә, Крамаровка авылы читенә киттем. Полковник Колесник һәм дивизия партия комиссиясе секретаре партиягә һәм комсомолга кабул итү мәсьәләләре белән мәшгуль иде.

— Сез кайда йөрисез, Алексей Петрович? Иртәдән бирле күргәнем юк.

— Һөжүм вакытында хәл ителәсе эшләр бик күбәйде, ә Днепрга чыккач, алар тагы да артты,— дип жавап бирде ул, елмаеп.— 72 нче дивизиядә булдым, офицерлар киңәшмәсенә катнаштым. Хәзер менә партиягә һәм комсомолга алуны сорап биргән гаризалар белән танышам. Эш тә эш...

Колесник, блокнотына карап, Лосев дивизиясендә партиягә алуны сорап — 78, комсомолга — 128, ә Николаев дивизиясендә партиягә — 38, комсомолга — 134 гариза кергәнлеген хәбәр итте. Хәзер, һөжүмгә күчмәс борын, аларның барысын да карарга, кабул ителгәннәргә шунда ук партия һәм комсомол билетлары тапшырырга кирәк иде. Партиягә һәм комсомолга алуны сорап гариза бирүчеләрнең барысы да сугышларда үзләрен батырлыклары белән таныткан, орденнар, медальләр белән бүләкләнгән солдатлар, сержантлар һәм офицерлар иде.

Николаев белән Лосевка телефон аша 18.30 сәгатькә минем күзәтү пунктына килергә кушып, штабка киттек.

Штаб начальнигы А. Д. Овсянников анда иде инде. Ул машиналар өчен әлегә кадәр чокырлар һәм щельләр әзер булмаганга, комендантны, оператив дежурныйларны кыздыра иде.

— Егерме минутта барлык машиналар чокырларда булсын,— дип әмер бирде ул ачулы тавыш белән аларга.— Личный состав өчен щельләр казылсын! Барысын да маскировкаларга — һавадан гына түгел, жирдән дә егерме адымнан һични сизелмәслек булсын!..

Минем тирәдә ординарец Сидор Новгородов белән повар Рәхимжанов чуалырга кереште. Ординарец, унай момент туры китереп:

— Сез бүген ашыйсызмы, юкмы?— дип сорады. Ана кушылып повар да мыгырданды:

— Барысы да ашап-эчеп туйдылар. Сезнең генә вакыт юк, имеш...

* * *

Дивизия командирлары Лосев белән Николаев:

— Сезне урман юлы чатында көтәбез,— дип шалтыраттылар. «Виллис»ны калдырып, урман сукмагы белән «Восточный» утравына таба жәяүләп кенә киттек.

Юлда егермедән артык әсирне озата баручы 222 нче гвардия полкы сугышчылары очрады. Алардан сорашып «Восточный» утравында дошманның 106 нчы пехота дивизиясеннән бер рота оборона тоткан булуын, ә «Западный» утравы һаман да фашистларның 320 нче дивизия составына кергән батальон кулында булуын белдек. Бу

дивизияләренең калган частьлары Днепрның уң як ярына, Барадаевка авылына, чигенгәннәр. Утрауларда оборона тотучы немецлар төп көчләренең елганы кичүен капланторырга тиеш булганнар һәм аларга теге якка кичү өчен бернидә калдырылмаган. Шуна күрә алар ахырга кадәр каршылык күрсәтәләр икән.

Крамаровка һәм Иске Орлик — икесе дә зур, матур авыл. Йортлар, каралтылар яфракларына сары төшә башлаган бакчаларга күмелгән. Бакчаларга тоташып нарат урманы башланып китә. Без шул урман белән барабыз. Ылысның хуш исен күкрәк тутырып сулыйбыз. Саф урман һавасы арыган буыннарга хәл кертә, аяклар үзләреннән-үзләре кызурак атлый.

Һава салкыная башлады — су якынлыгы үзен сиздерә. Ординарецларны машинада калган шинельләрне алып килергә йөгертергә туры килде.

Урманнан чыккач, утрауга керү юлындагы контроль постында безне полковник К. П. Соколов белән разведка бүлеге начальнигы майор И. А. Воронцов каршылады. Алар безне күзәтү пунктына озаттылар.

Урманнан пычкылар чыжлавы, балта тавышлары ишетелеп тора. Сугышчылар елганы кичү өчен саллар ясыйлар, аларны яр буена китерәләр. «Западный» утравы ягында атыш тавышлары дәвам итә.

Тулган ай якты сында тын елга өсте көзге кебек ялтырап ята, кара күләгәләр булып утраулар калкып тора, теге якта, биек яр башында, Барадаевка авылы күренә, калку курганнар еракта, шактый күптән баеган кояш нурлары кызыллыгына төренеп, офыкка барып тоташалар.

Алдыбызда — безнең өчен бик кадерле булган чал Днепр. Днепрның гаҗәеп матур төнге табигате тәэсиреннәндерме, шушы матурлыкка ия булган туган илебез белән горурлану хисеннәндерме, күнелләр ничектер нечкәреп китте. Барыбыз да, бу бөек елгага текәлгән килеш, тынып калдык... Теге якта фашист табаны астында күпме ватандашларыбыз, туганнарыбыз җәфа чигә әле...

Корпусның кичү полосасында Днепрда ике утрау бар. Картада алар «Барадаевка утраулары» дип исемләнә. Сугышчылар аларга үзләренчә — якынына «Восточный» дип, ераграгына «Западный» дип исем куштылар. Аларның икесе дә куе урман, куаклык белән капланган. «Западный» утравының буе ике, аркылысы ярты километр. Утрауларның икесе дә яр буеннан зур Днепрның тармаклары белән аерылган. «Западный»га кадәр тармак тирән һәм көчле агымлы, киңлеге 300 метр. Утрау ярыннан ук ярга кадәр километр ярым киңлегендә елганың төп үзәне уза.

Дошман чигенгәндә елганы «Восточный» утравы аша кичкән. Анардан бары тик җәяүләп йөрерлек кенә такта күперчек калган. Артиллерия өчен кичү урыннары шартлатылган.

Курганнар артыннан дошман елга өстенә прицелсыз-нисез 150 миллиметрлы орудиеләрдән снарядлар яудыра.

Елганың уң ярында, тау итәгендә, дошманның беренче траншеясы, ә тау өстеннән 114,5 һәм 147,4 биеклекләре буйлап чәнечкеле тимер чыбык киртәләр белән уратылган икенче траншеясы сузыла. Дзотлар, орудиеләр һәм миномётлар өчен әзерләнгән позицияләр бик күп күренә.

— Әйе, — диде генерал Лосев, — немецлар нык тырышканнар. Яр буйларын җирәнә җиткереп ныгытканнар. Ә Барадаевка тагы да көчлерәк ныгытылгандыр...

Авылда һәм траншеяларда беркем дә күренми. Уң як яр буе тып-тын.

Безнең янга полковник Соколов белән майор Воронцов килде.

— Иптәш генерал, инженер разведкасы нәтиҗәләре турында хәбәр итәргә рөхсәт итегез, — дип мөрәҗәгать итте миңа Соколов.

Мин рөхсәт бирдем.

— Мин «Восточный» утравының көньяк чите турысы кичү өчен ин уңай урын дигән фикергә килдем. Туплану районы да дошманга күренерлек түгел.

Без аның фикере белән килештек.

— Җәяүле күперне ремонтлагыз, ә тармак аша юлга чыбык-чабык җәегез, — дидем мин. — Моны иртәгә кадәр эшләргә кирәк. Кичү җайланмалары белән тәэмин итү мәсьәләсен дә тикшерегез.

Воронцов «Западный» утравында ныгып урнашкан 300 ләп немец солдатын һәм офицерын юк итү өчен өстәмә көчләр җибәрүне сорады. Ул хаклы иде. Ләкин кешеләр кайдан алырга соң? Дивизияләрдән батальон түгел, рота алу да полкларны зәгыйфьләндерү дигән сүз. Аларны плацдарм өчен сакларга кирәк.

Мин армия командующиена шалтыраттым, аңа шәхси рекогносцировка нәтиҗәләре һәм шартлар турында хәбәр иттем.

— Утраудагы разведотрядны көчәйтү өчен армия резервыннан файдаланырга рөхсәт итәм, — диде Шумилов. — Отряд командиры белән бәйләнешкә керегез, бурыч куегыз һәм утрауга чыгарыгыз. Корпус елганы кичәргә керешкәнче, утраудагы гарнизонны юк итегез.

Штабтан А. Д. Овсянников корпус дивизияләре һәм корпус карамагына бирелгән частьлар командованиесенең иртәгә сәгать 10 га командующий күзәтү пунктына җыелырга приказ алынганлыгын әйтеп шалтыратты.

— Елганы кичәргә приказ булыр, ахры, — диде Лосев...

* * *

Ай, курганнар артына кереп, күздән югалды. Тирә-як кап-караңгы һәм тып-тын иде.

— Кирпеч заводы тирәсенә разведка җибәреп, тәвәккәлләп карыйк, — дидем мин генерал Лосевка. — Нигә вакытны юкка уздырырга?

— Мин каршы түгел. Үзем дә нәкъ шул турыда уйлап тора идем. Командующийга әйтикме?

— Хәзергә әйтеп тормыйк. Әгәр беренче траншеяда дошман оборона тота икән, үзен сиздерер: разведчикларны ут белән каршы алыр. Әгәр юк икән, бик яхшы, разведчиклар анда оборона оештырырлар. Аннары разведчикларны көчәйтербез. Командующийга иртәгә иртән хәбәр итәрбез.

— Әйе, кайчан булса да барыбер кичүне башларга кирәк. Никадәр соңрак булса, шулкадәр начаррак. Дошман без елгага чыкканны белә, иртәгә резервлар китерүе һәм яр буен тагы да ныгытуы мөмкин, — диде Лосев, минем фикерне куәтләп.

— Кайсы полктан башлыйсыз? — дип сорадым мин.

— Подполковник Баталов полкыннан, 229 нчыдан.

Подполковник Баталов тыныч характерлы, нык уйлап эш итүчән һәм шул ук вакытта бик кыю командир булып, аңа чын-чынлап ышанырга мөмкин иде.

А. И. Лосев Баталовка шалтыратты, аңа разведвзводтан бер төркем иң кыю разведчиклар сайларга кушты.

Кырык минуттан безнең күзәтү пунктына Баталов һәм өлкән сержант Георгий Фокин командасы астында җиде таза, нык, җитез сугышчы һәм бер сапер килеп җитте. Георгий Фокин дивизиядә үзенең куркусызлыгы, җитезлеге, зур тәҗрибәгә ия булуы белән дан тота, аның турында армия газеталары яза, листовкалар чыгарыла иде.

— Разведчиклар елганы уңышлы кичәләр, аргы якка аерым отряд та күчерергә мөмкин булыр. Көчәйтелгән рота һәм аның өчен йөзү кирәк-яраклары әзерләгез, — дип боерды Лосев Баталовка.

24 сентябрь төне. 23 сәгать. Шомлы тынлык. Елга өзлексез ага, урыны-урыны белән тирән чоңгылларга очрап, зыр-зыр болганырга тотына, аннан котыла да тагын дәртләнеп, омтылып алга ыргыла.

Өлкән сержант Георгий Фокин, өлкән сержант Николай Попов, сугышчылардан: Павел Ржевский, Александр Анохин, Пристенский, Николай Черных һәм сапер Александр Казаков утырган көймә тавышсыз гына «Восточный» утравыннан кузгалып китте. Ике кул пулеметы, автоматлар, танкка каршы гранаталар, ящик белән патроннар — батыр разведчикларның кораллары шул гына. Ә капчыкларда — «НЗ», азык-төлек.

Менә көймә Днепр уртасына килеп җитте. «Западный» утравыннан аларны күрделәр, пулеметлар ут ачтылар. Ләкин ара ерак иде, пулялар көймәдән 100—150 метр читтә суга сибелделәр.

Уң як ярда һаман шомлы тынлык хөкем сөрә. Көймә тиешле юнәлештә тын гына юлын дәвам итә.

Аргы якта дошман бөтенләй юкмы икән әллә? Әллә сизмиләр генәме? Без, тыныбызны алырга да куркып, көтәбез.

Бер сәгатькә якын вакыт үткәннән соң, Александр Казаков кайтып төште.

— Разведчиклар кирпеч заводы каршында кинлеге 100 метр, тирәнлеге 80 метр арада плацдарм алдылар. Сул тармак белән уң тармак кушылган урында агым бик нык көчәя. Идарәне нык тотарга кирәк, — дип хәбәр итте ул.

72 нче гвардия дивизиясенең 8 батыры, 7 нче гвардия армиясеннән беренчеләрдән булып, Днепрның уң як ярына аяк басты һәм шунда ныгып урнашты.

Без җинел сулап куйдык. Сорауларыбыз аңа бик күп. Ләкин вакыт тар, ул үзенең көймәсен яна рейска әзерли. Ашыгырга кирәк, беренче уңышны ныгытырга кирәк.

Кырык кешедән торган алдынгы отряд, коммунист капитан Азотов командасы астында, ике станоклы пулемет, дүрт кул пулеметы, танкка каршы ата торган мылтыклар, автоматлар белән коралланып, ярдан кузгалып киттеләр. Беренче көймә белән сапер Александр Казаков идарә итте.

Караңгылык тагы да куерды: елга өсте куе томан белән капланды. Әйтерсең, елга үзе безнең сугышчыларга булышырга, аларны дошман күзеннән сакларга тели иде.

Тиздән саперлар алдынгы отрядның командирыннан шатлыклы донесение китерделәр:

«Кинәт һөҗүм итеп, отряд дошманның икенче траншеясын һәм кирпеч заводын алды. Гитлерчыларның сак отряды каушап, коралларын ташлап, сугышсыз-нисез Барадаевка авылына чигенде. Отряд разведчиклар группасы белән кушылды һәм оборона бөҗрасы оештырды. Разведка алып барабыз...» — диелгән иде анда.

Шулай итеп, уң як ярда өч йөз метр киңлектә, биш йөз метр тирәнлектә плацдарм яулап алынды.

Таң алдыннан Воронцов белән Соколовка мичкәләрдән саллар һәм башка кичү кирәк-яраклары әзерләргә кушып, без үз команда пунктыбызга кайттык.

Командующийның күзәтү пунктында

24 сентябрь иртәсе аяз иде. Лосев та, мин дә самолет тавышына уянып киттек. Днепр өстендә өч «ЛА-5» очып йөри иде. Ике минуттан алар көнбатышка таба юнәлделәр һәм курганнар артында күздән югалдылар.

Үлән яфракларында чык бөртекләре ялтырый, һава тып-тын, чалт аяз, болытның әсәре дә юк.

Үземнең күзәтү пунктына шалтыраттым. Майор Воронцов җавап бирде.

— Алгы сызыктан нинди яңа хәбәрләр бар?

— Берни дә юк. Искечә. Безнекеләр дә, дошман да күренми, — диде разведчик.

Аннан-моннан гына капкаладык та 81 нче гвардия дивизиясе командиры полковник С. Г. Николаев янына киттек. Нык, таза гәүдәле, пөхтә киенгән Николаев безне үзенең штабында каршы алды. Ул докладка әзерләнә иде.

Штаб тирәсендә сугышчылар кичү жайланмалары әзерлиләр, көймәләргә утыргычлар кагалар, ишкәкләр ясыйлар, бүрәнәләрне бер-берсенә беркетеп бәйлиләр. Полковник Соколов белән инженер-майор Демичев та биредә иде. Йокламаганлыклары кызарган күзләреннән күренеп тора. Ләкин алар барлык эшләр белән дә үзләре житәкчелек итәләр, әледән-әле, кулларына балта алып, сугышчыларга ярдәм итүдән дә тартынып тормыйлар иде.

— Кадакны менә болай кагарга кирәк,— дип, полковник Соколов бер яшь сугышчыдан чүкеч алды һәм ике-өч сугуда кадакны агачка кертеп жибәрде.

Мин Николаевтан «Западный» хәлен сораштым.

— Отряд утрауда. Төне буе каты сугыш барды. Ике әсир китерделәр. Алар гарнизонда 300 кеше барлыгын, ныклап урнашуларын расладылар. Каршылык күрсәтүләрен дәвам иттерәләр.

72 нче дивизиянең бер ротасы һәм разведгруппаның Днепрны кичеп, плацдарм яулап алуы турында корпуста бик азлар гына белә иде әле.

Бу турыда Колесник та ишетмәгән иде. Армия штабына да хәбәр итәргә житешмәгән идек. Утрауга барышлый, полковник Колесникка ул турыда сөйләп бирдем. Ул мина карап беравык торды да:

— Чынлапмы бу? — диде, гажәпләнеп. — Мина белдермәвегез әйбәт түгел. Мин сезнең белән күзәтү пунктында булырга тиеш идем.

«Западный» утравында каты сугышлар һаман да дәвам итә иде әле. Ә үн як ярдагы плацдармда һаман тынлык хөкем сөрә, безнең сугышчылар дошманның борын астында күзәтү алып баралар иде.

Без армия командующие күзәтү пунктына юнәлдек. Сапердар армия командующие өчен күзәтү пунктын куаклык белән капланган калкулык өстенә әзерләгәннәр иде. Моннан Днепрның үн як яры да, андагы курганнар да, Барадаевка авылы да, аннан ары-рак Верхнеднепровск шәһәре дә ачык күренеп тора иде. 25 нче гвардия һәм 49 нчы корпуслар урнашкан полоса куе урманнарга, бакчаларга күмелгән.

Күзәтү пунктына армиянең барлык корпус, дивизия командирлары һәм аларның урынбасарлары, армия штабы офицерлары — һәрберсе Белгородтан Днепрга хәтле сугышчан юл үткән тәжрибәле хәрби белгечләр җыелган иде. Моңа кадәр әле күпләрнең бер-берсе белән танышканнары юк, береңче тапкыр күрешәләр, сөйләшәләр, таныш булганнары бер-берсе белән моңа кадәр кичергәннәрен уртаклашалар. Барысының да күңеле күтәренке. Шулай булмый мөмкин дә түгел: чөнки Ватан боерыгын, Хәрби Совет приказларын үтәүләренә — Днепрга билгеләнгән срокта чыгуларына барысы да канәгать.

— Бүген иртән барысыннан да әлек үзем Днепрда булдым, — дип сөйләнергә кереште генерал Скворцов. — Днепр суы белән битне юдым. Днепр суын Хәрби Советка күрсәтергә шешәгә салып алып килдем. Менә ул! — һәм ул шешәсен югары күтәреп барысына да күрсәтеп чыкты.

Мәзәк һәм шаяртырга яраткан генерал Лосев:

— Сонга калгансыз икән, Александр Васильевич, — диде, көлеп. — Без кичә үк инде комкор һәм полковник Николаев белән Днепр суында ике тапкыр коенып чыктык.

Кемдер шунда:

— Бүген иртән барыгыздан да әлек Хәрби Совет члены белән командующий үзе елга буена барып кайтты, — дип сүзгә кушылды.

Ун туларга унбиш минут калгач, Хәрби Совет членнары, М. С. Шумилов һәм армиянең башка офицерлары килде.

24 нче гвардия корпусы составындагы дивизия командирлары, комкор генерал-лейтенант И. А. Васильев, 25 нче гвардия корпусыннан генерал А. И. Лосев һәм полковник С. Г. Николаев докладларыннан соң, сүзне мина бирделәр. Мин полкларның туплану районнары, артиллериянең, тылның килеп житүе, кичү жайланмаларының әзерлеге турында сөйләдем. Командующий барысын да бик игътибар белән тыңлады. Кичү буенча кабул ителгән карарга күчкән генә идем, сүземне бүлде:

— Иптәш Сафиуллин, кичә төнлә Днепрны кичкән разведчикларның һәм отрядның плацдарм яулап алуын нигә әйтмисез? — дип сорады ул, таләпчән тавыш белән.— Ни өчен Хәрби Советка һәм штабка бу турыда хәбәр итмәдегез? Генерал Лосев та ул турыда берни дәшмәде.

Киңәшмәгә катнашучылар гаҗәпләнеп безгә текәлделәр.

— Тәвәккәллек һәм инициатива өчен сезгә һәм дивизия командирына рәхмәт, — дип дәвам итте командующий сүзен. — Ләкин бу турыда хәбәр итмәвегез өчен җәзага тартам. Ун як ярга десант чыгаруыгыз турында без генә түгел, хәтта фронтның Хәрби Советы да белә.

Мин, үземне уңайсыз хис итеп, дәшмәдем. Хәер, мин аның үз кул астындагы командирларына карата мөнәсәбәтен яхшы белә идем инде. Ул болай гына куркыта, ә үзе эченнән хуплый. Мин тынычланып, үз-үземне кулга алдым һәм барысы турында да сөйләп бирдем.

— Ипташ Скворцов, Днепр суы тутырылган шешәне чыгарып ташларга була, — диде шуннан соң полковник Козак. Барысы да көлештеләр.

Ахырда командующий Днепрның ун ягындагы торак пунктларда һәм калкулыкларда дошманның нигуын, әлегә резервлар китерүе күренмәвен әйтте, бүген төнлә һәм иртәгә бөтен укчы частьларның елганы кичүен бурыч итеп куйды.

Армиянең Хәрби Совет члены генерал А. В. Мухин Днепрны беренче булып кичкән безнең разведчикларның һәм алдынгы отрядның батырлыгы турында һәр сугышчыга житкерергә, листовкалар чыгарырга, газеталарга язарга кушты.

Армиянең штаб начальнигы генерал Г. С. Лукин елганы кичү турында приказ укыды. Приказ буенча, 25 нче гвардия корпусы уңнан — Крамаровка, көнчыгыш Барадаевка, Барадаевка авылы каберлеге; сулдан — Иске Орлик, 1,4 биеклеге полосасында Днепрны кичәргә һәм һөҗүм итәргә тиеш иде.

Рекогносцировка тәмамланды. Приказны язып алып, без үз частьларыбызга кайтып киттек.

Корпус плацдарм яулый

Иртәгесен иртүк дивизияләр һәм корпус карамагына бирелгән частьларның командирлары белән «Восточный» утравында мин рекогносцировка үткәрдем, үземнең карарны белдердем. Бу карар буенча корпус, үзенең 72 нче гвардия дивизиясе белән, сул флангтан төп ударны ясарга тиеш иде. Иң якын бурыч — 5,5 километр тирәнлеккә бәреп керү, көннең бурычы — 11—15 километр ара үтү: беренче көнне үк корпус Барадаевка хуторы районына чыгу. Артиллерия әзерлеге үткәрмәскә, елганы төнлә дошман искәрмәслек итеп кичәргә!..

Көне буе киеренке әзерлек эше барды. 6—10 кеше сыярлык 36 балыкчы көймәсе, бүрәнәләрдән һәм мичкәләрдән сигез сал ясалды. Балыкчылар, боларга өстәмә итеп, тагын 8 көймә китерделәр. Алар бу көймәләрне дошман борын астыннан алып килгәннәр иде.

Балыкчылар вакытлыча бездә калдылар, әзерлек эшләрендә сугышчыларга ярдәм иттеләр, көймәләрне ремонтладылар.

Артиллерия һәм миномет полклары ут позицияләренә урнашты. Дивизия һәм корпус артиллерия группалары оештырылды. Һәр дивизиягә бер артиллерия полкы һәм безнең карамакка бирелгән миномет полкы ярдәм итәргә тиеш иде. Корпус артиллерия группасына шулай ук туп-артиллерия полкы һәм «М-13» реактив жайланмасы полкы кертелгән иде.

Корпусның сугышчан хәрәкәтен дошман авиациясе һөҗүменнән полковник М. А. Кудрявцевның 5 нче зенит дивизиясе капларга тиеш иде.

Алардан тыш 115 нче аерым гвардия полкы дошман танкларын юк итү өчен махсус билгеләнгән иде. Командующий, боларга өстәмә итеп, 27 нче армия танк бригадасын корпуска ярдәмгә жибәрергә вәгъдә бирде.

Төн. Елга өсте яп-якты — күктә тулган ай йөзә. 229 нчы гвардия полкы — кичүне ул башлаячак — «Восточный»дан йөз метр ераклыктагы туплану районында.

Дошман, кичәге кебек үк, сирәк-мирәк утрауларга һәм елга өстенә артиллериядән атып тора.

Аргы яктагы алгы позициядән рация буенча ике донесение алынды:

«Дошман ике ротага якын көч белән ике тапкыр контратака ясады, — дип хәбәр итте отряд командиры. — Атакаларны кире кактык. Позицияләрдә нык торабыз».

Нәкъ 22 сәгать 15 минутта ун көймә, биш зур сал утраудан суга төшерелде: 229 нчы гвардия полкының бер батальоны кичү эшенә кереште. Аларга ике 45 миллиметрлы туп, батальон миномётлары бирелде. Бу рейс белән полк командиры майор Г. Б. Баталов үзе дә юлга җыенды.

— Минем урыным хәзер аргы якта. Биредә минем урынбасарларым һәм штаб работниклары да булдыра алыр, — диде ул.

Көймәләр һәм саллар белән тәжрибәле саперлар идарә иттеләр. Баталов утырган иң алдагы көймә белән идарә итүне инде ике мәртәбә аргы якка барып кайткан батыр сапер Александр Казаков үз өстенә алды.

Дошман кичүчеләрне күрде. Барадаевка авылы артыннан артиллериядән һәм миномёттан тәртипсез ут ачты. Әмма пулеметтан ата алмый иде ул, бу юнәлештәге уңай позицияләр аргы якта безнең алдынгы отряд кулында иде.

Беренче рейс китеп, 20 минут үткәч, икенче рейс, аннан өченчесе, дүртенчесе китте. Иртәнгә кадәр шулай дәвам итте.

Аргы яктан көймәләр һәм саллар исән-сау әйләнеп кайттылар. Алай гына да түгел, үзләре белән тагын өч көймә алып кайттылар, куаклык арасына немецлар яшереп куйган булган икән.

Иртәнгә инде корпусның авангарды — 229 нчы гвардия полкы — үзенең барлык танкка каршы туплары, батальон, полк туплары һәм миномётлары белән, көнбатыш ярга күчүне тәмамлаган иде.

Таң алдыннан полк командиры:

— Барадаевка авылының көнчыгыш кырыена һөҗүм итәм, — дип хәбәр итте.

— Үзегез ничек кирәк тапсагыз, шулай эшләгез, — диде ана каршы дивизия командиры генерал Лосев.

Барадаевканың көнчыгыш өлеше күзәтү пунктыннан күренми, кирпеч заводы артында уйсулыкка урнашкан иде ул.

Озакламый шул якта төрле төстәге ракеталар күтәрелде, атыш тавышы, мина, снарядлар һәм гранаталар шартлаган тавышлар ишетелде.

Сугыш иртәнге алтыга кадәр барды. Барадаевка авылының бүе бер километрдан артык, аркылысы сигез йөз метр өлеше дошманнан чистартылды. Полк авылдан көньяктарак булган биеклекне алды, Кременчуг — Верхнеднепровск юлын кисеп чыкты. Шуның белән ул 24 нче гвардия корпусының уң флангысын төньяк-көнбатыш яктан һөҗүмнән саклады.

Днепрны полкның уңышлы кичүе һәм плацдармны киңәйтүе турында армия командующиена хәбәр иттем.

— Гвардиячеләргә белдерегез: армиядә беренче булып Днепрны кичкән һәм плацдарм яулап алган батырларны армия Хәрби Советы котлый, — дип приказ бирде командующий.

Ул 24 нче гвардия корпусының алдынгы отряды да елганы уңышлы кичкәнлеген әйтте. Уң як күршебез — 49 нчы корпус частьларының кичүе турында хәбәр юк иде әле.

Яктыра башлау белән, роталар Барадаевка авылының үзәгенә бәреп керделәр. Дошман оборонасына җан керде. Миномет тавышлары яңгырады, йортлардан һәм дзотлардан пулеметлар, автоматлар атарга тотынды. Полкның флангысына дошман батальоны контратака ясады, сугыш көчәйгәннән көчәйде.

Бу сугышта гвардия сержанты комсомолец Иван Поляков зур батырлык күрсәтте. Дошман уңайлы позициягә урнашкан иде. Әре калибрлы пулемет безнең сугышчыларга баш күтәрергә дә ирек бирми. Поляков шуышып пулемет янына барып житә һәм аны, расчеты-ние белән, граната ыргытып юк итә. Рота командиры яралангач, Иван Поляков рота белән командалык итүне үз өстенә ала, аны үз артыннан һөҗүмгә алып китә. Һәм рота оборона өчен уңай позицияне яулап ала.

Плацдармны юк итү өчен дошман бөтен көчен куйды. Ләкин безнең сугышчылар яулап алынган плацдарм рубежларын киңәйтү өчен тагын да киренкерәк көч куйдылар. Алар Днепрның уң ягында һөҗүмне киңәйтүнең безнең гаскәрләр өчен әһәмиятен яхшы белә иде.

Фашистлар өлкән сержант Фокин командасы астындагы группаны камап алалар. Сугышчылар, оборона бөҗрасы өештырып, урыннан дошманга каршы көчле ут ачалар. Киная разведчик Пристенский «Фокин, немецлар!» дип кычкырып җибәрә. Фокин борылып караса, үзеннән берничә адымда гына шуышып килгән күп кенә немецларны күрә. Фокин автоматын аларга төби, ләкин автомат атмый, патроннар беткән. Пристенскийда да патроннар юк.

Сугышның иң кызган вакытында патроннар юк — сугышчы өчен моңардан да кыен, куркыныч хәлнең булуы мөмкинме икән? Фокин башта каушап кала, ләкин, бик тиз үз-үзен кулга алып, киная тора да, автоматын көпшәсеннән тотып, дошманнар эченә ташлана, автомат түтәсе белән өч фашист солдатын бәреп үтерә, дүртенчесеннән кул пулеметын тартып ала һәм озын очередьлар белән дошманнарга терәп ата башлый. Дошманның исән калган егерме солдаты һәм офицеры сугыш кырын ташлап кача. Дошманның икенче пулеметын Пристенский кулга төшерә, ләкин үзе яралана. Әмма сул ярга китәргә теләми.

Ул көнне плацдармны саклаучылар дошманның унөч атакасын кире кайтардылар. Патроннар җитмәүгә дә карамастан, алынган позицияләрдән чигенмәделәр.

Барадаевка авылы кешеләре дә безнең сугышчыларга зур ярдәм күрсәтте. Хатын-кызлар окоплар казырга булыштылар, яралыларны бәйләделәр, су белән тәэмин иттеләр. Ә ирләр, үлгән һәм яраланган сугышчыларның коралын алып, дошманга каршы сугыштылар.

* * *

26 сентябрьга каршы төндә командующийдан дивизияләрнең төп көчләре белән Днепрны кичәргә, Барадаевка авылын һәм курганнарны азат итәргә приказ алынды.

Корпусның сугышчан тормышында иң җаваплы һәм авыр момент башланды.

Кичтән корпус карамагына бирелгән Баш командованне разведкасының понтон батальоны белән 329 нчы инженер-сапер батальоны килеп җитте. Бу понтоннардан 12—16 тонна йөк күтәрерлек өч паром җыярга мөмкин иде. Аларны тартырга катер да бирделәр. Хәзер тягачлары белән туплары һәм миномётларны да аргы якка чыгарырга мөмкин иде инде.

Кояш баегач ук дивизияләрнең төп көчләрен аргы якка чыгару эшенә керештек. Сугышчылар көймәләрне елгага жилкәләренә күтәреп китерделәр. Саллар өстенә туп-ларны һәм миномётларны тартып керттеләр.

Караңгы төште. Төн ул безнең союздаш Без шуны гына көттек. 229 нчы гвардия полкы дивизияләрнең кичүен каплап торды. Беренче салларга утырып, И. П. Качалов батальоны һәм 81 нче гвардия дивизиясенең 224 нче гвардия полкыннан беренче ба-тальон сугышчылары юлга чыкты. Алар арасында корпус штабының майор Степной житәкчелегендәге оператив группасы да бар иде. Корпус политбүлегеннән майор Сай-гетдинов белән майор Токарев та алар белән китте.

Егермедән артык сал, дистәләрчә көймә берьюлы кузгалды. Алар алдан бил-геләнгән интервал һәм дистанцияләрне саклап йөзделәр. Ин арттан, полк тупларын һәм миномётларын төягән паромны тартып, катер йөзеп китте.

Армиянең инженер гаскәрләре начальнигы генерал-майор В. Я. Пляскин кичтән үк «Восточный»га килгән иде. Ул иртәнгә кадәр безнең корпус кичкән полосада булды. инженерлар, саперлар һәм понтончылар эше белән житәкчелек итте, резервларны һәм артиллерия полкларын аргы якка күчерергә ярдәм итте. Офицерлар да, генераллар да аны игътибарлы, ягымлы булуы, ярдәмгә һәрвакыт әзер торуы өчен яраталар иде.

Дошман кичүчеләр өстенә артиллериядән һәм миномётлардан өзлексез атып тор-ды. Ләкин аларның утлары прицелсыз иде, безнең сугышчыларга зур зарар китерә алмады. Шулай да берничә снаряд саллар һәм көймәләр арасында шартлады.

Шундый снарядларның берсе элемтәчеләр салы янында шартлый. Сал тарала, ка-бель су астына китә. Әмма элемтәчеләр чумып кабельне алалар һәм, ярга йөзеп чы-гып, сул як яр белән телефон элемтәсе урнаштыралар.

Билгеләнгән вакытка корпусның барлык полклары ун якка чыгып бетте һәм 229 нчы гвардия полкы яулап алган плацдармга урнашты.

Плацдармны киңәйтү сугышлары

Таң беленә башлау белән ун як ярдан полкларның атакага әзер булуын хәбәр ит-теләр. Алар сул яктан артиллерия һәм миномет полкларының залпын көтәләр иде. Алдан исәпләп куелганча, Барадаевка авылы үзәгенә һәм авылдан көньяк-көнбатыш-тарак булган биеклекләргә ун минутлык ут яудырылырга тиеш иде.

Мин Николаев, Лосев, Колесник һәм Журавлев белән төнне күзәтү пунктында үткәрдем.

— Башлыйбызмы? — дип сорадым мин дивизия командирларыннан.

— Томан бит. Артиллеристларга начар күренә, — диде Журавлев.

— Аның каравы пехота өчен яхшы, — диде ана каршы Лосев. — Калкулык өстен-дә томан юк, корректировщиклар яхшы күрсәтә алалар.

Ун минутлык артиллерия әзерлегенә команда бирелде.

— Барадаевка үзәге шәп актарылды,—дип хәбәр итте ун яктан майор Степной.— Хәзер атака башлыйбыз.

Һөҗүм шундый искәрмәстән һәм омтылышлы булды, дошман авыл читендә бө-тенләй каршылык күрсәтә алмады. Полклар авыл эченә бәреп кергәч кенә, фашист-ларга жан керде, аларның ут ноктaлары телгә килде. Урамнарда, йортларда, тран-шеяларда каты кул сугышы башланды. Төрле яктан дошман танклары күренде.

Авылның үзәгенә яр буйлап 81 нче гвардия дивизиясенең 233 нче һәм 235 нче полклары һөҗүм итә иде. Бу дивизиянең 238 нче полкы 114 5 биеклегенә атакага таш-ланды. Ә 72 нче гвардия дивизиясе полклары авылның көнчыгыш ягыннан Домоткань юлы буендагы биеклекләрне штурмладылар.

Армия командующие шалтыратты. Аны Барадаевка авылы үзәгендәге һәм авыл-ның көньяк читендәге дошман көчләре кызыксындыра иде: фашистлар резервлар ки-терергә өлгермәдеме икән?

Танк тупларыннан аткан тавышларны ишетеп булса кирәк, ул борчулы тавыш белән:

— Дошманның танклары күпме? — дип сорады.

— Күп түгел. Барысы уникe. Минемчә, бу резерв түгел, 39 нчы пехота дивизиясе танклары, — дип җавап бирдем.

Дошманның 39 нчы пехота дивизиясе безгә каршы Мерефа янында сугышты. Красноград янында ул безнең фронттан алынды да Днепрның ун ягына күчерелде һәм кин оборона полосасы биләде.

Барадаевка авылы һәм аның тирәсендәге сугышлар көндезге 12 гә кадәр дәвам итте. Немецларның бик аз солдатлары һәм офицерлары гына авылның көнбатыш чи-тенә һәм юл артындагы биеклекләргә чигенә алды, күбесе кырылып бетте.

Катлаулы сугыш шартларында коммунистларның һәм комсомолецларның шәхси батырлык үрнәге барлык сугышчыларны жиңүгә әйдәде.

Василий Сагайда батальоны дошманның рәттән сигез атакасын кире какты. Фа-шистлар тугызынчы тапкыр атакага ябырылдылар. Сафлары шактый сирәгәйгән ба-тальонга каршы дошман яна көчләр белән һөҗүм итте. Гитлерчылар безнең оборона-ның беренче линиясен өзделәр. Сугышчыларны рухландырырлык, аларда жиңүгә ыша-

нычны көчәйтерлек нәрсәдер эшләргә кирәк иде. Шул вакыт батальон командиры коммунист Сагайда үзе пулемет артына ятты, озын очередьлар белән дошманга ут өермәсе яудыра башлады. Фашистлар чигенделәр.

Коммунист Григорий Стрепетов житәкчелегендәге уналты сугышчы бер көн эчендә дошманның биш атакасын кире какты, сигез танкысын җимерде, утызга якын солдатын һәм офицерын юк итте.

Партия членлыгына кандидат Сухарев һәм комсомолец Уваров Барадаевка авылына береичеләрдән булып бәреп керделәр, дошман ныгып урнашкан йортны гранаталар атып шартлаттылар, немецларның җиде солдатын һәм бер офицерын юк иттеләр.

Мондый батырлык, куркусызлык үрнәкләрен йөзәрләп һәм меңәрләп китерергә мөмкин булыр иде.

Шулай һич тә көтмәгәндә генә полк командиры Баталов урнашкан пунктка дошманның утыз автоматчысы үтеп керде. Фашистлар ун кешедән торган кечкенә генә отрядны юк итеп, полк командирын әсир алырга исәп тоттылар. Безнең офицерлар һәм сугышчылар, ни туры килде, шуның белән коралланып, дошманга ташландылар, прикладлар белән сугыштылар, гранаталар ыргыттылар, автоматтан һәм пистолетлардан аттылар. Фашист автоматчылары барысы да юк ителде...

Полклар яулап алынган рубежларда ныгып, дошман оборонасын штурмлауны дәвам иттерделәр.

Барадаевкадан корпусның разведка начальнигы И. А. Воронцов шалтыратып, безгә каршы дошманның 106 нчы, 320 нче һәм 39 нчы пехота дивизияләре сугышканын хәбәр итте. Әсирләр әйтүенчә, 106 нчы һәм 320 нче дивизияләр алдагы сугышларда шактый зәгыйфьләнгән, бары 39 нчы дивизия генә тулы составта икән. Бу дивизия үзенең танкларын, бронетранспортерларын һәм артиллериясен шактый тулы саклый алган.

Әсир төшкән дошман офицерлары резервлар китереләсен ишеткәннәр. Аларны танклар һәм авиация көчләре белән ныгытырга вәгъдә биргәннәр. Ләкин алар бу көчләрнең кайчан килеп җитәсен белмиләр иде.

81 нче гвардия дивизиясе 72 нче гвардия дивизиясе белән бер линиядә, ачык калган уң флангны каплап, көньякка таба һөҗүм итте.

49 нчы корпус полклары бездән өч километр төньяк-көнбатыштарак 147,4 биеклеген штурмлый иде, ә 24 нче гвардия корпусы Домоткань шәһәренең көнбатыш читенә бәреп керде.

Дивизия командирлары Лосев белән Николаев күзәтү пунктларын уң якка күчерергә рөхсәт сорадылар. Мин каршы килмәдем. Шул ук вакытта корпусның оператив группасына +2,0 биеклеген алгач та, шунда минә күзәтү пункты әзерләргә куштым.

Сугышлар һәр калкулык, һәр каршылык күрсәтү үзәге өчен барды. Дошман юл тирәләрендә аеруча каршылык күрсәтте, бер-бер артлы контратакага күтәрелде. Һавада дошманның бомбардировщиклары күренде. Алар күп булмасалар да, кичү урыннарын, гаскәр тупланган урыннарны бик тырышып бомбага тоттылар.

Сугышның һәр сәгате, алга атланган һәр адым сугышчылардан гаять зур батырлык, фидакарьлек таләп итте.

Капитан Михаил Дякинның танкка каршы ата торган туплар батареясы, укчылар сафы арасына урнашып, дошман танкларының унике атакасын кире какты, дүрт танкысын яндырды. Сержант Алексей Гриб орудиесе расчеты, дошманның алты танкысын яндырганнан соң, снарядлары беткәч, автоматлар белән коралланып, фашистларга каршы атакага ташланды. Капитан М. В. Дякинга һәм сержант Алексей Грибка бу сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

Дошман ныгытмаларының өченче линиясе гвардиячеләрне көчле ут өермәсе белән каршы алды. Кичкә таба дошманның бомбардировщиклары һәм штурмовиклары очып килеп җитте. Артиллерия әзерлегеннән һәм һавадан бомбага тоткаННан соң, дошманның бер полк пехотасы, 15 танк ярдәмендә, 223 нче гвардия полкының флангысына китереп бәрде. 229 нчы гвардия полкына да фашистларның ун танкысы, бер полк пехотасы һөҗүм итте. Дошманның бу атакаларын кире кайтару әллә ни авыр булмады. Дивизия контратакага күчте һәм, һөҗүм итеп барган унайга дошманның траншеяларына бәреп кереп, көчле күл сугышыннан соң, барлык калкулыкларны кулга төшерде. Гвардиячеләр шуның белән бүгенге көн өчен куелган бурычны үтәделәр һәм ул калкулыкларда ныгып урнаштылар.

Лосев белән Николаев, көймәләргә утырып, ун як ярга чыгып киттеләр. 45 минуттан инде мин аларның аргы яктан, яңа күзәтү пунктларыннан, телефон буенча докладларын тыңладым.

— Дивизия штабын кайда урнаштырырга боерасыз? — дип сорады Лосев.

— Авыл эченә урнаштырмагыз. Авылдан көньяк-көнчыгыш якта әйбәтрәк булыр. Хәзергә штабларның һәм тыл частьларының беренче эшелонын гына уң якка күчерегез.

(Ахыры киләсе санда.)

БЕЗНЕҢ САФКА

Узган елның октябрь—декабрь айларында татар совет язучылары сафына тагын ике яшь шагыйрь кабул ителде. Рәдиф Гатауллин һәм Равил Фәйзуллиннар үзләренең шигырьләре белән инде әдәбият мәйданына чыккан һәм укучыларыбызга таныш шагыйрьләр.

СССР язучылары союзы членлыгына Рәдиф Гатауллинны шагыйрьләребездән Хәсән Туфан, Нури Арсланов һәм Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллинны Сибгат Хәким, Илдар Юзеев һәм Рөстәм Кутуй иптәшләр тәкъдим иттеләр.

Түбәндә без шул тәкъдимнәрдән икесен урнаштырабыз.

Сокландыра да, шатландыра да

Рәдифне мин әдәбиятта күренә башлаган көннәреннән бирле кызыксынып күзәтеп киләм. Поэзиябезгә килүче яшьләр арасында һаман да ачыла, үсә, төгәлләнә баруы белән сокландыра да, шатландыра да ул мине.

Һәм ышандыра да. Мин аның — тумыштан талантлы икәненә, димәк, Тукайлар — Такташлар — Җәлилләр васыятен дәвам иттерүчеләрнең берсе булачагына ышанам. Безнең Рәдифнең күңел күзе дә бар: халык күңеле гөлләренә нинди суларкиргән ачык сизә ала ул, абстракцион шигырь чүлләрендә каңгырып йөрүчеләрдән түгел ул.

Телебезнең эчке гүзәллекләрен, тирән нюансларын, аның мөмкинлекләрен гаҗәп нечкә рәвештә сизә һәм шул хисләрне реаль тормышка күчерә, әйтә ала Рәдиф:

Кайтыгыз, былтыргы карлар,
Кайтыгыз, сезгә карыйм,
Гөнаһсыз чакның карына
Гөнаһлы исемем языйм...

Аз гына сүздә шундый күп кичерешләрне әйтә алу өчен, туган телеңнең җылысын сизә дә, сөя дә ала торган үз йөрәк, чын йөрәк кирәк — шигъри йөрәк кирәк.

Рәдифнең беренче җыентыгы («Гөлләр су сорый») күңелле вакыйга булыр кебек тоела: укучылар аны сөенеп, сокланып, үз күреп кабул итәрләрдер.

Эчтәлекләре һәм формалары белән яңача яңгыраш тудырган бу шигырьләр, асылда, безнең хәзерге традицион поэзиябездәге тәп сыйфатларга нигезләнеп иҗат ителгәннәр.

Күренә ки, безнең Рәдиф («Яңалык» яшелчәләрен күрше бакчалардан эзләүче кәкәләрчә түгел) зур поэзия капкасына ир-егетләрчә — сыналган, сайланган, расланган характер белән килә. Мин аны кочаклап каршылау ягындагылар сафында торып, СССР язучылары союзы членлыгына тәкъдим итәм.

ХӘСӘН ТУФАН.

Поэзиябезгә яңа шагыйрь килә

Һәр талант, чын талант үзенчә ачыла. Көтмәгәнчә, син көтмәгән яктан. Курка-курка түгел, кыю, батыр, үзенә нык ышанып. Хәтта бераз сәер, син күптән күнегеп беткән формаларга, традицияләргә туры да килеп бетми шикелле. Туры килмәсә дә яза, яңача яңгырый.

Равил Фәйзуллинга 23 яшь. Белеме югары. Татар телен дә, рус телен дә яхшы белә. Татар әдәбиятын да, рус һәм Европа әдәбиятын да өйрәнгән егет. Кыскасы, ул поэзиягә әзерлек белән килә. Бу аның әсәрләреннән сизелә.

Равил Фәйзуллин безнең күбебез кабатлаган кимчелекне кабатламый. Аның шигырьләре натуралистик сурәтләүдән азат. Ул тирән фәлсәфи гомумиләштерүләр юлы белән килә һәм күп әсәрләрендә уңышка ирешә. Поэзия ул хистә, уйлануларда, тормыш турындагы фәлсәфәдә, шагыйрьнең туктаусыз алып барган бәхәсендә.

Равил Фәйзуллин — татар совет поэзиясендә беренче адымыннан ук яңа исем, үзенчә сүз башлый торган яңа исем. Яратсаң да, яратмасаң да ул үз эзләнүләре буйлап килә. Әдәбиятта әзер калыплар, әзер сукмаклар юк. Һәркем үзен үз газапларында ача, тормышны үзенчә раслый.

Мин күп республикаларда булдым, семинарларда катнаштым. Гомерем буе яшьләр белән индивидуаль эш алып бардым. Шул тәҗрибәмә таянып әйтәм: безнең поэзиягә яңа шагыйрь килә.

Мин Равил Фәйзуллинны Союзга членлыкка тәкъдим итәм.

СИБГАТ ХӘКИМ.

—✦—

Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел

ХУДОЖНИК Т. ХАҖИӘХМӘТОВНЫҢ «БЕЗНЕҢ КӨННӘР» РОМАНЫНА ЯСАГАН ИЛЛЮСТРАЦИЯЛӘРЕ

«Алар хәзер барлыгы берләшәчәкләр икән дә, ди, байларына язып бирәчәкләр, ди: — Безгә эш вакыты сигез сәгать булсын!.. Хезмәт хакы арттырылсын!.. Приказчиклар белән адәм кебек мөгамәлә кылынсын! — дип әйтәчәкләр, әгәр дә инде сораганнарын байлар бирмәсә, урыннарын ташлап чыгачаклар, имеш, ди».

«Ләкин бу озакка бармады, бу тәбәнәк, ярым караңгы залдан тагын күп коридорлар, тимер ишекләр аркылы барып, үлем агачы әзерләнгән таш коймалар уртасына тынтагач, муллага әмер булды. Ул аптырабрак, бунчалы коръәнен бер култыгыннан икенчесенә күчерә-күчерә, тоткынга килде, каушаган, калтыраган тавыш белән:

— Аллаһе тәгаләнең рәхмәтенә чик юк, дип әйтә китап. Тәүбә ныл. Иман әйт. Үлем алдыннан гөнаһларыңның кичерелүен сора. Аллаһе тәгалә гафу рәхим! — диде.

Гәрәй Солтан аңа карамый йөз чытты, кулы белән читкә таба этәрде, гаҗәп ят бер рәвештә:

— Синең алдыңда тәүбә итәрлек гөнаһ эшләганем юк минем! — дип кисте».

«Яхшы... кара ат. Кара күгелҗем чикмән киган калын кучер. Яңа, бай, чибәр дышлода, кыйммәтле мех якаларга төрена төшеп, яшь ханым утырган. Давыт башта танымады, таныгач, кирс чигенеп китәргә теләде...».



«Ерактан таң сызыла. Балкып кояш чыга. Яэның аяз матур көннәреннән берсе туа».

Г.Ибраһимовның тууына 80 ел

Миләүшә Маннурова

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «БЕЗНЕҢ КӨННӘР» РОМАНЫНДА РУС ОБРАЗЛАРЫ

Үзенең «Безнең көннәр» (1914—1920) романы[1] белән Г. Ибраһимов татар әдәбиятында тарихи-революцион жанрга нигез салды. Бу роман төрки халыклары әдәбиятларында изелгән, жәберләнгән милләтләргә 1905—07 елларда-гы беренче рус революциясенең тәэсирен күрсәтүче тәүге әсәрләренең берсе булды. Россиянең төрле шәһәрләрендә яшәү, эшче халык белән якыннан аралашу, яшерен оешмаларда катнашу, ниһаять, патша властьлары белән беренче бәрелешләр Г. Ибраһимовның дөньяга карашын кискен үзгәртеп жибәрделәр. Һәм әдип социаль-политик характердагы мәсьәләләрне кыюрак күтәрә башлый.

Галимжан Ибраһимов әдәбият халыкка һәм жәмгыятькә хезмәт итәргә тиеш дигән карашта торды. Аннан соң, һәр зур әдәби әсәр ихтыяж булганда гына туа, ул халыкка кирәк була башлый, социаль-иҗтимагый ихтыяж булып формалаша. Әгәр Г. Ибраһимовта рус кешеләре турында әсәр язу теләге туган икән, димәк ул патша самодержавиесенә каршы ике милләт көрәшенең көчәюен тойган дигән сүз. Г. Ибраһимов иҗатының социаль юнәлеше татарларга рус халкы тормышының асылын аңларга, рус һәм татар халкы арасындагы дуслыкның сәбәпләрен төшенергә ярдәм итте.

«Безнең көннәр» романында язучы рус халкы характерындагы кешелекле һәм гуманлык сыйфатларын яратып тасвирлады. Шул ук вакытта ул патша ялчыларының шовинизмы, кешелексезлеге турында нәфрәтләнеп язды. Соңгысын Г. Ибраһимов жандарм полковнигы Герасимов образында гәүдәләндергән.

1912 елда Г. Ибраһимов Киевкә бара һәм андагы революцион мөселман студентлары белән яшерен бәйләнешкә керә. Ләкин бу оешма тар-мар ителә, һәм Ибраһимов төрмәгә эләгә. Шик юк, төрмәдәге рәхимсез тәртипләр әдип күңелендә тирән эз калдырганнардыр. Монда ул беренче мәртәбә дошман белән күзгә-күз очраша, монда беренче мәртәбә аның үзенең һәм булачак әдәби геройларның ихтыярлары сынала. Бәлки, шул чакта ук язучы күңелендә патша ялчыларына булган нәфрәтне әдәби образлар аша сурәтләү теләге уянгандыр.

«Безнең көннәр» романында Г. Ибраһимов индивидуаль характерлар иҗат итүдә зур уңышка ирешә. Нинди дә булса бер шәхес образын тудыруда портрет зур роль уйный. Уңышлы портрет идеягә жан өрә, аңа көч һәм ачыклык бирә. Г. Ибраһимов Герасимов портретын контрастлар ярдәмендә төзи: «Ләкин бу кешедә бер дә алай куркыныч, ерткыч төсе юк. Киресенчә, ак чәче, ак сакалы, ачык көләч йөзе белән, өлкән аган яки туган атаң кебек ягымлы тавыш белән бу жандарм безнең тоткынга бик ипле карт булып күренде» (90 бит). Димәк, патша чиновнигының тышкы кыяфәте сыйфый дошманның асылына тәңгәл килми. Әгәр тәңгәл килсә, ул гади алым булыр иде.

Ә кайчакта автор полковникның ерткыч йөзен аның портреты аша, хәрәкәтләре аша күрсәтә: «Йөзендә арганлык, күзләрендә бер тынычлык, бер ут уйный... шунда ук куркыныч ерткычка әйләнә, бугазыңнан алырга торган палач яки алдындагы корбанын чәйнәргә торган усал лачынга әверелә» (97 бит).

Карт полковникның ерткычлыгы кинәт йөзенә бәреп чыга, бу — беренче мәртәбә очрашкан кешегә дә бик ачык аңлашыла. Һәм Булатның жандармны тилгән белән чагыштыруы Герасимовның чирканыч хезмәтен, жәмгыять өчен зыянлы кеше икәнлеген, яңа тормышны һәлак итәргә хәзер торуын бик төгәл чагылдыра.

Патша властьларының, милләтләрне кабалага төшерү һәм нидән калдыру политикасы алып барып, аз санлы халыкларны

---

[1] **Анализ романның 1934 елдагы икенче басмасы буенча ясала. Цитаталар Г. Ибраһимовның 1956 елда чыккан «Сайланма әсәрләре»нең 3 томыннан алынды.**

үзләренә тулысынча буйсынган һәм көрәшкә күтәрелергә базмый торган итеп күрәселәре килде. Алар кайчакта үзләренең теләкләрен чынбарлык итеп тә күрсәтергә маташтылар. Шуңа күрә Герасимов, тәжрибәле жандарм булуына карамастан, татар халкы үз-үзен аңлаудан һәм аңлы көрәштән ерак тора дип саный: «Мин татарларны яратам, утыз ел татар эчендә эш алып барам. Татарлар ак патшага каршы баш күтәрә торган халык түгел» (23 бит).

Утыз ел! Ышанычлы патша ялчыларының алгы сафында барып, бөтен милләтләрне изүгә багышланган 30 ел. Шуңа күрә дә жандармның: «...татар халкының бер генә бәласе бар: ул надан, караңгы» (340 бит) — дип, милләт хәлен уртаклашырга маташуы күз буяу, алдау булып кына яңгырый.

Полковник Герасимовны гомум идеяләр өчен көрәшләрдә ныгыган халыкара дуслык куркыта. Мондый дуслыкның нигуы патша хөкүмәтен бәреп төшерүдә хәлиткеч көч булачагын сизенә ул.

«Безнең көннәр» романында Г. Ибраһимов революция геройлары образларын ижат итүне үзенең төп максаты итеп куя.

Революция алдыннан язылып, Октябрьдан соң редакцияләнгән бу романда авторның оптимизмы ишетелә: ул Герасимовларның революция тарафыннан себерелеп түгеләчәгенә, аларның үлеме килеп житү котылгысызлыгына бөтен барлыгы белән ышана. Язучы бу үлемне әзерләгән көчне күрсәтә. Бу — большевиклар. Бөтен Россияне патша изүеннән коткаруны максат итеп алган бу кешеләр көрәштә башка милләт вәкилләре белән бергә атларга тиешлекләрен яхшы аңлыйлар. Романда иң ачык сурәтләнгән большевик образларының берсе Коля Кадомсов. Аны укучыга тәкъдим итү алымы үзе үк кызыклы: автор, геройдагы теге яки бу үзенчәлекләрне ачу өчен, аның турында башка кешеләрдән сөйләтә. Дөрес, әсәрдәге һәр персонаж фикерен иң дөрес дип исәпләргә ярамый торгандыр. Ләкин автор образларны шундый итеп кора ки, социаль планда аларның һәркайсының үз максаты ап-ачык сизелеп тора.

Хәтта дошман лагере вәкилләренең фикере дә Колянын типик асылын ачып бирә. Герасимовның: «Әллә кайчан асылырга тиешле кешеләрне без трибуналарга мендереп йөртәбез» (20 б), — диюе, Коляның кем икәнен ачык сөйли булса кирәк. Геройның характерын ача торган төп сыйфат итеп, автор Коляның максатка омтылучанлыгын, кирәкле эш өчен көчен кызганмавын, революцион эшкә бирелгәнлеген ала. Аның халык мәхәббәтен казана алуы әнә шул сыйфатлар белән аңлатыла да. «Татар эшчеләре партиянең бу шәһәрдә иң эшлекле ораторларыннан саналган бу яттәшне, үзләренең Кавказлы Гәрәй Солтаннары, Зариф Булатовлары белән бер уңайдан якын итеп, үз итеп яраталар» (20 б).

Әйе, Коля дошманнарның «ирек» дигән төшенчә белән уйнауларын, бу уенның пролетариат өчен никадәр куркыныч икәнен ачып сала һәм «тәмле телле» буржуазия ялчыларына каршы көрәштә пролетариатның корыч сүзен әйтә белә. Шуңа күрә дә, татар эшчеләре аны үзләренең Зарифларын һәм Гәрәйләрен яраткан кебек үк яраталар. Алар өчен инде милли аерымлыклар юк, бары тик омтылышлар, теләкләр уртаклыгы гына бар.

Русларга хас киң күңеллелек, туры сүзлелек Коляның һәр эшендә сизелеп тора: митингта Герасимов Булатны татарча сөйләүдән тыйгач, ул татар ияптәшләрен яклап чыга, 1905 нче ел 17 октябрь манифестының чын мәгънәсен аңлата башлый. Коля яшь революционерларга һәм башка милләт вәкилләренә карата дусларча мөнәсәбәттәге кеше. Партия комитеты члены буларак, ул Ризванны марксизм әдәбияты, листовкалар белән таныштыра, аны жанлы көрәшкә өнди.

Үз чиратында, татар большевиклары да татарларны патшага каршы руслар белән бергә көрәшергә чакыралар, аерылуның никадәр зыянлы икәнен аңлаталар. Зариф Булатовның «Рус, татар, димә. Барың бер кулдан дошманга каршы сугыш!» (112 бит) дигән сүзләре шуны раслыйлар. Ләкин әле рус революционерларының бөтен сыйфатлары да Коля Кадомсовта гына тупланган дип әйтеп булмый. Революционерларның төгәлләнгән әдәби образын без Нинада күрәбез. Революцион яшьләрнең типик үзенчәлекләре Нина характерында әледән-әле кабатланалар һәм, яңа бер яктан яктыртылып, тагын да эчтәлекле рәвештә, әһәмиятлерәк булып гәүдәләнәләр.

Нина — чын мәгънәсендә чиста һәм намуслы рус хатыны. Ул бөтен йөрәге белән революция эшенә бирелгән, үзе алып бара торган көрәшнең асылына төшенеп, шуннан шәхси ямь, рухи канәгатьлек, ләззәт таба. Яшерен партия эшләрендә Нина үзе белән эшли торган башка кешеләрдән берни белән дә аерылмый. Автор үзенең героинясына Коляга караганда да күбрәк игътибар иткән. Г. Ибраһимов көрәшчеләрдә күрергә теләгән сыйфатларның күбесен Нинада гәүдәләндерә диярлек була. Нина күп революционеркаларга хас тормыш юлы үтә: гимназия тәмамлый, Петербургта курсларда укып йөри, аннан соң түгәрәкләрдә эшли, соңыннан аны туган шәһәренә озаталар. Нина Н. К. Крупскаялар, Е. Л. Стасовалар, А. М. Коллонтайлар төсле революционерка.

Ул шәхси һәм жәмгыять интересларының бер-берсенә мөнәсәбәтен дөрес аңлый. Шул ук вакытта хатын-кызларга хас нечкә хисле дә, катгый да ул. Аның өчен дөньяда ике генә әйбер бар: Коля һәм революция. «Шуңа күрә сөеклесе сөргенгә жибәрелгәч, ул аз гына да икеләнмәде — үзенең язмышын аның белән бәйләде» (370 бит).

Аның өчен революция эше белән шәхси тормыш аерылгысыз. Революция эше өчен ул үзен корбан итә, ләкин моны корбанга санамый, аның тормыштагы бөек бурычы — көчсезләрне рухландыру, аларга көч бирү.

Сөргеннән кайткач, Нина Булат белән яңадан революцион эш башлый. Булат Нинада үзенә ышанычлы ярдәмче күрә, алар

икәү Үзәк Комитет белән бәйләнешкә керү һәм иптәшләрен туплау эшен башлап жибәрәләр.

Г. Ибраһимов бу образга зур бурычлар йөкли: Нина илдә яңа революцион күтәрелешләр көтелгән бер чорда кайтып төшә һәм яшьләр, эшчеләр арасында агитация алып барырга, гомумән, партия кая кушса, шунда эшләргә тиеш була.

Г. Ибраһимов романда, Гриша образы аша, рус характерының тагын бер үзенчәлекле ягын сурәтли. Гриша нык ихтыярлы кеше. Әсәрнең экспозициясендә үк Гриша укучыга үз сүзендә нык торучан революционер булып таныла. Төрмәдә үз хәле дә авыр булуга карамастан, ул көне-төне жәза көтеп яткан Гәрәй турында уйлый, ин яхшы дусты һәм иптәше һәлак булачагына бөтен йөрәге белән кайгыра. Гриша Гәрәйне хөрмәт итә, аңа чиксез ышана, аның өчен Гәрәй татар халкының ин ышанычлы вәкилләренең берсе. Гриша татар халкы турында шушы намуслы һәм кайнар йөрәкле кешеләргә карап фикер йөртә. Шуна күрә, аның Хәбиб һәм Әхтәм Тангатаров белән якын дус булуы да очраклы гына түгел. Бу Гриша характерында бер генә тамчы да шовинизм агуы булмау турында сөйли. Рус образларын ижат итүдә Г. Ибраһимов кабатлаулардан һәм ялыктыргыч тасвирлаулардан ерак тора. Рус халкы вәкилләре язучы өчен гомумән кеше генә түгел, ә һәр конкрет очракта тәмам конкрет, индивидуаль характер да, аның үзенә генә хас тышкы рәсеме, үзенә генә хас характеры бар һәм һәркайсында русларга хас түземлелек, тормышка ачык һәм кыю караш, тәвәккәллек, батырлык, башка милләт кешеләренә дус итеп карау бар.

Геройларның үз-үзләрен тотышларында да, сүзләрендә дә татар иптәшләренә карата кимсетеп карау, аларны политика һәм культура ягыннан кимсетү-түбәнсетү күрмибез. Алар революцион көрәшкә бергә чыкканнар икән, димәк, аларның политик дәрәҗәләре дә тигез.

Бу образларда авторның яшьлек елларда бергә эшләгән рус революционерларына булган хөрмәте чагыла. Руслар татарларны өйрәтүчеләр генә түгел, алар бөек эш өчен бергә көрәшүчеләр, тигез хокуклы кешеләр дә.

Бердәм көрәштә халыкларның тигезлеге һәм аларның дуслыгы нигу бу әсәрдә гүзәл исбат ителгән.

Автор бу көрәшчеләр турында язганда риторик чигенүләр ясамый, романтик характеристикалар бирми, чөнки бу революционерларның эшен реалистик сурәтләү — үзе үк романтика булып яңгырый.

—●●—

Сәнгать кешеләре

Галия Гафиятуллина җырлый

Шулай бер вакыт Татарстанның атказанган артисткасы Галия Гафиятуллинадан мин:

— Сез ничек җырчы булдыгыз? — дип сорадым.

Белмим: ничек җавап бирәсе инде бу кешегә, дип уйланып тордымы, әллә мин биргән сорау бераз сәеррәк тоелдымы?.. Ул бер мәлгә аптырабрак калгандай булды, ягымлы күзләрен кыскалап, миңа карап көлемсерәп торды. Аннан сөйләп китте:

— Җыр яратырга мине әнием өйрәтте. Аның тавышы бик матур иде. Эш арасында да, буш вакытларында да гел көйләп йөри, кайгысын да, шатлыгын да җыр белән уртаклаша. Хәтта кышкы озын кичләрдә безгә сөйләгән тылсымлы әкиятләрен дә еш кына берәр көй белән тәмамлый иде. Әле әнә шул бәләкәй чаклардан ук, аңа кушылып, мин дә көйлим, әнием шикелле итеп җырларга тырыша идем.

— Э инде профессиональ җырчы булырга,—дип дәвам итте Галия ханым, — Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә бөтен яшьлеген, көчен биргән талантлы оештыручы, әнием кебек үк бик кадерле кеше, Татарстанның атказанган артисткасы Зөләйха ханым Әхмәтова ярдәм итте...

Бу хәл моннан күп еллар элек була.

Казан сәхнәләреннең берсендә үзешчән сәнгатьтә катнашучыларның шәһәр күләмендәге олимпиада концерты бара. Һәвәскәр җырчылар, музыкантлар, бер-бер артлы сәхнәгә чыгып, үзләренең осталыкларын күрсәтәләр. Чират Галиягә җитә. Мехкомбинатта эшләүче бу яшь кыз үзешчән сәнгать түгәрәгенең актив члены икән. Ул инде күп тапкырлар төрле кичәләрдә, концертларда чыгыш ясаган...

Яшь җырчы, чишмәдәй саф, көчле тавышы белән, залдагыларның мәхәббәтен яулап ала: көчле алкышлар яңгырый. Беренче рәттә комиссия кешеләре утыра. Арадан берсе — Зөләйха Әхмәтова. Яшь җырчы Галия Гафиятуллина белән Зөләйха ханым беренче мәртәбә шушы концертта очраша.

Г. Гафиятуллина (сулда) һәм З. Әхмәтова.

— Каушап кына сәхнәгә чыккан гади, үзешчән җырчының, әле кемгә дә таныш булмаган Галия Гафиятуллинаның тавышы шулкадәр ягымлы, шулкадәр чиста яңгырады, — дип сөйли З. Әхмәтова, — мин, үзем дә сизмәстән, аны бирелеп тыңладым. Хәтерлим: ул чагында Галиянең тавышын Ангара елгасы белән чагыштырган идем. Ангара суына көмеш акча ташласаң, аның бөтерелә-бөтерелә аска төшкәнен төпкә житкәнче күреп торасың. Галиянең тавышы да үтә күренмәле, чылтырап аккан саф суны хәтерләтте. Анарда табигый талант булуы ап-ачык иде...

Зөләйха ханым Галия Гафиятуллина белән кызыксынып кына калмый, аны ансамблгә җырчы итеп чакыра. Галия беренче гастрольләр вакытында ук укытучысының үзенә булган ышанычын тулысы белән аклый. Концертларның берсендә киная бер артистка авырып китә. Теләсә теләмәсә дә, Галиягә аны алыштырырга туры килә. Шулай, башлап җырлаучы буларак, ул беренче тапкыр сәхнәгә чыга. Һәм тамашачыларның күңелен били, уңыш казана.

Зөләйха Әхмәтова яшь артистканың табигый талантын үстерү, аның тавышын бөтен үзенчәлекләре белән саклап калу өчен күп тырыша. Һәркөн репетицияләр уздыра, хәтта, ансамбль хорына җырчыларны да Гафиятуллина тавышына карап җыя. Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында күренекле композитор, дәүләт премиясе лауреаты Дзержинский, ансамбль концертын тыңлаганнан соң, бу коллективны, тавышының сафлыгы өчен, «гыйффәтле» дип атый. Э Гафиятуллинаның матур җырлавын, репертуары дөрес сайлануын аеруча билгеләп үтә. Дөрестән дә, артистканың репертуары бай, ижат диапазоны гаять киң. Ул борынгы татар һәм башкорт халык көйләрен, совет композиторларының төрле жанрдагы җырларын зур осталык белән башкара. Ялгыз да, хор белән дә җырлый. Галия Гафиятуллина җырының мәгънәви һәм музыкаль эчтәлеген үзенчә ача, аны үзенә генә хас бизәкләр белән баета. Берәүне дә кабатламый, беркемгә дә иярми.

Менә «Фазыл чишмәсе». Галия Гафиятуллина башкаруында бу җыр матур, кояшлы көндә чылтырап аккан саф сулы чишмәне күз алдына китереп бастыра. Артисткаын үз тавышы да гүя чишмәдәй чылтырап, тамчылар чәчрәтеп агыла.

— Ул теләсә нинди җырны башкара ала, — диләр Галия ханым белән бергә эшләүче иптәшләре һәм мисал итеп шундый бер вакыйганы китерәләр:

Бервакыт, ансамбль репертуарын пластинкаларга язып алыр өчен, Мәскәүдән махсус бригада килә. «Кара урман» көен язабыз дигәндә генә башлап җырларга тиешле җырчының юклыгы беленә. Аптырашта калалар.

Г. Гафиятуллина (сулда), З. Солтанова.

Шуннан берәү: «Кәяле, Галия, булмаса, син җырлап кара»,— ди. Галия ханым риза була. Никадәр моң бу көйдә! Никадәр сагыш һәм эчке дәрт анда! Гафиятуллина башкаруында ул җыр сине кара урман эченә алып керә, табигатьнең гажәеп матурлыгы, кешеләрнең авыр язмышы турында сөйли.

Ансамбль репертуарындагы ин уңышлы җырларның тагын берсенә тукталасы килә. Ул радио һәм концерт тыңлаучыларыбызга яхшы таныш: «Бормалы су».

Җырның язылу тарихы турында композитор Заһид Хәбибуллин болай сөйли:

— Культура министрлыгы һәм филармония җитәкчеләре Нәкый ага Исәнбәт белән миңа уңган, тырыш, чибәр кызларыбыз турында яңа җыр язарга тәкъдим иттеләр. Без бу эшкә бик теләп алындык. Нәкый аганың шигыре гаять матур килеп чыкты.

Шигырь мине бик дулкынландырды. Күңелдә үзеннән-үзе көй яңгырый башлады. Түзмәдем, Зөләйха ханым Әхмәтова янына киттем. Уйнап та, җырлап та күрсәттем. Җыр аңа да ошады. Ансамбльнең балетмейстеры Фәйзи Гаскәрев, көйне тыңлагач, «бу шундый җыр, аны сылу кызлар биюе белән алып барырга кирәк», диде. Бию эзерләнде. Биюче кызларыбыз су төсендәге җиңел, ефәк күлмәкләргә киенделәр. Ниһаять, барысы да әзер. Галия Гафиятуллина җырны башлап җибәрә. Залга, талгын гына аккан елгадай, моң тарала башлый:

Ай бормалы, бормалы ла,
Бормалы су буйлары,
Бормалы су буйларында
Үскән зифа буйлары...

Менә ул көчәя, үсә. Солистканың җырына ансамбль дә кушыла:

Ал гөл дә таң гөл,
Сез кадерле яшь кызлар,
Сез уңган, сез чибәр
Ил күгендә йолдызлар.

Ул да түгел, алгы планга кабат башлап җырлаучы чыга:

Дан безнең кызларыбызга,
Гөл сибик юлларына...

Күз алдына бай табигатебезнең бер күренеше — киң тугайлы елга буйлары килеп баса...

Әйе, Галия Гафиятуллинаны ансамблгә чакырып Зөләйха Әхмәтова ялгышмады. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле республикада гына түгел, бөтен Союзда зур популярлык казанган иҗади коллективларның берсе. Кайда гына булмасын, Мәскәү һәм Ленинградтамы, Украина һәм Себердәме, Төньяк районнарында һәм Казагыстанда, Әзербәйҗан һәм Урта Азиядә һәм, ниһаять, чит илләрдә чыгыш ясыймы, аның концертларын зур хөрмәт, кайнар алкышлар белән каршылыйлар. Бу уңышта Татарстанның атказанган артисткасы Галия Гафиятуллинаның да өлеше аз түгел.

Минем алда ансамбль турында төрле елларда язылган газета һәм журнал рецензияләре, мәкаләләр, очерклар... Татар, башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк һәм башка күп телләрдә. Аларның һәрберсендә Галия Гафиятуллинаның исеме телгә алына:

«Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленең башлап җырлаучысы Галия Ирдәш Гафиятуллина татар совет композиторлары әсәрләрен һәм халык җырларын бик оста башкарды. Аның моңлы һәм матур җырлавын тамашачылар кат-кат көчле алкышлар белән каршыладылар...»

«Галия Гафиятуллина озын, моңлы көйләрне, шулай ук дәртле, шаян җырларны да оста башкаруы белән күптән инде Башкортстан тамашачыларына билгеле...»

«Татар җыры гажәеп!

Идел суы кебек җыр дәрьясы.

Урал урманнары сандугачларыннан да моңлы яңгыраган иркә назның. Татарстан жиреннән очып, Казакъ даласында канат кагуы бит бу. Менә Алма-Ата өстендә дә татарның былбыл кызы Гафиятуллина җыры яңгырап күтәрелде...»

Галия Гафиятуллинаның иҗади эшчәнлегенә 20 ел тулды. Нихәтле җыр җырланган бу елларда, никадәр җир гизелгән. Күпме җырлар меңнәрчә тыңлаучыларның тормышына ямь китереп, эшкә, яңа уңышларга рухландырган.

Хәзер Галия Гафиятуллинаның иҗаты чәчәк аткан чагы, ул үзенең яраткан эшендә яшьләрчә дәртләнеп эшли, аның йөрәк ялкыны белән җылытылган җырлары ераклларга таралып яңгырый.

ЗӘМИРӘ САЛИКОВА.

—✦—

1966 елның ноябрь ахырларында Качалов исемендәге Зур драма театры бинасында республика театрлары хезмәткәрләренең киңәшмәсе уздырылды. Ике көн буе дәвам иткән бу киңәшмәдә театрларыбыз эшчәнлегенә төпле бәя бирелде, иҗат коллективлары алдында торган зур, мөһим бурычлар турында сүз барды.

Журналыбызның бу санында укучыларыбызга Татарстан Культура министры Булат Гыйззәтуллинның әлеге киңәшмәдә сөйләгән докладын тәкъдим итәбез. Доклад кыскартылып бирелә.

СӘНГАТЬТӘ ЯҢА ҮРЛӘРГӘ

Билгеле, һәр театрны, беренче чиратта, репертуар мәсьәләсе кызыксындыра. Шуңа күрә дә театрларыбыз хакындагы сүзне нәкъ менә репертуар мәсьәләсеннән башлыйсы килә. Үткән сезонда республикабыз театрларында 53 яңа спектакль куелды. Аларның 43 е совет драматурглары, 4 се Көнбатыш Европа язучылары әсәрләре буенча эшләнде. Тагын ике классик пьеса («Зыковлар», «Һәр акыллыга гадилек кирәк») һәм ике классик опера («Князь Игорь» һәм «Тоска») күрсәтелде. Күрәсез, репертуарның сиксән процентган артыграгын совет язучылары иҗат иткән әсәрләр алып тора. Сүз дә юк, совет театрлары репертуарында төп урынны үз язучыларыбызның әсәрләре алырга тиеш тә.

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры үткән сезонда сигез спектакль әзерләде. Элеккерәк еллар белән чагыштырганда, шактый уйлап төзелгән репертуар иде ул. Спектакльләрнең тематик яктан төрлелеге театрның эзләнүе төрле алымнар һәм чаралар белән тамашачыга йогынты ясарга омтылуы хакында сөйли. Театрның үткән елгы репертуарында «Муса Җәлил», «Зөбәйдә — адәм баласы», «Күзләре нинди иде?», «Соңгы хат», «Ата хакы — тәнре хакы», «Гүзәлем әсәл», «Хуҗа Насретдин» кебек пьесалар бар иде. Трагедия, драмалар, комедияләр... Рус, башкорт һәм кыргыз әдәбиятларыннан әйбәт кенә тәрҗемә әсәрләре.

Икеләнүсез әйтергә була, Академия театры үткән сезонның уңышлы

тәмамлады. Коллектив ижади уңышларга иреште. Бу, беренче чиратта, «Гүзәлем әсәл» спектакленә карый. «Муса Җәлил» һәм «Хужа Насретдин» спектакльләрен дә тамашачы яратып каршылады.

Татар дәүләт академия театрында талантлы өлкән буын актерларның бөтен бер плеядасы барлыгын һәркем белә иде. Ә яшьләр? Аларның ижади үсеш юллары нинди соң? Бу сорау безне һәрвакыт борчып килде.

Үткән сезон театрда өметле һәм ышанычлы алмаш булганлыгы исбатланды. «Гүзәлем әсәл», «Муса Җәлил», «Соңгы хат» спектакльләрендә яшьләр чынлап та талантлы, зур һәм җитди иҗат эшенә сәләтле икәнлекләрен күрсәттеләр.

«Гүзәлем әсәл» спектакленең төп уңышы аның бүгенге заман белән аваздаш булуында. Бу спектакль белән театр үз труппасында талантлы актерлар булганлыгын раслады. Чыңгыз Айтматов әсәрендәге персонажлар — безнең заманның гади кешеләре. Игътибар беләнрәк карагыз әле, нинди зур эчке культурага һәм акыл көченә бай образлар алар. Автор чын мәгънәсендә шигъри, лирик хисләргә бай әсәр язган. Театр исә шул лиризмны һәм шигъриятне түкми-чәчми тамашачыга житкерә алды. Бу — зур казаныш. Беренче карашка, актерлар үз рольләрен бик жиңел, көч куймый гына башкаралар кебек тоела. Әнә шунда режиссерның (әсәрне сәхнәгә Үзбәкстан ССРның халык артисты Т. Ходжаев куйды) бөтен осталыгы күренә дә инде. Бу спектакльдә икенче дәрәҗәдәге персонажлар, эпизодик рольләр юк диярлек. Шуна күрә спектакль бөтен бер ансамбль булып кабул ителә.

Әлбәттә, спектакльдә аерым әһәмияткә ия булган рольләр бар. Алар: Ильяс (артист Р. Тажетдинов), Әсәл (артистка Н. Гәрәева), Хәдичә (артистка Ш. Әсфәндиярова) һәм Байтимер (Ш. Биктимеров). Бу актерларның сәләтле булуына берәү дә шикләнми иде. Шушы спектакльдән соң, аларның осталыгы бөтенләй яңа яктан ачылып китте. Уңышның сере актерның үзе башкарырга тиешле образның рухи дөньясын ачу өчен кирәкле чараларны төгәл сайлый белүенә, хисләрне тыйнак, гади итеп тамашачыга житкерә алуына бәйләнгән. Әмма бу гадилек образны ярлыландырмый. Киресенчә, аны тирәнәйтә генә. Тышкы гадилек пәрдәсе артында зур эчке киеренкелек сизелеп тора. Спектакльдә озын-озын паузалар күп. Ләкин алар эчтәлексез, «үле» паузалар түгел. Актерның кинәт сүзсез, тынып калуына карамастан, тамашачы аның киеренке фикер агышын, бу минутта нинди уй-кичерешләр белән янып яшәвен тоя. Бу исә, үз чиратында, артистның сәхнәдә фикер йөртә алу сәләте, югары, интеллектуаль культурага ия булуы турында сөйли. Шуна да «Гүзәлем Әсәл» тамашачыларның һәм тәнкыйтьчеләрнең зур бәясен алды, ин яҳшы спектакль дип танылды.

«Гүзәлем Әсәл» — рус драматургы тарафыннан сәхнә әсәре итеп эшләнгән. Аны сәхнәгә үзбәк режиссеры куйды. Декорацияләрен немец художнигы ясады. Сәхнәдә татар артистлары уйнады. Бу — гыйбрәтле хәл.

Яшь актерларның осталыгы хакында сүз чыккан икән, «Муса Җәлил» спектакле һәм анда төп рольне башкаручы Ринат Тажетдинов турында аерым әйтеп үтмәү килешмәстер.

Тажетдиновның Мусасы коеп куйган, курку белмәс герой гына түгел. Юк, ул — үз Ватанын чиксез ярата белгән коммунист — көрәшче, кин күңелле, мөлаем, сөйкемле, тормышны сөюче совет кешесе. Ләкин бу әле Муса куркак һәм кыенлыклар алдында тез чүгүче кеше дигән сүз түгел. Киресенчә, сугышка ул үз теләге белән китә һәм алдына куйган максатына ирешү өчен аяусыз көрәшә...

Үткән сезонга күз салсак, театрда яшь артистларның торган саен активлаша баруларын күрербез. Бу — шатлыклы күренеш. Чөнки театрның киләчәге яшьләр кулында. Ә мондый сәләтле яшьләргә эстафетаны ышанып тапшырырга мөмкин.

Бер үк спектакльгә төрле буын артистларны катнаштырып, театр

житәкчеләре дөрес эшлиләр. Җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәя алган «Ата хакы — тәнре хакы», «Хужа Насретдин», «Муса Җәлил» кебек спектакльләр шул турыда сөйли.

Үткән сезонда, уңышлы спектакльләр белән бергә, театр сәхнәгә начар спектакль дә чыгарды. Сүз «Күзләре нинди иде?» хакында бара.

Без еш кына олы гражданлык хисләрен күтәргән әсәрләр булмаудан зарланабыз. Ә менә Ә. Баянов пьесасында шундый мәсьәләләр бар иде. Һәм театр бу әсәр аша безнең тормыштагы әһәмиятле, зур проблемалар турында сөйли алган булыр иде. Әмма коллектив бу бурычны башкарып чыга алмады.

Аерым-аерым алганда, Татар академия театрының үткән сезонда чыгарган спектакльләренең күбесе ярыйсы гына әйбәт тәэсир калдыра. Инде шул спектакльләрнең бөтенесен бергә җыйсаң, сәер генә күренешкә тап буласын. Аның спектакльләрен караудан алган тәэсир капма-каршылыклы. Чынлап та, аның сәхнәсендә барган спектакльләрнең һәрберсе а к а д е м и я театры дәрәҗәсендә югары эшләнгән дип булмый. Татар театрында төрле мәктәпләр, төрле стильләр аралашкан. Театрның үз йөзен булдыру өчен бер типтагы әсәрләр кую гына мәҗбүри түгел, билгеле. Коллективның үз ижат кредосы, театр сәнгатенә карата үз фикерләре булырга тиеш. Моңа ирешү жинел түгел, әлбәттә. Әмма ни генә булмасын, Академия театрындагы иптәшләр бу хакта бик житди уйланырга тиешләр.

Үткән сезон Качалов театры өчен дә үзенчәлекле булды. Сезонның беренче яртысында ул «Дженни Герхард», «Берлиндагы эссе җәй», «Солдат һәм Ева», «Дүртенче», «Тауларда» исемле спектакльләр чыгарды. «Дүртенче»не санамаганда, калган барлык пьесалар репертуар сайлауда театрның гажәп зур зәвыксызлык һәм талымсызлык күрсәтүе хакында сөйлиләр.

Бәхеткә каршы, сезонның икенче яртысында театр уңай якка искен борылыш ясый алды. Репертуарга, «Синең өчен... исендә тот!», «Физиклар һәм лириклар», «Зыковлар», «Без туган йорт», «Мәзәкче» шикелле, чын сәнгать әсәре алдына куела торган зур теләкләргә жавап бирерлек әсәрләр кертелде. Арада классик пьеса да һәм татар авторларының әсәре дә бар (югыйсә, Качалов исемендәге театрда татар драматургларының пьесалары инде байтактан күренми иде). Әмма мәсьәләне әйбәт әсәр сайлый белү генә хәл итми әле, сайланган әсәрне тиешле дәрәҗәдә куясы да бар. Бер дә шикләнмичә әйтергә мөмкин, сезонның икенче яртысында тамашачыга тәкъдим ителгән әлеге спектакльләр чын сәнгать югарылыгында торалар.

Рөстәм Кутуй һәм Алмаз Бикчәнтәевләрнең «Синең өчен... исендә тот!» исемле яңа пьесаларын сәхнәгә Н. Орлов чыгарды. Спектакльдә театрның бөтен труппасы диярлек катнаша. Әмма, моңа карап, спектакль таркауланмый да, эстрада концертына да охшап калмый. Чөнки әсәрнең күп төрле компонентлары бер уртак идеягә — совет кешеләрендәге иң күркәм сыйфатларны ачып бирүгә буйсындырылган.

«Синең өчен... исендә тот!» — шигъри-героик спектакль. Анда гаделсезлеккә, ваемсызлыкка каршы сугышчан протест белдерелә.

Бу спектакльдә без күреп гадәтләнгән мәгънәдә сюжет та, конкрет геройлар да, аерым кешеләрнең язмышлары да юк кебек. Анда традицион конфликт та, геройларның уңай һәм кирегә бүленеше дә юк. Бу — символик спектакль. Анда фәлсәфи гомумиләштерү көчле.

Әсәр «Синең өчен... исендә тот!» дип атала. Һәм аның бик төгәл адресаты да бар — ул бүгенге яшь буын. Исендә тот, йөз меңнәрчә кешеләрнең батырлыгы синең өчен эшләнде, синең өчен иң яхшы кешеләр үзләренең гомерләрен бирделәр! Боларның берсен дә онытма, берсен дә исеңнән чыгарма!

Шушы фикер спектакльнең башыннан ахырынача кызыл җеп булып сузылып килә. Театр заман яшьләре белән эшлекле сөйләшү алып бара. Бу — тормыш турында кешенең тормышта тоткан урыны

хакында партияле сөйләшү. Театр, кырыс таләпчәнлек белән, тормыштагы гаделсезлекләргә, кимчелекжитешсезлекләргә каршы килешмәүчен көрәшкә өнди. Залда Михаил Кульчицкийның нәфрәт һәм ачу тулы юллары яңгырый: «Дөньяда иң коточкыч нәрсә — ваемсызлык». Бүгенге яшь буын! Безнең этиләребез синең тыныч һәм бәхетле тормышың өчен көрәштеләр, һәлак булдылар. Алар синең өчен, жир йөзендә тормыш дәвам итсен өчен, коточкыч газаплар, хәтта үлем каршында да куркып чикмәделәр, һәм үлгәннән соң да исән калдылар. Алар безнең хәтердә, безнең йөрәкләрдә яшиләр!

Спектакль Муса Җәлилнең 60 еллык юбилеена багышлап куелды. Ул Муса турында һәм аның турында гына да түгел. Ул кешенең ныклыгына, кыюлыгына, аның турылыклылыгына, азатлыкка омтылышына, коммунизмның бөек идеалларына дан жырлаучы гомумиләштерелгән сәхнә әсәре буларак кабул ителә. Ул Фучик турында, Хикмәт турында, Тельман һәм Габриэле Пери турында, тагын бик күп көрәшчеләр турында сөйли.

Качаловлылар быелгы сезонны «Зыковлар», «Без туган йорт», «Мәзәкче» спектакльләре белән башлап жибәрделәр, һәм, әйтергә кирәк, ул әсәрләр югары сыйфатлы итеп куелдылар. Беренче карашка, төрле эпохалар, илләр, кешеләр турында сөйләүче, төрле мәсьәләләр күтәрүче бу әсәрләр арасында уртаклык юк шикелле. Әмма бу беренче карашка гына шулай. Чөнки шушы өч спектакльнең һәркайсы өчен дә уртак булган төп бер линия бар һәм ул театр коллективының ижат линиясе белән дә бик тәңгәл килә. Сүз граждanлык һәм кешелеклелек хисе турында бара. Билгеле, бу хис һәр спектакльдә үзенә бертөрлерәк итеп бирелә: «Без туган йорт» спектаклендә, мәсәлән, шактый йомшак һәм ягымлы, ә «Зыковлар» һәм «Мәзәкче»дә, киресенчә, кырыс һәм таләпчән төс ала. Әмма, ничек кенә булмасын, олы йөрәклелек, кешелеклелек хисе спектакльләрнең өчесе өчен дә уртак һәм шушы уртаклык беренче карашка үзара һичбер охшашлыклары булмаган өч әсәрнең бер үк театр сәхнәсендә уңышлы гына уйналып килүләрен тулысынча аклый.

Качалов исемендәге зур драма театры сәхнәсендә бүгенге совет һәм чех язучылары пьесалары да (режиссерлар Э. Митницкий һәм Г. Соколов), М. Горькийның революциягәчә үк ижат ителгән әсәрләре дә (режиссер Н. Орлов) заманча яңгыраш таба алдылар.

«Зыковлар» — соңгы елларда качаловлылар ижат иткән иң уңышлы спектакльләрнең берсе.

«Без туган йорт» спектакле дә тамашачының хөрмәтен казанды. Һәм бу гажәп тә түгел. Спектакль башыннан алып ахырынача рухи күтәренкелек, йөрәк җылылыгы, кешелеклелек белән сугарылган, һәм тамашачыда да шундый үк тойгылар уята. Монда да кире образлар һәм кыенлыклар бар, әлбәттә. Шуның өчен тормыш ич ул. Әмма Э. Митницкий тарафыннан сәхнәгә куелган бу спектакльнең төп юнәлешен алар түгел, ә тормышны әйдәп баручы чын кешеләр билгелиләр. Спектакль оптимизм белән сугарылган. Анда катнашучы актерларның уенына сокланмаска мөмкин түгел, аларның һәркайсы үз ролен менә дигән итеп башкаралар. Һәм аларның һәркайсы турында бик жентекләп сөйләшергә, бик күп мактау сүзләре әйтергә була. Режиссерның һәм артистларның осталыгы биредә бик уңышлы төстә бергә үрелгән. Нәтиҗәдә, бердәм һәм гажәп әйбәт спектакль барлыкка килгән. Сүз дә юк, качаловлыларның әле генә атап үтелгән спектакльләре дә аерым кимчелекләрдән азат түгелләр. Әмма ул кимчелекләр генә ирешелгән уңышларның әһәмиятен киметә алмыйлар.

Драма театрларыбызның эш нәтиҗәләре әнә шундый. Сүз соңында тагын бер генә нәрсә өстисе килә: театрның чын йөзе нигездә аның репертуары, сәхнәгә ниндн әсәрләр күтәрүе һәм шушы әсәрләрне режиссураның ничек аңлатуы, аларның тамашачыга ничек житкерелүе белән билгеләнә. Шуна күрә, сән-

гать юлында өзлексез эзләнүче, һәрвакыт яңалыкка омтылучы коллектив кына уңышка ирешә ала.

* * *

Хәзер күчмә театрлар турында берничә сүз. Зур шәһәрләрдән, ягъни зур культура учакларыннан еракта булган авылларда һәм промышленность пунктларында яшәүчеләргә хезмәт күрсәтүчеләр булараk, алар гаять зур эш башкаралар — культураны киң халык массалары арасында пропагандалыйлар. Әнә шуна күрә, аларның хезмәте аерым игътибарга, хөрмәткә, мактауга лаек.

Моннан бер ел элек күчмә театрлар арасында иң алда әлмәтлеләр бара иде. Әмма тормыш һаман да бер көе генә акмый. Һәм быел беренчелекнең Татар дәүләт күчмә театрында икәнлеген билгеләп үтәбез. Моннан элекке сезонда аның репертуарында яңа оригиналь әсәрләр булмады, ә үткән сезонда ул үз сәхнәсенә өр-яңа өч әсәр күтәрде. Болар — Ю. Әминовның «Мин — Гөлүзә» («Өти балак»), М. Шәрифуллинның «Туганнар» һәм Т. Закировның «Яучылар» пьесалары. Алар барысы да театр коллективының турыдан-туры катнашы белән ижат ителгән әсәрләр. Моннан тыш, театр ике тәржемә әсәре— Арбузовның «Минем мескен Маратым» әсәрен һәм башкорт язучысы В. Сәйфуллинның «Умырзая»сын да үз репертуарына алды. Әлбәттә, бу спектакльләр сыйфат ягыннан бөтенесе дә бер үк дәрәҗәдә тормыйлар. Арада «Минем мескен Маратым» шикелле уңышсызы да, «Туганнар» кебек урта кул дәрәҗәдә генә куелганы да бар иде. Ә калган өчесе, һичшиксез, әйбәт спектакльләр.

Кадрлар мәсьәләсенә килгәндә, Татар дәүләт күчмә театры, башка күчмә театрларга караганда, әйбәтрәк тәэмин ителгән. Аның труппасында хәзер югары белемле ике режиссер, Казан театр училищесын тәмамлап килгән бер төркем яшь актерлар бар. Шуна күрә бу театрга карата таләп тә зуррак.

Ә менә Әлмәт һәм Минзәлә театрларының үткән сезонындагы репертуарлары безне чын-чынлап борчый. Минзәлә театрының репертуарына күз салыгыз: Мдиванинның «Синең бабаң», Бруштейнның «Шомлы төн», И. Соболевның «Үлем карары», Мирзаһитовның «Чәчәкләр бакчасы», Хәй Вахитның «Соңгы хат»ы...

Бу әсәрләр начар, аларны куярга ярамый, дип әйтергә теләмим мин. Һич юк. Әмма ни өчен арада шушы театр сәхнәсенә адреслап язылган бер генә әсәр дә юк соң? Бусы аңлашылмый. Үткән ел оригиналь әсәрләргә карата тиешле таләпчәнлек белән килмәгән өчен, театр бик нык тәнкыйтьләнгән иде. Ләкин бу бит драматурглар белән бәйләнешне өзәргә, үзең өчен яңа әсәрләр эзерләү эшеннән бөтенләй читләшергә, дигән сүз түгел әле. Театр җитәкчеләре бу нәрсәне искә алырлар дип ышанасы килә.

Әлмәт театрында да шундыйрак хәл. Үткән сезонда ул үз репертуарына төрле елларда Академия театры сәхнәсендә барган әсәрләрне — А. Гыйләҗевның «Көзге ачы жилләрдә», Собконың «Икенче фронт артында», М. Кәримнең «Ай тотылган төндә», К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл», Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә—адәм баласы» пьесаларын кергән иде. Сүз тагын да алынган әсәрләрнең сыйфаты хакында түгел, ә театрның үз репертуарына карата эзлекле бер фикере булмау турында бара. Бу театр да үзе өчен яңа авторлар, яңа әсәрләр эзләми, бу театр да драматурглар белән эш алып бармый.

* * *

Хәзерге вакытта балалар театрларына игътибар аеруча зур. Һәркемгә билгеле булганча, балалар белән эшләү, аларны сәнгать дөньясына тарту — искиткеч катлаулы, мәшәкатьле һәм күп көч куюны сорый торган жаваплы хезмәт. Балалар театрында сәнгать белән педагогика үзара бәйләнеп-үрелеп баралар. Шуна күрә театр үз эшен педагогик таләпләрдән дә чыгып оештырырга тиеш.

Курчак театрының үткән сезонда эшчәнлегендә сөенерлек тә, көенер-

лек тә хәлләр байтак. Сезон дәвамында театр үз труппасының ижади составын яхшырту, ныгыту өчен кайбер чаралар күрде.

Әмма Курчак театры турында сөйләгәндә дә, безне, беренче чиратта, репертуар мәсьәләсе борчый. Үткән сезонда театр үз тамашачыларына «Кыю экият», «Күңелле экиятләр», «Яңа ел сәхнәсе» исемле спектакльләр күрсәтте. Боларның башлагы икесе әйбәт кенә эшләнгән. Сүз әйтерлек түгел. Әмма алдан уйлап планлаштырылган берничә спектакльне театр сәхнәгә бөтенләй чыгара алмады. Сүз Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил шигырьләре буенча эшләнергә тиешле спектакльләр турында бара. Татар труппасы исә тамашачыларга бер генә яңа спектакль дә тәкъдим итә алмады...

Күптән түгел театрга сәләтле, бай фантазияле баш режиссер килде. Димәк, Курчак театры якын киләчәктә уңышлы спектакльләр дә бирә алыр дип өметләнергә нигез бар. Шулай була күрсен.

* * *

Үткән сезонда опера һәм балет театры җиде премьера чыгарды: «Князь Игорь», «Тоска», «Дим буенда» опералары; «Чегәннәр бароны» опереттасы; «Золушка» һәм «Маскарад» балетлары һәм балалар өчен язылган «Песи йорты» операсы.

«Тоска» операсы белән «Золушка» балеты коллективның зур ижат мөмкинлекләре барлыгын раслый торган спектакльләр. Кызганычка каршы, ул мөмкинлекләр күп очракларда тиешенчә файдаланылмыйлар.

Соңгы елларда театр милли репертуарны баету хакында житәрлек борчылмый диясе килә. Үткән сезонда татар телендә нибары бер спектакль («Дим буенда») куелды. Анысы да республиканың музыкаль тормышын жанландырып жибәрерлек вакыйга була алмады. Татар спектакльләренең репертуарда булган кадәресе дә әйбәт хәлдә түгел. Алар, еш кына, тузып беткән декорацияләр белән куелалар, мизансценалар күптән онытылган...

Ярый, инде милли репертуар ярлы, ди. Ә классик спектакльләр, тугандаш халыклар яки чит ил композиторларының әсәрләре белән эш ничегрәк тора соң? Шәп түгел. Шебалин, Тактакишвили, Спадавеккия, Баласанян, Равель, Моцарт, Сметана, Бриттен һәм башка бик күп, бик күп күренекле исемнәрнең берсе дә юк.

Дөрес, театр житәкчеләре матур гына планнар да төзиләр. Ләкин план реаль репертуар түгел бит әле. Аны тормышка ашырырга кирәк. Инде эшләр әлеге планны тормышка ашыруга килеп терәлдеме — алдан уйланган исемнәрнең күбесе, теге яки бу сәбәп аркасында, репертуарга кертелмиләр, тамашачыга барып житә алмыйча калалар.

Балет труппасында хәтта андый план да юк. Ә бу, үз чиратында, коллективта ижади борчылу һәм канәгатьсезлек хисе тууга китерә.

Балет труппасының эшенә театрда баш балетмейстерның булмавы да тискәре йогынты ясый, әлбәттә.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, шундый нәтижә ясарга була. Театрдагы күп эшләр үз агымына куелган. Жирле авторлар белән эшләү бөтенләй юк дип әйтерлек. Эш планнары реаль мөмкинлекләрдән чыгып төзелмиләр һәм бик еш үзгәреп, алышынып торалар. Тамашачылар белән эш алып бару да бик йомшак куелган. Шуның нәтижәсендә театрга йөрүчеләрнең саны кими бара. Кайбер спектакльләргә нибары 100—150 кеше килә...

Әлбәттә, югарыда санап үтелгән кимчелекләр өчен бөтен гаепне театр житәкчеләре өстенә генә аударып калдыру да бик үк дөрес булмас иде. Без моны яхшы аңлыйбыз. Ләкин шул ук вакытта театр коллективы көче белән дә күп кенә кимчелекләрдән арынырга мөмкин бит.

* * *

Бу мәкаләдә республика театрларының үткән сезондагы эшләренә кыскача күзәтү ясалды. Хәзер кайбер нәтижәләр ясыйк.

Театрның йөзе, позициясе нигездә репертуар белән, ягъни сәхнәгә ку-

елган әсәрләрнең сыйфаты, сәнгатьчә кыйммәте белән билгеләнә. Коллективның әсәрне тамашачыга җиткерү осталыгы да гаять зур әһәмияткә ия.

Сәнгать ул — өзлексез хәрәкәт, эзләнү, яңа сүз әйтү. Шушы хәрәкәтнең берәр ноктасында туктал-дыңмы, син инде артта калдың дигән сүз. Сәнгатьнең яшәү көче, аның тормышчанлыгы һәм кирәклеге — яңалыкка омтылуда, даими канәгатьсезлек тойгысында, өзлексез хәрәкәттә. Сәнгатьтә үзгәрешсез критерийлар юк, үзгәрешсез таләпләр генә бар. Һәм аларның иң әһәмиятлеләре — идеялелек, партиялелек, заманчалык һәм гражданлык пафосы. Болар — сәнгатьтә яшәтә, әйдәп бара торган төп, нигез сыйфатлар.

Үткән елгы сезон безгә нинди генә уңышлар, казанышлар китермәсен, тынычланып калырга бернинди нигез юк. Театрларыбыз алдында торучы күп кенә проблемалар әле һаман да хәл ителмәгән көе кала киләләр. Үз чорыбызга багышлап язылган яхшы әсәрләр җитешми. Бу хакта без күптәннән сөйләшеп киләбез, ә үзгәреш һаман күренми. Бәлки, моның сәбәбе драматургларыбызның тормышны белеп житкерməүләрендә генә дә түгелдер. Бәлки, бүгенге тормыш конфликтларын чишү өчен яңа драматик алымнар табарга кирәктер. Соңгы елларда безнең драматургиядә әхлак-этик проблемаларны күтәреп чыккан әйбәт кенә пьесалар язылды. Әмма алар да чорыбызның катлаулы, зур проблемаларын канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә хәл итә алмыйлар.

Без хәзер Бөек Октябрьның илле еллык юбилее алдында торабыз. Театрларыбызның хәзер дәвам итә торган яңа сезоны шушы бөек бәйрәмгә лаек булырлык дәрәҗәдә үтсен өчен, без үзебезнең уңышларыбызга да, житешсезлекләргә дә реаль һәм аек карап эш итәргә тиешбез.

Булат ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.

Укучылар соравы буенча

Фуат Вәлиев,
тарих фәннәре кандидаты.

БОРЫНГЫ БАБАЛАРЫБЫЗ КЕМНӘР?

ХӨРМӘТЛЕ РЕДАКЦИЯ!

Журналыгызның берәр санында халкыбызның борынгы бабалары кемнәр булуы турында язсагыз иде. Татар халкы борын-борыннан Идел буенда яшәгәнме, әллә башка берәр җирдән күчеп килгәнме? Бу сорауга җавап бирү, минемчә, күпләр өчен кызыклы да, файдалы да булыр иде.

Тәскирә ГАЛИЕВА,
Ижевск шәһәре.

Илтәш Галиеваның бу хатына җавап бируне үтенеп, без тарих фәннәре кандидаты Фуат Вәлиевкә мөрәҗәгать иткән идек. Түбәндә аның Т. Галиевага җавабын урнаштырабыз.

Идел буе һәм Урал буе татарларының бабалары кемнәр булган? «Татар» сүзе кайдан һәм ничек килеп чыккан?

Бу сорауларны безгә, татар делегатларына, дөнья халыкларының антропологиясе, этнографиясе һәм сәнгате проблемаларын өйрәнүгә багышланган һәм 1964 елның җәендә Мәскәүдә үткәрелгән Җиденче Халыкара конгресста катнашкан чит ил делегатлары да биргән иде. Шул ук сорауны еш кына илебез халыклары арасында да ишетергә туры килә. Әлеге конгресста катнашкан буржуаз чит ил делегатлары белән сөйләшкәндә шул нәрсә мәгълүм булды: аларның кайберләре өчен бу мәсьәлә әле һаман «ачыкланмаган», ә кайберләре өчен, киресенчә, инде «күптән хәл ителгән». Соңгылары фикеренчә, татарларның килеп чыгуы Чыңгыз хан җитәкчелегендәге килмешәк татар-монголларга бәйләнгән. Ләкин тикшеренүләрен марксистик-ленинчыл методлар нигезендә алып бара торган совет фәне мондый «карашлар»ның чеп-чи хата булуын күптән фаш итте инде.

Хәзерге чор буржуаз чит илләр галимнәре генә түгел, Октябрь революциясенә кадәрге буржуаз рус һәм татар тарихчылары да бу мәсьәләне аңлы рәвештә бозып, имеш, Идел буе татарлары XIII—XIV гасырларда Идел ярларында «Бөек Татарстан»ны (Алтын Урда) төзегән татар-монголлар токымы алар дип аңлатып килделәр.

Ләкин археология, этнография, антропология һәм сәнгать өлкәләрендә алып барылган хәзерге заман тикшеренүләре буржуаз «тарихчылар»ның искеләренең дә, яңаларының да бу мәсьәләдә ялгыш, уйдырма фикер йөртүләкләрен кире кагып булмаслык дәлилләр белән тулысынча раслады. Ул «концепция»нең бернинди фәнни нигезе юк. Ул, бер яктан, рус самодержавиесенең татар халкына карата алып барган милли-колониаль изү политикасын аклау өчен уйлап чыгарылган нәрсә булса, икенче яктан, милләтчелек һәм панисламизм идеяләре белән саташкан, татарлар арасында русларга нәфрәт уятырга омтылган, яңа базарлар табу өчен алып барылган политик һәм идеологик көрәштә рус буржуазиясенә таянырга, Россиядәге барлык татарлар өстеннән хакимлек итәргә өметләнгән бер төркем татар буржуазиясе һәм интеллигенциясе тарафыннан алга сөрелгән «концепция» генә.

«Татар» исеме белән аталып йөртелә торган төрки телле халыклар күп милләтле илебез халыклары арасында сан ягыннан шактый зур урын алып тора[1]. Алар — Себер, Казан, Астрахань, Кырым, Касыйм татарлары һәм татар-мишәрләр. Революциягә кадәр, гәрчә этник чыгышлары ягыннан башка төр халык булсалар да, әзербайҗаннарны, чеченнарны һәм күп кенә башка халыкларны да «татар» дип атап йөрткәннәр.

Күрәсез, татарлар — территориаль яктан шактый киң таралган халык. Ләкин бу мәкаләдә без барлык татарлар турында да түгел, бәлки Урта Идел һәм Урал буйларында яшәүче Казан, Касыйм татарларының һәм татар-мишәрләрнең килеп чыгышы хакында гына сүз алып барачакбыз.

Сүзне Казан татарларыннан башлыйк. Ин элек шуны ачыклап китик: «казан татарлары» дигәннән сүз бары тик Казанда яшәүче татарлар турында гына бара икән дип уйларга кирәкми. Казан татарлары дигән төшенчәгә без чыгышлары ягыннан бер токымнан булган барлык татарларны да кертәбез.

Казан татарлары, нигездә, Татарстан АССРда яшиләр. Аларның аеруча куе урнашкан, башка халыклар белән кушылмаган районы — Казан арты, ягъни республикабызның төньягы[2]. Болгар дәүләте җимерелгәннән соң, XIII—XIV гасырларда монда болгар халыклары килеп урнашкан. Шулай итеп алардан яна болгарлар барлыкка килгән. Соңыннан аларны казан татарлары дип атый башлаганнар.

Татарстаннан тыш казан татарлары Советлар Союзының башка республикаларында һәм өлкәләрендә дә яши. Урта Идел буен рус дәүләтенә кушканга тикле казан татарлары, тулысынча үк булмаса да, географик чикләре якынча хәзерге республика территориясенә туры килә торган үз жирләреннән читкә таралмаганнар, бергә яшәгәннәр. Патша татарларга карата милли-колониаль изү, көчләп чукындыру политикасы алып бара башлагач исә, казан татарлары авыллары-авыллары белән үз илләреннән читкә китәргә мәҗбүр булганнар. Казан ханлыгын яулап алганнан соң башланган бу хәл XVIII гасыр урталарына кадәр дәвам итә. Менә шул сәбәпләр аркасында казан татарлары элекке патша Россиясенең төрле губерналарына таралып кала. Киров өлкәсендәге Нократ, Карин һәм Уржум, Малмыж (Киров өлкәсе) татарлары да, Удмуртиянең Глазов, Белизин районнарында яшәүче татарлар да — казан татарлары. Нократ, Глазов һәм Белизин районнарында XIV гасырга кадәр үк Чепец елгасы буенча килеп урнашкан болгарлар яшәгән (Карин князьлеге). Казан ханлыгы жимерелгәннән соң, казан татарлары да шулар янына килеп урнашкан. Башкортстанда яшәүче «типтәрләр» дип аталып йөргән татарлар да — казан татарлары. Алар анда Мәскәү князьлеге Урта Идел буен яулап алганнан соң XVI гасыр урталарында һәм XVII гасыр башларында килеп урнашканнар. Ләкин казан татарлары Башкортстанда Казан ханлыгы чорында да яшәгәннәр. Алар күп санлы хезмәтчеләр тоткан Казан феодаллары булганнар. Ул татарлар, ихтимал, Башкортстан жиренең көнбатыш өлешен биләп торган Идел буе болгарлары нәселедер. Башкортстанның Чишмә районындагы Чишмә авылы янындагы кабер ташлары һәм XIV гасырдагы болгар архитектура памятнигы булган Кәшәнә[3] тәкиясы (мавзолей) әнә шул турыда сөйли булса кирәк.

Казан татарлары Мари республикасының көнчыгыш өлешендә дә яшиләр. Алар да анда XVI гасырның икенче яртысы һәм XVII гасыр башларында барып урнашканнар.

XVIII гасырның икенче яртысында казан татарлары (нигездә, шәһәр халкы) Оренбург өлкәсенә дә күчеп китәләр.

Казан татарлары Чиләбе өлкәсенә, Казагыстанның төньяк районнарына да чәчелгән һәм алар себер татарлары, казакълар белән бергәләп яшиләр.

Болардан тыш казан татарлары Донбасста, Мәскәүдә һәм Ленинградта, Бакуда һәм Астраханьда да байтак.

---

[1] 1959 елгы халык саный алу мәгълүматларына караганда, Советлар Союзында яшәүче татарларның гомуми саны 5 миллион кеше. Шуларның 1,5 миллионлабы Татарстан территориясендә яши.

[2] Хәзерге Арча, Балтач районнары һәм Зеленодольск районының төньяк-көнчыгыш өлеше. Республиканың төньяк өлешендәге Иделнең уң яр буе да шуна керә.

[3] Аны Тура хан дип тә йөртәләр.

Казан татарларының килеп чыгышы әле безнең эраның беренче мең елында ук җирле фин-угр кабиләләре белән Азиядән килгән төрки телле тоҡымнар арасында барган катлаулы этногенетик процессларга бәйләнгән.

Хәзерге заман фәне алып барган күп яклы тикшеренүләрдән шул нәрсә ачыкланды: X гасырда Көнчыгыш Европада беренче дәүләтләрнең берсе булган Болгар дәүләтен төзегән болгарлар килгәнгә кадәр күптән үк инде казан татарларының борынгы бабалары Урта Идел буенда яшәгәннәр[1]. Болгар дәүләте төзелгәч тә, ул дәүләт халкының төп өлешен фин-угр кабиләләрен ассимиляцияләгән казан татарларының бабалары тәшкил итеп торган. Тора-бара болгарлар үзләре дә, казан татарларының борынгы бабалары тәэсиренә бирелеп, ассимиляцияләнгәннәр.

Ә казан татарларының борынгы бабалары кемнәр булган соң? Алар VI—VII гасырларда Идел һәм Урал буйларына басып кергән төрки телле кабиләләр белән Идел-нең сул ярында Болгар белән күрше һәм шулай ук төрки телле угыз-печенег кабиләләренең катлаулы кушылмасыннан гыйбарәт булган. Казан татарларының борынгы бабаларына, ихтимал, массагет-алан һәм һуннар аралашудан барлыкка килгән эфталит кабиләләре дә кушылгандыр. Ә X гасырда эфталитларның төп өлешен исә болгарлар белән политик бәйләнеш тоткан угыз-ябгу кабиләләре тәшкил иткән. Хәзерге төркмәннәр, әзербәйҗаннар һәм госманлы төрекләре һ. б. әнә шул угыз кабиләләре тоҡымнары инде.

Болгар халкы арасында угыз кабиләләре күбрәк булган. Моның шулай икәнлеген болгар теленең угыз-печенеглар теленә якын, тугандаш булуы раслап тора. Ә Болгар халкының культурасы исә (монгол чорына кадәр) Урта Азия халыклары культурасына якын булган. Ул культурада шулай ук Төньяк Кавказ халыклары культурасы элементлары да бар, һәм ул элементлар шул яктан килгән, сан ягыннан әллә ни күп булмасалар да, соңыннан дәүләткә исем биргән болгарлар культурасы элементлары булырга кирәк.

Казан татарлары культурасы белән угыз-печенег тоҡымы халыклары (әзербәйҗаннар, госманлы төрекләре һ. б.) культурасындагы якынлыклар казан татарлары орнаментларында һәм халык сәнгатенең башка төрләрендә шактый ачык чагыла. Менә шул фактлар әлеге халыкларның тугандаш икәнлекләрен һәм аларның ата-бабалары бер тамырдан барлыкка килгәнлекне раслый булса кирәк[2].

Болгар дәүләтенең күп кенә Көнчыгыш дәүләтләре белән тыгыз культура һәм экономик бәйләнеш тотуы аның халкы тормышына Көнчыгыш илләре культурасы элементлары керүгә дә юл ачкан. Болгар дәүләте чорында төрле төрки телле кабиләләр, шул исәптән Идел-нең үн як ярында яшәгән күчмә кыпчаклар да (половецлар, команнар), туктаусыз инфильтрацияләшеп торганнар. Алтын Урда чорында Болгар дәүләте составында кыпчакларның саны аеруча күбәеп китә. Әмма культура өлкәсендә алар болгар халкы арасында шактый тиз ассимиляцияләшәләр, икенче төрле итеп әйтсәк, болгар халкы культурасын үзләштерәләр.

Көнчыгыш Европа халыклары «татар» сүзен беренче мәртәбә монгол-татарлар басып кергәч кенә ишетәләр[3]. Соңыннан «татар» дигән атама монгол-татарлар тарафыннан буйсындырылган барлык төрки телле халыкларга, шул исәптән, Идел буеның, бигрәк тә аның үн як яр буеның, төп халкын тәшкил иткән кыпчакларга да тагыла. Бу турыда венгр монахы Юлиан 1236 елда менә болай дип язган: «Бөтен яулап алынган патшалыкларда да... буйсынган халыкларны татарлар дип атарга мәҗбүр итәләр».

Әмма «татар» дигән атама борынгы болгар халкына һәм аннан соңгы Казан ханлыгы халкына да озак вакытлар «ябыша» алмаган. Мәскәү князьлеге белән Казан ханлыгының политик мөнәсәбәтләре ничек булудан чыгып, рус елъязмаларында ханлык халкын я яна болгарлар дип, я казанлылар дип, яисә, кәефләре кырылган чакларда, татарлар дип язганнар. Бары тик XVII—XVIII гасырларда крайны Россиягә кушканнан соң гына «татар» дигән исемне акрынлап элекке Казан ханлыгы халкына

---

[1] В. Ф. Генинг, А. Х. Халиков. Ранние булгары на Волге. М., 1964, стр. 107.

[2] Ф. Х. Вәлиев. Казан татарлары орнаменты. Диссертация. В. И. Ленин исемендәге дәүләт китапханәсендә саклана (Мәскәү).

[3] Монгол гаскәрләренең бер өлешен тәшкил иткән татарлар үзләре дә монголлар тарафыннан яулап алынган халык булган.

да әйтә башлыйлар. Шунысы игътибарга лаеклы: Казан арты авылларында өлкән буын кешеләре әле һаман «татар» дигән исемне танымыйлар, үзләрен я болгарлар, яисә мөселманнар дип йөриләр [1]. Удмуртлар әле хәзер дә казан татарларын «бигер» (болгар дигән сүз) дип атыйлар.

Инде Урта Идел буе татарларының икенче группасын — татар-мишәрләрне карап үтик. Крайны Россиягә кушканга кадәр, алар компактлы рәвештә Ока елгасы кушылмалары бассейнында Темников, Кадом, Шацк һәм Норовчат шәһәрләре тирәсендә яшәгәннәр. Хәзерге шартларда алар Горький (Арзамас, Сергач, Курмыш, Рязань (Әҗи авылы), Пенза (төньяк һәм көньяк-көнчыгыш өлеше), Тамбов (Алчас һ. б.), Ульяновск (төньяк һәм көньяк өлешләрендә), Куйбышев (Камышлы районы һ. б.), Саратов, Оренбург, Чиләбе (Шадринск районы) өлкәләрендә һәм Мордва, Чувашия, Татарстан (республиканың ун як яр буе һәм Кама аръягының көнбатыш өлешләре) һәм Башкортстан АССРларда яшиләр. Татар-мишәрләр Идел буе шәһәрләрендә (Куйбышевта һәм бигрәк тә Казанда, Астраханьда), Мәскәүдә һәм Ленинградта да күп яшиләр.

Мишәрләрнең әнә шулай чәчелеп яшәүләре алар культурасына башка халыклар культуралары шактый зур йогынты ясауга китергән.

Казан татарларының үз жирләреннән башка жирләргә сибелүе рус самодержавиесенең түзеп булмаслык каты милли-колониаль политика алып баруы аркасында килеп чыккан булса, мишәрләрнең таралуы башка сәбәп белән бәйле. Мишәрләр патша Россиясенең оборона-стратегик политикасы нәтиҗәсендә төрле урыннарга таралырга мәҗбүр булганнар.

Урта Идел буен Россиягә кушканга кадәр үк әле мишәрләр рус жирләре чигендә яшәгәннәр һәм Алтын Урда чикләрен саклаганнар. Ә Алтын Урда Тимер тарафыннан туздырылганнан соң, мишәр феодаллары, үзләренең жир биләмәләрен саклап калу ниятеннән чыгып, Мәскәү патшасына хезмәткә күчәләр. Мәскәү ханы чыннан да аларның биләмәләренә тими һәм, шуның өстенә, тагын байтак кына өстенлекләр дә бирә.

Мишәрләр белән берәттән, Алтын Урда феодалларының да күбесе үзләренең хезмәтчеләрен ияртеп Мәскәү дәүләте ягына чыгалар. Аннары мишәрләр дә, Алтын Урда феодаллары да, рус подданныйлары булып, рус дәүләте чикләрен саклый башлыйлар.

Урта Идел һәм Урал буйларын дала халыклары һөҗүменнән саклау өчен, рус дәүләте XVII—XVIII гасырларда чик буйларына сакчылар куя, оборона ныгытмалары төзетә. Бу эшне дә, нигездә, мишәрләргә йөкли. Һәм аларга жир һәм башка төрле льготалар бирә. Шулай итеп, бу хәл мишәрләрнең Урта Идел һәм Урал буйларына таралуына сәбәпче була.

Мишәрләрнең кайдан һәм ничек килеп чыгышы шактый катлаулы һәм әлегә тикле ахырынача хәл ителеп бетмәгән мәсьәлә булып тора. Кайбер археологларның әйтүенчә, мишәрләрнең бабалары нинди дәрәҗәдә VI—VII гасырларда Идел һәм Урал буйларында яшәгән борынгы төрки телле кабиләләр белән бәйләнгән булырга мөмкин [2]. Әмма Хазар каганаты (VII гасыр), Болгар дәүләте (X гасыр), аннары Дешт — Кыпчак (XI гасыр) һәм Алтын Урда (XIII гасыр) чорында төрки телле халыклар этник яктан шундый нык катышып-кушылып беткәннәр ки, аннан мишәрләрнең этник кигезен табып алу бик-бик кыен хәл. Мишәрләрнең кайдан һәм ничек килеп чыгышы хакында фәнни әдәбиятта да мәгълүматлар бөтенләй диярлек булмавын искә алсак, бу мәсьәләне хәл итүнең нинди читен эш икәнлегенә төшенү өчен сүз озайтып торуның хаҗәте дә калмый.

Ихтимал, этник яктан мишәрләр, нигездә, кыпчаклардан, аннары Алтын Урта халкыннан торган катлаулы төрки телле халыклар синтезыдыр.

XI гасырда үк Идел буйларына килеп урнашкан кыпчаклар теле соңыннан татар-монголлар арасында да киң тарала һәм соңыннан Алтын Урданың дәүләт теленә әверелеп китә. Улус Дәндчи язмасы шулай үк кыпчак телендә алып барыла. Алтын Урда составына кушылганнан соң, болгар халкы да шул үк телдә сөйләшергә тиеш була. Казан ханлыгы халкы да соңыннан шул телдә сөйләшә башлый.

---

[1] Н. И. Воробьев. Казанские татары. Казань, 1953, стр. 19. Н. Спасский. Очерки по Родиноведению. Казань, 1912, стр. 36, 61.

[2] А. Х. Халиков. О происхождении Казанских татар. Газета «Советская Татария», 3 июль, 1966 ел.

Борынгы төрекләрнең кыпчаклар һәм фин-угр кабиләләре белән катлаулы кушылмасыннан, ихтимал, мишәрләр барлыкка килгәндер. Ә «мишәр» дигән исем «мещер» дигән сүздән барлыкка килгән булса кирәк. «Мещер» мордваларга тугандаш борынгы бер кабилә исеме. Элек шул кабилә яшәгән җирләргә килеп урнашканлыктан, аларны «мишәрләр» дип атый башлаганнардыр, күрәсең[1].

Алтын Урта хакимлек иткән гасырларда Идел һәм Урал буйларында яшәгән төрки телле халыклар арасында кыпчак теле бик киң тарала. Моңа кыпчакларның крайдагы төрки телле аборигеннар (болгарлар, башкортлар һ. б.) белән этник кушылуы да сәбәп була.

Шулай итеп Идел буенда ике төрле телле группа — казан татарлары һәм татар-мишәрләр барлыкка килә.

Культуралары, сәнгатьләре һәм орнаментлары ягыннан казан татарлары чыгышлары буенча угыз-печенег токымы булган халыкларга — әзербәйҗаннарга, госманлы төрекләренә һ. б. якын торалар. Ә мишәрләр культурасы һәм сәнгате исә чыгышлары ягыннан кыпчак токымы белән якын торган башкорт, кыргыз һәм, өлешчә, казакъларга тартым. Әмма шул ук вакытта мишәрләр культурасына соңыннанрак казан татарлары һәм рус культуралары элементлары да килеп керә.

Казан татарлары һәм мишәрләр культурасының үзара якынлашуы капитализм чорында башлана һәм Совет власте елларында аеруча көчәеп китә. Әмма, шулай булуга да карамастан, алар культурасында кайбер аермалыклар хәзер дә саклана әле.

Башкортстанда яшәүче типтәрләр һәм мишәрләр Урал буе татарларының үзенчәлекле бер группасын тәшкил итә. Элек яшәгән урыннарыннан инде күптән киткән ул халыкларның, җирле халык культурасы белән борынгы традицион культуралары аралашу нәтиҗәсендә, хәзер үз культуралары туган.

Урта Идел татарларының өченче, чагыштырмача кечкенә группасы — касыйм татарлары. Алар хәзерге Рязань өлкәсенең Касыйм районында (Касыйм шәһәре) яшиләр. Касыйм татарларының элек зур булмаган Касыйм князьлеге булган. Вассал рәвешендә Мәскәү карамагында торган ул князьлек XV гасырга тикле яшәгән һәм Казанга каршы көрәштә Мәскәүнең форпосты булып хезмәт иткән[2].

Касыйм князьлегенең барлыкка килүе Алтын Урда патшасы улы Касыйм исеме белән бәйләнгән. Касыйм үзенең дружинасы белән XV гасырда Мәскәү дәүләтенә хезмәткә күчкән. Шуның өчен Мәскәү патшасы аңа мещер җирләрен биләргә рөхсәт иткән. Касыйм татарлары группасы этник яктан Алтын Урда татарлары белән мишәрләр һәм соңыннан Казан ханлыгыннан Касыймга күчеп килгән казан татарлары үзара кушылудан барлыкка килгән.

Идел һәм Урал буе татарларының барлыкка килүен, аларның төрле урыннарга таралуын һәм тарихи-культура аермалыкларын күрсәткән картина кыскача менә шундый.

Йомгак итеп шуны әйтәсе килә: бу мәкаләдә сөйләнгәннәрдән чыгып, татар халкының ничек һәм кайдан килеп чыгуы инде тәмам ачыкланып беткән икән дигән нәтиҗә ясарга кирәкми. Бу мәсьәләдә ачыкланасы моментлар байтак әле һәм галимнәр аны тагын да ныграк тикшерерләр, халкыбыз тарихы пәрдәләрен киләчәктә киңрәк итеп ачарлар дип уйлыйбыз.

---

[1] Шунысы характерлы: казан татарларыннан аермалы буларак, мишәр картлары үзләрен чын татарлар дип исәплиләр. Әмма алар татар дигәндә һич тә монгол-татарларын күздә тотмыйлар. Алар «мишәр» дигән исемне кире кагалар. Бу турыда «Очерки по Родиноведению» (Казань, 1912, стр. 59) исемле хезмәтендә Н. Спасский да әйтеп китә. «Мишәр» дигән исем аларның бабалары кайчандыр кысрыклап чыгарган мещер кабиләләре белән ассоциацияләнгәнгә, бу исемне кабул итә алмый булса кирәк мишәр картлары.

[2] Мишәр морзалары белән бергәләп, Касыйм князьләре Казан ханлыгын яулап алуда Иван IV ничегә актив ярдәм күрсәткәннәр.

Леон Небенцаль,

Германия Демократик Республикасы.

ШАГЫЙРЬ-КӨРӘШЧЕ

Кадерле иптәшләр һәм дуслар![1]

Бу трибунадан Муса Җәлилнең совет культурасы, һәм бигрәк тә татар культурасы үсеше өчен күрсәткән хезмәтләре хакында күп сөйләнелде. Борынгыдан бай тарихы булган татар культурасының Бөек Октябрь революциясеннән соң, совет халыкларының бердәм семьясы эчендә гөрләп чәчәк атуы шартларында эшләгән һәм культура фронтының төрле өлкәләрендә — шигъриятта, журналистикада, драматургиядә—гаҗәп зур казанышларга ирешә алган бу шагыйрьнең талантын, партиялелеген, күпкырлы эшчәнлеген, гадәттән тыш зур иҗади энергиясен без дә югары бәялибез һәм хөрмәт итәбез.

Ләкин Муса Җәлилне без барыннан да бигрәк комсомол һәм Ленин партиясе тарафыннан пролетар интернационализм рухында тәрбияләнгән, хәтта үлем камерасында да ачык фикерле булып кала алган көрәшче буларак беләбез. Ул немец халкын ярата һәм ихтирам итә, аны немец милитаризмыннан һәм фашизмыннан, реакциянең үзенең бөтен ялкынлы йөрәге белән күрәалмаган явыз көчләреннән бик төгәл аера белә. Муса Җәлилне без барыннан да бигрәк үзендә әнә шундый сыйфатларны туплаган көрәшче буларак ихтирам итәбез.

Муса Җәлил немец халкының бөек фикер ияләре Марксны һәм Энгельсны белгән, аның бөек композиторларын һәм шагыйрьләрен белгән. Белгән һәм ихтирам иткән. Моабит дәфтәрендәге соңгы шигырьләренең берсендә, «Алман илендә» исемлесендә, «Хәр йөрәкле Гейне гашыйгы... Гете белән шашкан» кеше, дип яза Муса үзе хакында. Шулай туры килгән ки — бу хәзер билгеле инде — Шпандау хәрби төрмәсенең 53 нче камерасында утырган чакта Муса укыган китапларның иң соңгысы Гетенең бөек әсәре «Фауст» була. Муса аны немец телендә укыган.

Немец эшчеләренең сыйнфый көрәшен Муса зур теләктәшлек һәм кайгыртучанлык белән күзәтеп торган. Моны без аның 1924 елда язылган «Фрагментлар» поэмасында ук күрәбез. Шул ук вакытта ул немец эшчеләренең дошманнарын да күреп тора, үзенең 1935 елда язылган «Джим» поэмасы белән ул аларны фашитә һәм хурлык тамгасы белән билгеләп үтә. Ә шушы дошманнар аның туган иле Совет җиренә басып кергәч, ул, һич икеләнеп тормастан, аларга каршы көрәшкә чыкты. Көрәш өчен ул барлык төр чараларны, ә барыннан да бигрәк үзенең ялкынлы шигырьләрен соңгы сулышынача корал итеп файдаланды.

Кызганычка каршы, бу көрәштә Муса Җәлил алдында торган әлеге явыз көчләрне без әле бүген дә инде булган да беткән, тарих чүплегендә ташлап кына калдырылган бернәрсә итеп хисаплый алмыйбыз. Алар милитаристик һәм реваншистик Бонн республикасында аерым бер дәүләт булып оештылар һәм яңадан халыкларның тынычлыгын бозарга маташалар. Хәзерге заман коралының нинди зур җимерү көченә ия булуын истә тотып әйткәндә, бу — алар бик күп халыкларның һәм иң беренче чиратта үз илләрендә яшәүче халыкның җир йөзендә калуын калмау мәсьәләсен шик астына куялар дигән сүз.

Гыйбрәтле бер мисал белән бу дәүләтнең агрессив хасиятен күрсәтеп бирергә рөхсәт итегез. Кайзер һәм Гитлер «рейхы»ның «Германия, Германия барыннан да өстенрәк» дигән кушымталы тәкәббер гимны күпләргә билгеле һәм ул барлык халыкларның нәфрәтенә дучар булган иде инде. Җырда шовинизм символы булып әверелгән бу гимн шул чаклы мәсхәрәгә калды ки, 1949 елда сепаратив Көнбатыш Германия дәүләте оешкач, аның кайбер җитәкче даирәләре бөтенләй яңа гимн язу һәм гамәлгә кертү турында уйлана башладылар. Бәхәс ике якның килешүе белән тәмамланды: иске гимннның дошманнары да, яклаучылары да аның өченче строфасын — «бердәмлек, хокук һәм азатлык» турында әйтелгән өлешен сайлап алырга дип килештеләр. Чөнки андагы фикер, бераз гомумирәк формада әйтелгән булса да, Бонн хөкүмәте башында утыручыларның фикере белән туры килә.

Илебезнең көнбатыш ягында оялап калган бу явыз көчләр акрынлап икенче сугышта алган яраларыннан арына барган саен яңадан

---

[1] Бу — Л. Небенцальнең Мәскәүнең Чайковский залында Муса Җәлилнең 60 еллыгына багышлап үздырылган тантаналы җыелышта сөйләгән речь.

кеч тупларга керештеләр. Бонн дәүләте экономик яктан буенча империалистик державалар арасында икенче урынга чыкты, яңадан үзенең сугыш машинасын булдырды, үз территориясен киңәйтүне дәгъвалый башлады. Һәм менә бу кадәресе әле сезнең күбегезгә билгеле дә түгелдер, дип уйлыйм — үткән ел, сугыш тамамлануга 20 ел узгач, Көнбатыш Германия Федератив Республикасы хөкүмәте элекке гимн кушымтасындагы әлеге сүзләрнең дә үз гимнына кертелүен рәсми төстә игълан итте.

Ә сез ул кушымтаның тулы текстын, эчтәлеген беләсезме? Бөтен бер басып алулар программасын, бөтен бер реванш, икенче бөтендөнья сугышы нәтиҗәләрен яңадан карау программасын үз эчена алуын беләсезме Сез аның? «Германия, Германия барыннан да өстенрәк бу дөньяда, ул Маастан Мемельгача, Эчтан алып Бельткача...» дип җырлана анда. Әйдәгез, тикшереп карыйк... Маасның Франция, Бельгия һәм Голландия җирләре аша ага торган зур елга икәнлеге һәркемгә билгеле. Бельт сулары ерак төньякта Дания ярларын юа. Эч Италиянең төньяк өлешеннән ага һәм, 900 километрдан артыгракка сузылган туры сызык булып, Германия Федератив Республикасы һәм Мемель (немецлар Неманның түбәнге агымындагы җирләрне шулай атыйлар) тирәләрендә Литва ССР чикләре арасыннан үтә. Әмма эш монда 900 километрда гына да түгел: шул ук территориягә тагын социалистик дәүләтләрнең Польша Халык Республикасы белән Германия Демократик Республикасы да кераләр бит...

Кыскасы, Бонндагы сугыш чукмарларының чит дәүләтләр җирләрен басып алуны күздә тотып төзелгән яңа программалары Европадагы бер төркем илләрнең курыкынычсызлыгына турыдантуры яный һәм ул үз эчена Көнбатыш Германия территориясенә караганда күп тапкырлар зуррак өлкәләрне ала.

«Бу программа, — дип яза безнең танылган публицистыбыз һәм тарихчыбыз, профессор Альберт Норден, — әлеге гимнны башкару төсендә Германия Федератив Республикасының мәктәпләренда, солдат казармаларында, офицерлар казиноларында, фашистик ертыкыч берләштерү элекке рәсеме төшерелгән флагны мачтага күтәргән чакта, барлык рәсми тантаналарда игълан ителә. Бу дәүләт өчен бик тә яхшы программа ул, чөнки ул андагы хөкүмәтнең рәсми программасы белән бик төгәл тәңгәл килә һәм, бөтен эш Германия Федератив Республикасының җитәкчеләреннән генә торса, ул әле бер җыр булып кына да калмас иде».

Әмма, бәхеткә каршы, бөтенесе дә алардан гына тормый шул... Германия территориясендә бөек Советлар Союзы һәм башка социалистик илләр белән тыгыз бәйләнгән икенче бер дәүләт тә бар.

Бу — Моабит камерасында яткан көе үзләрена Муса Җәлил мөрәҗәгать иткән эшчеләр сыйныфы партиясе, Тельман дуслары һәм Цеткин оныклары партиясе җитәкчелегендәге эшчеләр һәм крестьяннар дәүләте. Бу дәүләтнең дә антифашист Эйслер тарафыннан антифашист бехер сүзләренә язылган үз гимны бар. Ул немец халкын һәрвакыт кояш нурларында коеныл балкучы, бәхетле, тынычлык сөючән, демократик Германия төзергә өнди: «...һәм Германия өстендә гүзәл кояш балкып күтәрелде».

«Алман илендә» шигыренең түбәндәге юллары Сезнең барыгызга да билгеле, әлбәттә:

Борыгыз мусенын комсыз карчыганың,
Кояш чыксын Алман җиренә.
Күтәрелсен Тельман трибунага,
Маркс, Гейне кайтсын илена.

Казанга килгәч, Республика музеендагы шушы юлларны укыгач, аларның безнең гимн белән аваздаш яңгырауларына таң калдым мин. Гарчә Бехер аны 1950 елда язган булса да, ә Җәлил шигыре беренче тапкыр 1953 елда гына басылып чыкса да, алар арасында бик тирән рухи бәйләнеш бар.

Германия Демократик Республикасында Җәлилнең теләкләре тулысынча тормышка аштылар, андагы трибуналардан хәзер Тельман шәкертләре сөйли, ә Маркс белән Гейне яңадан үз ватаннарына әйләнеп кайттылар һәм фәкать шуның аркасында гына Бехер кояш нурларында коеныл балкучы Германия турында гимнын яза алды.

Моңа ирешүдә татар халкының бөек улы Муса Җәлил дә үз көрәше белән зур булышлык күрсәтте. Әна шуңа күрә немец халкының барлык прогрессив көчләре аны хөрмәт итәләр, аңа чын күңелдән үзләренең рәхмәтләрен белдерәләр.

Җәлил Камалетдин,
гарәп язучысы, Совет-Ирак дуслыгы җәмгыяте Башкарма комитеты әгъзасы[1]

ЖӘЛИЛ ТУРЫНДА СҮЗ...

I

Муса Җәлил юбилеенда татар язучылары мине «гарәп җәлилчесе» дип атадылар. Миңа карата әйтелгән әлеге җылы сүзләрне, юбилей көннәренда булган ителгән кечкенә генә значокны гомер юлымдагы ин яхты хатираләрдән саныйм.

Башта ук шундый сорау туа: гарәп язучылары ни өчен Җәлилне шул кадәр зурлыйлар һәм яраталар? Ни турында сөйли бу?

Мондый сорау урынлы да, урынсыз да кебек. Ни өчен бүтән бер язучы түгел, а нәкъ Муса Җәлил шулай популяр? Бу ноктадан караганда, сорау, чыннан да, урынлы. Ләкин күп кеше бернәрсәне исәпкә алып бетерми: гарәпларга Татарстан чит-ят җир түгел. Татар халкының даны һәм батырлыгы белән без дә горурланабыз: Татарстанның даны күпмедер күләмдә безнең дә даныбыз ул. Моның белән минем кебек халыкчы бер культура традицияләре һәм, әйтергә кирәк, машһур культура традицияләре бәйли дигәсем килә. Бу гомум культура безне үзара янынлаштырып кына калмый, шул ук вакытта нык һәм тыгыз рәвештә, тагын да төгәлрәк әйткәндә, орга-

[1] Ж. Камалетдин бу мәкаләсен журнал өчен махсус язды. Мәкалә бераз кыскартылып бирелә. Редакция.

ник рәвештә бер дөнья, бер цивилизация кешеләре итеп тә берләштерә. Багдад һәм Казан, үткән гасырларның бу ике мөһим культура үзәге, дусларча аралашып, бәйләнеш тотып яшәгәннәр.

Билгеле, мин борынгы культураның җитешсезлекләрен акларга теләмим, бары Казан һәм Багдадны берләштергән культура традицияләренең нигезләрен күрсәтеп китәсем генә килә. Без бер үк дөньяга керәбез. Бу — үзенчәлекле Шәрекъ дөньясы. Җәлилнең Хәйям, Сәгъди, Хафиз кебек шәрекъ шагыйрьләрен өйрәнүе очраклы хәл түгел. Соңга таба ул көнчыгыш поэзиясенә хас кайбер кимчелекләрдән арынды, билгеле. Ләкин бу поэзиянең күп кенә көчен, уңай сыйфатларын аның иҗатында ныклы урын алды. Талантының җитлеккән чагында ул борынгы шәрекъ әдәбиятының артык абстрактлыгыннан баш тартканы. Ләкин борынгы әдипләр иҗатын абстрактлылык һәм мистика белән генә бәяләү дөрес булмас иде. Әл-Мутанәбби, Әл-Марри, Хәйям, Сәгъди, Хафиз, Җәләлетдин Руми һәм башка гарәп, фарсы, төрек шагыйрьләре поэзиясендә кеше һәм табигать матурлыгына, саф мәхәббәт хисләренә дан җырлау, үз идеалларыңа турылыклы булу, чын гуманизм кебек күркәм сыйфатлар өстенлек алуын да онытырга ярамый. Муса Җәлил иҗатында да шул үк нәрсәләр яктыга чагылыш табалар. Реализм, романтизм элементларын бергә үреп килгән бу шагыйрьләр кеше боеклеген, аның рухын, югары кешелек сыйфатларын җырлаган үлемсез әсәрләр бирделәр.

Җәлил борынгы шигърияттән һәм мәдәнияттән баш тартмады гына түгел, аларны үстерде дә. Борынгы әдипләр туплаган бай тәҗрибәне һәм үз чоры казанышларын үзләштереп, ялкынлы поэзиясе белән бөтен дөньяга, бөтен халыкларга мөрәҗәгать итте. Аның шигырьләренда үз заманы, үз чынбарлыгы яңгырый. Бернәрсәгә шикләнмәскә мөмкин: Җәлил үзенә кадәр булган татар шигърияте традицияләрен (Дәрдмәндне, Тукайны) һәм Шәрекъ әдәбиятын тирән белгән һәм шуларга таянып, ул үз заманын, үз чынбарлыгын шәп итеп җырлый алган.

Җәлилгә охшаш шагыйрьләр хәзерге заман Ирак әдәбиятында да бар. Әл-Баяти Габделваһап, Сәгъди Йосыф, Мөхәммәт Салих һәм бөек Ирак шагыйре, Ирак язучылар союзы председателе Мөхәммәт Мәһди әл-Җаваһири шундыйларга керәләр. Бу мәшһүр гарәп шагыйрьләренең барысы да, үз халыкларының халык һәм кешелек язмышы белән бәйләп, үз иҗат юлларын Җәлил кебек салдылар.

Һәрберсенең үз стиле, үзенчәлекле индивидуаль йөзе булган бу язучыларны тормышка бер төсле нәраш, бер төсле мөнәсәбәт берләштерә. Әйтәсе килгән сүз шул: Җәлилнең олы җаны, аның алга омтылышы, халыкча тугрылыгы безгә чит түгел. Кызганычка каршы, моңа кадәр безнең шагыйрьләр Җәлилне белми, аның шигырьләрен укымаган иделәр. Ләкин аларның күбесе, үзләренең идеаллары белән Җәлил ягында...

Әгәр мин Җәлил турында мәкаләләр язганмын, аңа багышланган китап өстендә эшлим икән, бу — аның иҗаты безнең үткәндәге культурабызга, хәзерге гарәп шигъриятенә якын булган өчен генә түгел әле. Ул конкрет вакыйгалар, индивидуаль образлар аша кешелек җәмгыятенең барлык алдынгы вәкилләре өчен уртак үй-хисләрне, уртак омтылышларны чагылдырды. Тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә, ул конкрет фактлар аша бөтен кешелек җәмгыяте өчен гомуми булган нәрсәләрне сурәтли алды... Бельгияле дусты Андрега багышланган шигырендә Җәлил болай ди:

Кайтса иде гөлләр арасында
Гөрләп үскән көләч көннәрем,
Дускай, сиңа бүләк итәр идем
Илкәемнең иркә гөлләрен.

Биредә «илкәемнең иркә гөлләре» Ватан символы, бөек Советлар Союзы төсе булып кына калмый, ә шагыйрь язмышы белән Ватан язмышы аерылгысыз булу турында да сөйли... Шигырьдә Җәлил үз тойгыларын гына түгел, ә бөтен кешелек өчен хас гомум хисләрне җырлый.

II

1941 елның 12 январенда тормыш иптәше әминәгә җибәргән хатында Муса болай яза:

«Аерылышкан чакта йөрәгемне тутырган сагыш-кичерешләрнең ниндидер башка сәбәпләрен күрмәганлегемнән, хәтта куркып: «Бу сине дә, сөекле Чулпанымны да яңадан һичкайчан күрә алмавымны алдан сизенеп ямансылавым түгелме соң?» дип шикләнә дә башладым».

Сорау туа: бу соң йомшаклык түгелме? Герой шагыйрь, көрәшче шагыйрь, фронтовик шагыйрьнең шул рәвешле йомшап китүен ничек һәм нәрсә белән аклырга була?

Бу сорауга без җавап бирмибез. Чөнки аңа Җәлил үзе җавап бирә. Хатын ул болай дәвам итә:

«Минем җаным барлык кыенлыкларга, барлык газапларга һәм җәзаларга түзә алачак, әмма 8 январьда кич белән Чулпанны соңгы тапкыр күрдем дигән уй белән һичничек тә килешә алмыйм. Күңелем бөтен көче белән моңа каршы күтәрелә... Чулпанымны мин шулкадәр көчле яратам, бу ярату барлык үлемнәрдән көчлерәк...»

Бу ярату барлык үлемнәрдән көчлерәк! Җәлилнең бу сүзләре шәхси бәхет турында сөйләүче ван хакыйкать кенә түгел. Бу — олы хакыйкать. Җәлил барлык кешеләрне шуңа чакыра.

Нишлисең бит, бөек хаклык юлы
Шундый тайгак булгач?
Көрәшчегә бары җиңү яки
Үлем генә юлдаш.
Тиздән сүнәр, сүнгән йолдыз кебек,
Соңгы яшәү көчем.
Үләм, ләкин бөек хаклык өчен,
Илем, халкым өчен.

(«Үлемгә».)

Җәлил Чулпанына һәм Ватанга булган мәхәббәтен әнә шулай аңлата. Монда күп нәрсә әйтелгән. Бу юллар Җәлилне ачык характерлый һәм безгә аны кеше буларак та, шагыйрь буларак та аңлау өчен ачкыч бирә.

Юк, Җәлил йомшаклык күрсәтми. Нинди генә авырлыклар килгәндә дә, ул Кеше булып, Кеше булып кына түгел, Шагыйрь дә булып кала. Аның Чулпанны сөюе — барлык сабыйларны сөюе. Димәк, киләчәкне сөюе. Җәлил хәзерге, бүгенге көн белән генә чикләнеп калмый, ул кешелекнең киләчәк бәхетен яклап калучы. Яклап калучы гына да түгел, ул үзе дә шул киләчәкнең бер агъзасы. Чулпан — аның өчен Туган ил дә, киләчәк тә, йөрәгенең бер кисәге дә. Шушы зур мәхәббәткә шагыйрь үзенең гомерен бағышлады, тормышын бирде...

Югарыда телгә алынган хатның соңгы юлларын тагын бер тапкыр кабатлыйсы килә:

«...Ләкин моның өчен (сентименталь хисләргә бирелгән өчен — Ж. К.) мин үземне гаепләмим. Хисләргә бай йөрәк кенә зур эшләргә сәләтле була. Менә (тиздән) сугышка керәм, күрерсең, бу хыялый, сентименталь җан нәрсәгә сәләтле икәнен күрсәтер әле.

Я, хуш, сөеклем!.. Җиңүгә кадәр!»

Җәлилнең бу сыйфаты тере кешеләргә ят нәрсә түгел. Киресенчә, ул бик характерлы. Бу күбрәк татар халкы өчен, барлык көнчыгыш халыклары, шул исәптән гарәп халыклары өчен уртак хис.

Һәрчак чын, бөек шагыйрьләр гомум, зур бәхет өчен үз шәхси бәхетләреннән баш тарталар. Һәм алар хаклылар. Шагыйрь — тормыш авазы, халык авазы, хаклык авазы бит ул. Тормыш, халык һәм хаклык дигән бу өч төшенчә бер-берсе белән органик рәвештә бәйләнгәннәр. Җәлилнең эстетик идеаллары, алар нинди форма-

дә гына гәүдәләнмәсеннәр, бер нәрсә тәкъдирлыйлар. Ул шагыйрь-кеше һәм кеше-шагыйрь. Моның белән минем аның кешелеге шагыйрьлегенә, шагыйрьлеге кешелегенә каршы килми диясем килә...

Җәлил җанының байлыгы аның шигъриятенең байлыгында, аның батырлыгының байлыгында. Аның тойгылары акылыннан өстенлек итми, ә органик рәвештә акыл белән бербөтенне тәшкил итә. Аның акылы тойгылар белән никадәр баетылган булса, шулкадәр үк бөек тә. Аның барлык шигырьләрендә көчле тойгы гына түгел, акыл авазы да яңгырый...

Җәлилнең үлемгә кадәр булган бөтен тормыш һәм иҗат юлы югарыда китерелгән хатындагы сүзләрен раслый. Аның җаны зур эшләргә сәләтле булуын, барыннан да элек, Җәлилнең бөек шагыйрь-кеше икәнен күрсәтте. Аның җаны да, сүзләре дә үз иҗатында өч төшенчәнең — Кеше, Тормыш, Халык төшенчәләренең — берләшүен күрсәтә.

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.

(«Катыйльга».)

Җәлил, Ватан намусын, үз туганнарының, семьясының намусын яклап, үлемгә барды. Бу гаҗәп түгел дә. Моңа ул яшьтән үк әзерләнгән иде. 14 яшьлек нечкена Җәлил «Бәхет» исемле шигыренда болай язды:

Кулымда мин «кызыл кылыч»ны алсам,
Шулай шуннан «кызыл фронт»ка барсам,
Олуг бер дәрт белән сафка атылсам,
Кулымны уртага, дошманга салсам,
Бөтен куәт белән шунда сугышсам,
Җиңәлми мин һаман да алга барсам;
Мина шунда бирәр пуля очса-килсә,
Килеп ул күкрәгемне бишкә киссә,
Үлем кулы килеп басса — егылсам,
Җаным күккә-гарешкә очса-китсә —
Мина шунда бәхетле мин, бәхет — шул.
Минем өчен зур олуг шан, зур бәхет ул.

Һәм Җәлил бөтен гомере буе шушы данны, шушы бәхетне җырлады. Ватан намусы өчен, туганнарының намусы өчен үлемне ул тормыш дип, тормышка яңадан кайту дип санады. Сүз уңаенда әйтеп китәргә кирәк, гарәпнең классик шагыйре Әл-Мутанабби болай ди:

Саклап калып булмый чын намусны,
Аның өчен каның коймасаң.

III

Җәлил — татар халкының тавышы иде. Җәлил поэзиясенең новаторлыгы әдәби традицияләргә, үткәндәге мирасқа каршы түгел иде. Тукай һәм Җәлил арасындагы күпер тере һәм бай иде. Шагыйрьнең халык иҗаты белән кызыксынуы аның иҗатының реалистик юлдан гына түгел, бөтен стиль үзенчәлекләре һәм индивидуальлеге белән, реализмның таза һәм бай эчтәлекле юнәлеше — социалистик реализм юлыннан баруын күрсәтә.

Татарның бөек шагыйре Тукай үзе халыкка омтылды, барлык шагыйрьләрне халык тавышына колак салырга чакырды. Бу аның иҗатының тарлыгын яки йомыклыгын түгел, ә аның рухи тазалыгын күрсәтте.

Муса Җәлилне яки Хәсән Туфанны, шулай ук башка татар совет шагыйрьләрен укыганда, татар шигъриятенең остазы Тукайның тере сулышы тоясың.

Татарстанның данлы улларын — аның шагыйрьләрен халыкны шулай сөярга Тукай өйрәтте. Җәлилнең «Батырлык турында» исемле шигыреннән түбәндәге сүзләре:

Ил онытмас, бирсәң каныңны
Ватан өчен изге көрәшкә.
Хаин каны тамса чиләкка,
Батыр каны тама йөрәккә. —

Тукай тавышын искә төшерәләр.

Үлмәсен, үлсәм дә, намы, гәҗиҗем фәүт итмәсен.
Катмәсен бушка бәнем җәһдем вә мәшгульлиятем.
Бер заман ят әйләсә бильстифат миллат бәни, —
Иштә, будыр максатым, мәэмүл вә мәсгудиятем[1].

Егет юлы — Тукай өчен дә, Җәлил өчен дә бер ул. Җәлилнең Моабит шигырьләрендә Тукай «Пар ат»ының моңы сизелә. Казанга, данлы Казанга омтылу — бу улның анасыз, канның тәнсез яши алмавы төсле. Туган җирдән аерылу, аңардан читтә булу Тукайда һәм Җәлилдә, шулай ук тагын кайбер татар язучыларында һәм шагыйрьләрендә ирек яулау авазы, Ватанны яклау, аның даны һәм иреге өчен көтәрелү, кеше азатлыгы өчен көрәш авазы булып үсә.

1907 елда бөек Тукай болай дип яза:

И Казан, дәртле Казан! Моңлы Казан!
Нурлы Казан!

Ә Казаннан аерылган Җәлил:

Җиңү безгә туры юл күрсәтер,
Томан тетелер ал таң нурыннан.
Туган йортны, дускай, без табарбыз
Сөйгәнемнең сагыну җырыннан, —

ди. Без Җәлилне Тукай белән бөтенләй тигезләргә, аның иҗади үзенчәлекләрен күзгә йомарга теләмибез. Бу мисаллар белән без Җәлил юлы — татар халкы юлы, аның шагыйрь-егетләренең юлы икәнен күрсәтергә телибез. Җәлил бу юлда үзе генә түгел. Үз вакытында Тукай кебек, Җәлил күпләрнең укытучысына әйләнде. Бу бөек шагыйрь артыннан Советлар Союзы даны өчен, Татарстан һәм бер үк вакытта Шәрекъ даны өчен бүгенге һәм киләчәк җәлилчеләр бараллар.

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. 4 томда. 2 том, 50 бит.

Яңа сәхифәләр ачылганда

XVIII йөздә ил гаять зур вакыйгалар кичергән. Ул вакыйгаларда татар халкы да актив катнашкан. Бу турыда яңадан-яңа документлар табыла. Мәсәлән, Мәскәүдәге борынгы актлар үзәк дәүләт архивы (БАҮДА) фондларында аеруча зур байлык саклана. Монда татар халкының социаль-экономик хәле, көнкүреше, аның Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьян сугышында катнашуы турында бик кызыклы документлар, XVIII гасыр татар шагыйрьләре ижат иткән әсәрләр, һәртөрле язмалар тупланган. Халык тарихын, аның культурасын, телен һәм әдәбиятын өйрәнүдә бу истәлекләрнең әһәмияте әйтеп бетергесез зур.

Без түбәндә шундый яңа ике документ турында сөйләячәкбез. Аларның берсе — Каныш Маки угълының 1749 елда язылган васыятьнамәсе, икенчесе — 1763 елда Түрттүбә авылы халкыннан Мәскәүдәге якташларына язылган хатлар[1].

XVIII гасырда татарлар арасында җир биләү ике төрле хокукка нигезләнгән булган. *Йомышлы татарлар* үз хезмәтләре өчен җирне патшадан, поместье милке формасында, бүләк төсендә алганнар. 1718 елда йомышлы татарларны, корабльләр төзер өчен, агач эшенә беркеткәннәр. Шуннан соң аларга поместьелар бирелмәс булган, үзләрен лашман дип атый башлаганнар, ә элек бирелгән җирләрне биләү формасы үзгәрми сакланып калган.

Татарларның икенче өлеше исә *ясаклы татарлар* дип йөртелгән. Алар җирне община, «мир» белән, ягъни бер авыл крестьяннары шул авыл тирәсендәге җирләрне барысы бергәләп биләгәннәр. Җир бөтен общинаныкы булганлыктан, ясаклы татарлар аны сата да, бүләк итеп яки бүлеп тә бирә алмаганнар. Моннан үзгә буларак, йомышлы татарлар үз җирләре белән иркенрәк эш иткәннәр: сата, бүләк итә, мирас итеп калдыра һәм башкача эшли алганнар. Кунгур өязенең Кәбанәк авылыннан булган Каныш Маки улы, йомышлы татар буларак, үз җире белән үзе әнә шулай иркен эш итә.

Йомышлы татарлар XVII—XVIII гасырларда патша хөкүмәтенә каршы күтәрелгән восстаниеләрне бастыруда катнашалар һәм, пленга төшкән башкорт, кыргыз-кайсак, калмыкларны алып кайтып, үз хуҗалыкларына чура (крепостной) лар итеп җиргә утырта торган булганнар.

Түбәндә Каныш Маки васыятьнамәсеннән бер өзек китерелә:

«...Вә янә Шикәр Актажык угълы атасындин-анасындин ятим калды. Алдар җавында. Таркаш урустан алып кайтып бактым. Бик яшь угълан ирде. Үзем бактым. Душын һәм күп түләдем. Янә ул Шикәрне үземә угълыкка сүләшеп асрадым: «Бичә алып бирермен, үз угълым кеби ат-сыер бирермен. Угълым Байраж үсеп бичә алганча, үземдә торгыл», — тидем. Янә ана кыз яраштем, биш сум акча бирдем. Элекке туйны ясадык. Пот бал тотындым. Янә ул, Шикәр, алганча булмады, кызның йортына керде. Миндә тормады. Һәм тормаса да, сүзем сүз булсын тип, ана бер бия бирдем. Андин тугълы бер яхшы ат, ун сумлык. Әлхаль ул маларым ул Шикәрдә, вә янә ул Шикәр яшь булса да, миндә торган вакыт эшләгән эше мәна булсын. Вә янә Калмаш юлда Кырмучак елганың ике яны берлә — мәнем бувнавым, ул ерларне бувнаганда Тимбай миндә ирде, ана мәгълүм, вә янә Шикәр Актажык угълы миндә торган вакыты ирде, аны бувнаганда яшь угълан ирде. Шикәр сөрептур алты приез. Андин артык тимәсен. Вә янә Салапгы башында бувнавымны һәм сөргән Шикәр ике приез. Андин аз һәм тимәсен».

Үз васыятендә күрсәткәнчә, Каныш 1735—40 еллардагы Алдар-Кусюм восстаниесен бастыруда катнаша һәм Шикәр исемле малайны, чура итү өчен, үзенә алып кайта. Ул аны үз хуҗалыгында эшләтә, ләкин бөтенләйгә крепостной итеп калдыра алмый. Шикәр зур үскәч аңардан китә. Бу хәл татарлар арасында крепостнойлыкның җәелә алмавын ачык күрсәтә. Җәелә алмауның төп ике сәбәбе булган:

1. Патша хөкүмәте татарлар арасында экономик көчле бер сыйныф булдырудан курыккан. Мондый сыйныфны үстермәү өчен чаралар күргән. Мәсәлән, Петр I

[1] БАҮДА, 6 фонд, 1 оп, сак. бер. 416, II кисәк, 432 һәм 440—442 битләр.

1713 елда: «Йомышлы татарлар ярты ел эчендә чукынып бетсеннәр, чукынмасалар, аларның крестьяннарын жирләре белән тартып алырга»[1], — дигән указ чыгара. Шуннан соң, йомышлы татарлардан булган морза-крепостникларның саны бик нык кими.

2. Крепостнойлыкка һәм эре жир биләүгә каршы татар крестьяннары кискен һәм көчле кораллы көрәш алып барганнар. Нәтиҗәдә, йомышлы татарлар кулында крепостнойларның саны XVIII гасыр башында 7692 ир кеше булса, 1781 елга бер меңнән артыграк, ә 1860 елга бары 71 кеше генә калган[2].

Каныш тарафыннан яздырылган бу васыять феодаль мөнәсәбәтләрнең үсмәвен ачыклап кына калмый, ә балки яңа, буржуаз мөнәсәбәтләрнең җәелүен дә күрсәтә. Каныш Маки улы акча, заклад, процентлар белән дә эш йөртә, ростовщиклык белән дә шөгыльләнә.

Гомәр Абдулловның Мәскәүгә Рахманколый Канкай улына язган хаты да бик әһәмиятле.

ГОМӘР ГАБДУЛЛА УГЛЫННАН МӘСКӘҮГӘ РАХМАНКОЛЫЙ КАНКАЙ УГЛЫНА

Безки Гомәр Габдулла угълындин сезки дустымыз ду[3] жиһан карендәшем мулла Рахманколый Канкай угълына кәрарәнмәрарән[4] догалар кыйламыз. Гомреңез озын-озын улсын, дәүләтеңез артсын йәүмән-фийәүмән[5]. Үз халемездин сорсаңыз, әлхәмделлиллаһ сагъ вә сәламәт дәю беләсез.

Вә бәгъдә мәгълүм улына: межевой капитандин хәл сорсаңыз, безнең мөселман җәмәгатьләренә һич тә рәхиме юктыр, бик гаять тә рәнҗетәдер шул, шул рәвешле кем, писцовой кенәгәнең[6] копиясен үземез алдык — күп хәреж тоттык. Вә яңа мәгълүм улына: межевой комичнәгә Лихачев капралның өен алдырды — аена бер сумга — ирексезлик илә. Яңа мәгълүм улына: «Ике елдан бире килеп торамын сезләрнең өчен; ашарга-эчәргә һичнәрсә биргәнеңез юк, үземнең ашаймын, — дәю мәгълүм кыйладыр. — Шундайларга бирәсез, кемләр эш эшләмәкдин орса, сукса — анларга бирәсез. Эшеңезне эшләймен, һичнәрсә биргәнеңез юкдыр. Без ормайбыз һәм сукмаймыз — шуның өчен безләргә нәрсә дә бирмәйсез», — дигәнлеке өчен. Түрттүбә берлә: «Кырык читбрүк[1] арыш бирермез», — дәю мәгълүм кыйлдык. Шул капитан ул кырык читбрүк ашлыкка хуш булды. Беразынча базардан сатып алып бирдек. Ул мәзкүр ашлыкны безләрдән тарттырадыр тегермәндә.

Вә яңа мәгълүм улына: «Катарым[2] усал, — дип, — Байчин авылга торырга барырмын», — дәю, истрашит[3] итте. Халык ул сүзне ишедеп: «Безләргә рәнҗү күп булыр», — дип, Тининский Матвей попның өен алдык илле өч сум илле тиенгә. Ул өйгә пич салдырып вә һәм карындык ясатып, булган бозык ерларен төзәтеп, чыгыш булды ете сум. Имде мәгълүм кыйламыз, ул капитан: «Тора торган өем дә ярайдыр», — дип чыкмайдыр ул сатып алган өемезгә. Әмма ул попның өенә шул мәзкүр ете сумдин башка акча бирелмәгәндер. Фәһем идәмез[4], янаралдан куркуы бар, дип. Вә һәм ашлыкны да алмас булды: «Янарал килгәч килтермәнез, киракмәс», — дидер. Вә яңа «печән», «утын» дип безләрдин сорайдыр булган нәрсәләрне. Вә яңа мәгълүм улына: без, Гомәр, Байчин авылымыз берлә бердек унбиш арба печән көз көне былчырак вакытта.

Әмма ләкин алай да булса үзенез фәһем идеп эшләнез: капитанның усаллыкларын мәгълүм кыйламыз. Әмма Лев Катанскийның эше рәвешендә булмагай ирде. Әмма куркамыз шуның өчен: эш тирәнгә китәр дип, яңа камичния булыр дип, капитанга бүләк биргәнне мәгълүм кыйлсак, халыкка авырлык килмәгәй ирде дәю. Вә бәгъдә мәгълүм улына: межевой капитан межа итәр өчен Куйгы Убачига чыкты. Әмма ләкин ер хакында межа итә башлады. Усаллыгы мәгълүм дәгелдер, тугърылык илә эш эшләргә ният бар. «Убачидан безнең Байчин авылга барырмын», дәю мәгълүм кыйладыр. Вә дәхи мәгълүм улына син мулла Рахманколыйга: межевой капитан болын хакында Посат урыслардан побиринная[5] сорады доношения берлә, өч мәртәбә: «Байчин татарларның ерен нә рәвешле көтәсез?» — ди. Әмма анлар побиринная бирмәйләр, грамоталарын да мәгълүм кыйлмайлар. Әмма син, мулла Рахманколый, язмак илә мәгълүм кыйлган ирдең: капитан Травинны һич кеше яратмай дәю. Алай да булса, усаллыкка таба ният юк, вә һәм парутшик[6] тугърылык илә межа итәргә ният бар.

Ушбу юкарыда язылган капитанның бозыклыклары илә эш күрсәтмәйсезләр. Сабыр итәргә боердылар.

Сүземез күп ирде. мөхтәсәр кыйлдык[7].

Түрттүбә халаекларыбыз.

1763 сәнә — елда майның 28 яменде.

---

[1] **Россия империясе законнарының тулы җыентыгы. Рус теленда. 2784 сан.**

[2] **Татарстанны өйрәнү буенча материаллар. II чыгарылыш. 91 бит; Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте җыентыгы. XVIII чыгарылыш. 4—6 битләр.**

[3] **Ду — ике.**

[4] **Кәрарән-мәрарән — иксез-чиксез.**

[5] **Иәүмән-фийәүмән — көннән-көнгә.**

[6] **Писцовая книгә — налог салу өчен халыкны исәпкә алу исемлеге.**

[1] **Читбрүк — четверик, поттан артыграк.**

[2] **Катар — тирә-як.**

[3] **Истрашит — страшить сүзенең бозылып язылганы.**

[4] **Фәһем итү — фикер йөртү.**

[5] **Побиринная (поверенное) — ышанычлык язуы.**

[6] **Парутшик — поручик.**

[7] **Мөхтәсәр кыйлдык — кыска тоттык.**

Бу хат татар крестьяннары өстеннән булган милли-колониаль изүне ачык тасвирлый. Крестьяннарның төрле категорияләре бер үк жиргә төрлесе төрле вакытта, төрле-төрле авыллар булып килеп утырганга, XVIII йөздә авыллар арасында жир низаглары күбәя, бер авыл жире белән икенче авыл жире арасындагы межалар билгеләнмәгән була. Хөкүмәт бу низагларны бетерер өчен 1757 елда межалау инструкциясе чыгара. Межа комиссияләре төзелә. Аларга баш итеп межевой комиссарлар куялар. Башка патша чиновниклары белән берәттән, алар да халыкны теләсә ничек талаганнар. Халык талаучылар өстеннән жалоба бирергә дә курыккан.

Рахманколый Канкай улы — Кунгур өязе (хәзерге Пермь өлкәсе) татар крестьяннарының Мәскәүгә жибәрелгән вәкиле. Русча һәм татарча грамоталы мондый кешеләрне крестьяннарның Мәскәүгә һәм Петербургка үз вәкилләре итеп үтенеч белән жибәрүләре гадәти бер хәл булган.

Архивтагы башка хатлардан Рахманколый Канкай улының мөлкәтле кеше булуы аңлашыла. Семьясы ишле булган, хужалыгында батраклар эшләгән, ә үзе Мәскәүдә сәүдә белән шөгыльләнгән.

Яңа табылган документлар XVIII гасырда татарлар арасында укымышлылыкның торышына да билгеле дәрәҗәдә яктылык ташлый. Архивтагы документларның барысы да 1773—1775 еллардагы крестьяннар сугышын бастыру барышында патша гаскәрләре кулына эләккән крестьяннардан алынганнар. Монда эш кәгазьләре дә, әдәби әсәрләр, бәетләр һәм шигырьләр дә, китаплар да бар. Мәсәлән, Якупов дигән кешедән 10 сумлык, Мостаевтан 18 сумлык 12 китап, Мөсәлимовтан 1 сумлык бер китап алынган [1]. Ул чакта китаплар бик кыйммәт булганнар (арышның поты 10 тиен булганда, бер китап бер сум һәм кыйммәтрәк тә торган). Шулай булуга карамастан, китап сәүдәсе шактый жәелгән. Киң таралган кулъязма китаплар һәм әдәби әсәрләрдән башка, XVIII гасыр ахырында басма китаплар да чыга башлаган. 1800—1803 елларда инде Казанда барлыгы 12 300 данә басма китап чыгарылган [2].

Халыкның күп өлеше грамотасыз булып, карангылыкта яшәсә дә, грамоталы кешеләр дә байтак булган. Ул вакыт тарихчысы Рычков үзенең юл язмаларында һәрбер татар авылында балалар өчен мәктәпләр (мәдрәсәләр) бар дип һәм:

«Күп кенә татар мужикларының, бигрәк тә сәүдә кешеләренең зур булмаган язма әсәр жыентыклары бар һәм үзләре турында, шулай ук күрше илләр турында яхшы гына белемнәре, монардан башка тагын үзләренең борынгы тарихлары турында байтак мәгълүматлары бар», — дип яза. XVIII гасыр рус сәяхәтчеләре: «Грамотасыз кешеләр татарлар арасында хөрмәт һәм ихтирам белән файдаланмыйлар» [1], — дип язганнар. Хәзерге кайбер авторлар XVIII—XIX гасырлардагы татар мәдрәсәләре бернәрсәгә дә өйрәтмәгәннәр дип язалар. Хәлбуки, яңа табылган материаллар моны расламый. Мәсәлән, 1820 елга килгәндә «татарларның аз дип исәпләгәндә һәр жиденчесе грамоталы» булган [2].

Хәлфин, Алкин, Тәвкилевләр кебек морзалардан башка да, русча белүче, рус грамотасына өйрәнгән кешеләр булган. Казан губернаторы Фон-Брандт 1771 елда, Свияга провинциаль канцелярисенә тылмач итеп, Хөсәен авылы ясаклы крестьяны Юлдаш Маметкуловны жибәргән. Фон-Брандт Маметкулов турында болай яза: «Әтисенең тырышлыгы нәтиҗәсендә, татар һәм рус грамотасына укый, яза белерлек итеп өйрәтелгән... Тышкы эшләр дәүләт коллегиясендә комплекттан тыш студент булып торган» [3]. Якуп Биметов исемле берәүнең 1762 елда турыдан-туры патшага исемләп язган мондый үтенече бар: «Минем малаем Субханкул Якупов, үземнең тырышлыгым аркасында, татар һәм рус грамоталарына укырга һәм язарга, татар теленнән русчага тәржемәләр ясарга өйрәнде. Тылмач булып ул 3 ел эшләгән иде. Штат кыскару нәтиҗәсендә хәзер хезмәттә түгел. Яңадан тылмач итеп урнаштырсагыз иде» [4].

Пугачев житәкчелегендәге крестьяннар сугышында катнашкан татарлар арасында да русча сөйләшә һәм русча укый-яза белгән татарлар байтак очрый. Крестьян отряды житәкчесе Юскәй Кудашев, татарча язылган Пугачев манифестларын русчага тәржемә итеп, рус, удмурт крестьяннары арасында тараткан. Пугачев полковниклары Каранай Моратов, Канзафар Усаев, Енгалычев һәм башкалар Пугачев манифестларын татарча да, русча да укып йөргәннәр, аларны күчереп таратканнар.

Татарның укымышлы кешеләре, әлбәттә, патша администрациясендә дә эшләгәннәр. Ләкин эшкә урнашу бик кыен булган. Бер мисал китерик. Тарихта билгеле булган Сәгыйт Хәлфиннең туганы Әхмәтгәрәй Хәлфин бик яхшы белгеч булган. Моны аның аттестаты ук раслый. Аттестат үзе Петербургтагы чит ил эшләре

---

[1] Борынгы актлар үзәк дәүләт архивы, 6 фонд, 1 оп. сак. бер. 592, 52—54 битләр.

[2] Г. Гобәйдуллин. Татар тарихы. Казан. 288—294 битләр.

[1] Россия дәүләтендә яшәүче барлык халыкларны тасвирлау. Рус теленда. II бүлек. 1792 ел. 11—12 битләр.

[2] Татарстан тарихы документларда һәм материалларда. Казан. 1937 ел. 353 бит.

[3] БАУДА. 441 фонд. 1 оп. сак. бер. 679, 1 бит.

[4] Хәрби диңгез флоты үзәк дәүләт архивы, 212 фонд, 1 оп., сак. бер. 28, 46—49 битләр.

коллегиясе тарафыннан бирелгән һәм анарда түбәндәге юллар бар:

«Император хәзрәтләренең указы һәм чит ил эшләре дәүләт коллегиясе билгеләве буенча, бу аттестат титуляр советник Әхмәтгәрәй Смайловка Хәлфин угълына түбәндәгеләр турында бирелде: ул император хәзрәтләре хезмәтенә 1802 елда мартның 2 нче көнендә татар һәм Россия телләрен белгәнлектән күрсәтелгән коллегиягә актуариус итеп алынды; 1804 елда апрельнең 15 ендә Бийскийга Алтай тауларыннан монда килгән калмык зайсаны князь Казаковны свитасы белән озату өчен жибәрелде; 1806 да гыйнварның 8 ендә шул ук коллегиянең тәрҗемәчесе итеп күтәрелде; ә 1811 дә августның 31 көнендәге үзенең үтенече буенча, авыру сәбәпле хезмәттән азат ителде, ана шул ук елда, айда һәм көндә, ул Хәлфинны шул ук 1811 елның 9 августында титуляр советник чины белән бүләкләүне сорап Идарә итүче Сенатка тәкъдим ителүе турында һәм коллегия ведомстенда хезмәт иткән вакытта үзен яхшы тотты, кушылган эшләрне тырышлык белән үтәде дип коллегия тарафыннан 3554 номерлы аттестат бирелде»[1]. Шундый кеше дә эшкә урнаша алмыйча шактый җәфалар күрә. 1819 елда Казанга килгән Сенат ревизия комиссиясенә адреслап, ул махсус гариза яза һәм түбәндәгеләрне белдерә:

«1811 елдан бирле эшсез, карт ата-анам жилкәсендә торуым алар өчен авыр булганлыктан, 1815 елда губерния правлениесенә гариза биргән идем, ләкин ана жавап булмады һәм ул пожар вакытында янды. Губерния правленнесе 1818 елда мине, дворяннар жыелышы яхшы дип тапса да, Царевококшайский земский судына дворяннар заседателе итеп билгеләмәде. Үземнең һәм ата-анамның бернинди малы булмаганлыктан һәм бик ярлы хәлгә калуыбыз нәтиҗәсендә, сездән мине чиным буенча хезмәткә алуыгызны сорарга батырчылык итәм»[2].

[1] **Ленинград Үзәк дәүләт тарих архивы, 1553 фонд, 1 оп., сак. бер. 13, 4—5 битләр. (Документ рус теленнән безнең тәрҗемәдә бирелә — С. А.)**

[2] **Шунда ук, 1—3 битләр.**

Грамоталы татарлар Казан өязеннән Башкортстан һәм Оренбург якларына китеп тә «балаларны татар грамотасына» укытканнар. Үрбара авылы ясаклы крестьяны Халит Хәлимов, Курбашы авылы крестьяны Әбҗәлил Мусалимов һ. б. авыллардан Җәгъфәр Якупов, Муса Мостаев, Зәбир Уткулов, Назир Утямишев, Абдрахман Хөсәеновларны Пугачев хәрәкәтендә катнашкан дип кулга алгач, алар 1773 елда Башкортстан һәм Оренбург якларына «балаларны татар грамотасына укытыр өчен бардык» дип күрсәтәләр. Аларның бу күрсәтмәләре архивлардагы документлар арасында саклана[1]. Ә Ширдан авылы йомышлы крестьяны Әмир Ишимев «Твердышевның Уралдагы Воскресенский заводында крестьян балаларын татар грамотасына өйрәтү өчен 2 ел торды»[2],— дип сөйли. Бу фактлар, беренчедән, Башкортстандагы мәктәпләргә укытучылар Татарстаннан баруын раслый. Икенчедән, болар ул вакыттагы Урал заводларында татар крестьяннарыннан булган эшчеләрнең дә инде байтак эшләвен, балаларны укытыр өчен махсус укытучылар яллаганлыкларын күрсәтә.

Ләкин халыкны уку-укыту эшләрен патша властьлары, ислам дине тоткарлаган.

Бу мәкаләдә китерелгән документларның әһәмиятләре башка яклардан да юк түгел. Мәсәлән, хатларда китерелгән исемнәрнең чын төркичә булуы, гарәптән кергән исемнәрнең бик сирәк очравы XVIII гасырда татар халкының бу өлешендә исламның тәэсире әле кимрәк булуын күрсәтә. Документларда тел фәне өчен дә кызыклы материаллар бар. Боларны киләчәктә жентекләп өйрәнергә кирәк булачак.

С. АЛИШЕВ,
СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни эшчесе.

[1] БАҮДА, 6 фонд., 1 оп., сак. бер. 592, 32—69 битләр.

[2] БАҮДА, 349 фонд., 1 оп., сак. бер. 7184, 5 бит.

Г. Шамуков

Елан кырмыска оясында

Елан, яман ният белән,
Кырмыскалар оясына бәреп кергән.
Ә кырмыска халкы бердәм:
Чакырылмаган бу кунакны күрү белән,
Кайный башлый бөтен оя, зур казандай.
Елан, янган утка китереп ташлагандай,
Әрнүенә чыдый алмый,
Боргалана,
Сыргалана,
Үрле-кырлы сикерә, ауный;
Ары омтыла,
Бире омтыла.
Җәһәннәмнән чыгып ычкынмакчы була,
Әмма ләкин булдыралмый.
Кырмыскалар һөҗүменнән котылалмый.
Зәһәрләнеп чагуы да,
Һәлакәтле агуы да
Бу сугышта файда итми аңа һич тә.
Ахыр чиктә
Кычкыра ул сорап ярдәм
Урмандагы җәнлекләрдән:
— Коткарыгыз!.. Ах!.. Каравыл!..
Зинһар өчен куймагыз юл
Җинаятькә, хаксызлыкка!
Бер дә юкка
Күрәм җәбер!..
— Хаклык кирәкмени хәзер? —
Ди Бал корты. — Ләкин син бел:
Юләрләр юк, алданмаслар. Хаклык монда
Кем ягында —
Сизеп тора һәрбер күңел.
Күрәләр ич: кырмыскалар синдә түгел,
Син кырмыска оясында.

Тәэсирле хат

Имеш бер чак
Капыл гына
Кара урман башлыгына —
Аю картка килеп төшкән шундый бер хат:
«Сәлам сезгә, — дигән, — яшел, киң тугайдан,
Күк томанга төренгән Ялантаудан,
Җәелеп яткан буз яланнан...»
Аннан
Тагын шундый сүзләр хатта:
«...Карурманның сандугачы,
Бар галәмгә мәгълүм җырчы,
Килеп чыгып әллә кайдан безнең якка,
Кин яланны, Ялантауны, елга, күлне,
Бар җәнлекне, кош-кортларны — бөтен илне
Гажәеп җыры белән итте хайран,
Сихерләде һәр күнелне.
Җырының тәэсире шундый көчле,
Тынлагач та сихри моңын,
Бу дөньяда яшәүнең бар матурлыгын
Тирән итеп анлагандай булдык төсле.
Рәхмәт сезгә,
Шундый җырчы биргән өчен илебезгә!»
Шундый җылы хат укыгач,
Аю түрә тирән уйга батты чынлап:
— Кара син, ә! Болай булгач,
Чакыртып үзем дә бер карыйм тыңлап.

Аптыраш

Берәү
Тәмам аптыраган
бер дустына очраган.
«Ни булды? Ник төсең китте?» — дип сораган.
Әйткән теге: — Яңа гына
Начальнигым чакырып сорау бирде миңа:
— Яле тизрәк әйтсәнә, ди,
Кайсы тирәсендә кайсы әйләнә, ди:
Кояшмы Җир тирәсендә,
Җирме Кояш тирәсендә?
Шул сорауга жавабыңны бирәсең дә.
Бушатам ди, кайтып китәсең ди хәтта.
— Белмисеңмени бу хакта?
— Ничек белмим?
Ул кадәр үк тун түгел мин,
Укыган бар Галилейны, Коперникны,
Бу хакта бик фикерем ныклы.
Беләм, Кояш тирәсендә әйләнә Җир.
— Бар, алайса, тиз шулай дип жавап та бир.
— Ай-һай ансат килеп чыга бу синенчә!
Бәлки, хужам уйлыйдыр киресенчә?

Газиз Мөхәммәтшин

ТӘМӘКЕНЕ НИЧЕК ТАШЛАРГА?

Хикәя

Мин элегрәк хатын-кыз туганнарыбызга «Файдалы киңәшләр» биргән идем һәм анда, ни өчендер киң күңеллеләнеп, ир затлары өчен дә берәр киңәш язу уе бар, дип ычкындырган идем. Сүземдә тора торган егет буларак, мин ул вәгъдәмне үтәдем.

Менә ул киңәш:

Тәмәкене ничек ташларга?

Бу сорау белән бигрәк хатыннар һәм тәүлегенә егерме дүрт сәгать йөткерә башлаган стажлы тартучылар кызыксына.

Тәмәке белгечләре, бер пачка папиросның никотины атны үтерә, диләр. Ләкин мин моңа кадәр тәмәке тартучы атны очратмадым. Шунлыктан тәгаен генә әйтә алмыйм. Әмма яшь һәм башлап тартучыларга моны белеп торуның зыяны тимәс дип уйлыйм.

Иң элек тәмәкене кемнәр тартуын ачыкларга кирәк. Үзеңнең бу илкәдәге күп еллык тәҗрибәмә һәм шактый олы галимнәрнең шактый калын хезмәтләренә караганда, тәмәкене:

1) иптәшләре алдында мактанасы, тизрәк егет исеме күтәрәсе килгән тәмәке буе акылсыз малайлар тарта;

2) сөйгән кызы белән күрешергә баргач, сөйләшергә сүз тапмаган, кулын кая куярга белмәгән, мәхәббәт өлкәсендә тәҗрибәсе чамалырак егетләр тарта;

3) авыруларга, тартуны бүген үк ташлагыз, дип үгет-нәсихәт бирүче врачлар һәм тәмәкенең зарары хакында гомере буе лекция укып йөрүче лекторлар тарта;

4) өч минут эшләгән саен биш минут перекур ясарга яраткан «сыек бавырлы» кешеләр тарта һәм

5) болар графасына эләкмәгән башка күп миллионлы гади тартучылар тарта.

Тәмәке «кортларының» төгәл саны әлегә билгесез. Аны чутлау өчен электрон-хисаплау машинасы кирәк. Ә тәмәке белән арасын өзгән чакма ташыдай каты бәгырьле ирләрне санарга кул бармаклары да җитә. Әмма бу батырларның баш санын арттыру — һәр тәмәкеченең изге бурычы.

Моның өчен нишләргә кирәк? Ир-егетнең юлдашы — тәвәккәллек. Беткән баш беткән, диярга дә тәвәккәлләп тәмәкене ташларга кирәк. Ә бу процесс һәр вакытта да дип әйтерлек түбәндәгечә була:

Иң алдан, тартуны ташлаудан бер ай элек, тәмәкедән бизүегез турында бөтен дөньяга хәбәр таратыгыз. Иптәшләрегезнең башына күсәк белән тондырган шикелле булсын, күзләре акайсын. Шуннан соң: «Кешенекен тартып ардым — син бир әле, суырып карыйм әле! Хәзер тәмәкедән нинди тәм килә икән!» дип, бөтен җирдә, бөтен кешедән «атуга» күн-

чегез. Моның сезгә ике төрле файдасы тиячәк. Беренчедән, таныш-белешләрегез алдында серле һәм көчле бер геройга әйләнерсез. Алар гел сезнең хакта гына сөйләшерләр, үзенең фәкыйрь башына үзе теләп алган газап утында газаплана, тимер ихтыярлы егет икән, дип сезне кызганырлар һәм, астыртын гына көнләшеп, эчтән сызып яшәрләр. Икенчедән, дөнья кадәр акчагыз янга калыр. Көненә егерме өч тиеннән (бер пачка «Беломор», бер кап шырпы) чутлаганда, ай саен 6 сум 90 тиен акчагыз үз кесәгездә кала. Ә ул елына 83 сум 95 тиен, ун елга 839 сум 50 тиен, йөз елга 8395 сум (яңа акча белән!) җыела.

Дөнья җанлы акыллы адәмнәр бу хәзинәгә Идел ярыннан дача һәм, остәвенә, ялтыр лаклы «Волга» машинасы алалар. Ә тәмәкече-бөкече — иске сандал чүкече дип атказанган җүләр башлар кулларына үзе килеп кергән бу мескен дача белән мескен автомобильне авызларыннан һәм борын тишекләреннән төтен итеп өреп бетерәләр...

Шуларны искә алып, тагын берәр ай «КТФ» (Кешенекен Тарту Файдалы) суырып, иптәшләрегезне саламга сөяп йөрегез дә, инде аларның баш шәрифләрендә икеле-микеле уй кузгатмас өчен, атудан шып туктагыз. Хәзер инде үлем белән бер момент — юри-мырый түгел, чынлап ташлау моменты килеп җитә. Ләкин ахылдарга-вахылдарга, җиде катлы дөньяның җиде катын да берәмтекләп сүгеп чыгарга ашыкмагыз. Тәмәке ташлау бик җиңел. Марк Твен әйтүенчә, кайбер көчле ихтыярлы кешеләр аны үз гомерләрендә унсигезәр тапкыр ташлыйлар икән.

Ху-уш!.. Беренче көнне барлык дусларыгызны (әгәр булсалар!) һәм таныш-белешләрегезне күреп чыгыгыз: кирәк урында ялагайланып һәм хәйләләп, куркытып һәм янап бик каты кисәтегез.

— Бүгеннән минем алда көйрәтмәгез, тәмәке хакында лыгырдамагыз!...

— Елый-елый сорасам да, тезләнеп ялынсам да, пычак чыгарып һөҗүм итсәм дә, бер чеметем тәмәке бирмәгез, төпчек калдырмагыз! Акырып-бакырып үләргә ятсам да кызганмагыз!

— Мин сорый дип тәмәке сузган кеше белән гомергә исәнләшмим. Ул минем кан дошманыма әйләнәчәк! — диегез.

Мәҗлесләрдә кәефләнеп утырганда харап итмәсеннәр. Сак булыгыз, моны исегездән чыгармагыз. Чөнки бер-ике рюмка тондыргач, тамак төбе юхаланып кымырҗый башлый. «Давай, булмаса кабызып җибәр, син кемнән ким! Бүтәннәр әнә уйлап та бирмиләр — рәхәтләнеп тарталар!» — ди. Алкоголь белән никотин — мур кырган нәрсәләр — бик дус, бергәрәк йөрүне яраталар. Арслан йөрәкле, тимер күкрәкле күп ирләр, шушы ике тәмуг кисәвен җиңә алмыйча, рюмка каплый-каплый үзләре капланалар. Шуңа күрә бу мәсьәләдә иптәшләрегезнең колагына кайта-кайта кирт киртегез.

Кисәтеп, кирт киртләп чыккач, ярты мәшәкать бетте, дип исәпләгез. Өегезгә кайтыгыз да бар булган трубкаларыгызны, мөштекләрегезне, көл савытларын, Кара диңгездән алып кайткан кабырчыкларыгызны һәм тимер каплы шырпыларыгызны үзегез яратмаган, дошманрак күргән кешеләрезгә өләшеп, бүләк итеп бетерегез. Аннан соң бөтен папиросларыгызны чүп савытына чыгарып салыгыз. (Ләкин алдагысын алла белә: чүп савытының корырак урынын сайлагыз...)

Ярый, ху-уш! Инде бу мәшәкатьләр белән дә исәпне өзгәч, эшләгән җирегездән, берәр хәйлә табып, үз исәбегезгә ял алыгыз. Дөньяда нинни хәйләләр барлыгын бөртекләп язып тормыйм. Чөнки өйләнеп бер-ике ел яшәгән ирләрне хәйләгә өйрәтеп торасы юк.

Ял вакытында өегездән чыкмагыз. Телегезне аркылы тешләп булса да түзегез. Түзгән — тимерне дә өзгән, ди. Көнбагыш, кабак төше, эрбет чикләвеге чиртегез, монпаси суырыгыз, чөгендер, шалкан, кәбестә һәм кабак ише нәрсәләр кимерегез. Чи чөгендер кимерү, гадәттә, тамаксау кешеләрне дә бик тиз ялкыта. Алар нервланалар һәм хатыннарыннан,

чуерташ шикелле каты монпаси урынына, хуш исле йомшак шоколад даулый башлыйлар. Сез дә озакламый лач-лоч шоколад ашарга тотынырсыз. Ләкин, йөзләрчә тәҗрибәләргә күз салсак, бу метод бик үк ышанычлыдан саналмый. Кеше акылы ирешмәслек коточкыч газапларыгыз инде ахырына якынлашып килгәндә, сөекле хатыныгыз бер пачка сигарет бәясе белән сез унарлап-унарлап умырган шоколад акчасын чагыштырып карый да, семья бюджетына катастрофа янавын сизенеп, җаны көеп кибеткә йегерә. Соңыннан... ну, соңыннан еллар буе: «Тартуыңны ташла, тартуыңны таш-ла», дип колак итегезне чәйнәгән хатыныгыз үзе кайтарып тоттыргач... һм, гомеренә бер мәртәбә хатын сүзен дә тыңларга кирәктер ләбаса...

Әгәр бу юл сезгә авыр тоелса, яки аның алдан үк уңышсыз бетәчәген сизеп торсагыз, гарантиялерәк икенче чара да бар. Тын океан уртасындагы кечкенә генә комлы утрауга башыгызны алып олагыгыз һәм анда Робинзон Крузо шикелле яшәп карагыз. Үләнле утрауда үлән яфрагы көйрәтү куркынычы бар. Дәрес, комлы утрауда да сигезаяк тотып, шуның аягын киптереп һәм балык саңагы уып тартырга маташу фактлары булды. Ләкин, бәхеткә каршы, киң катлау пыскытучылар арасында бу ачыш ни өчендер яклау тапмады.

Утраудан кайтып эшегезгә чыккач, авызыгызда папирос күреп, ипташләрегез бик нык гаҗәпләнерләр. Тик каушап калмагыз. «Докторлар үзләре көчләп куштылар: йөрәгемне май басу куркынычы бар», дип, җәелгән авызларын җыелырга мәҗбүр итегез. Бераздан тагын: «Тәмәкене яңадан ташлыйм!» дип хәбәр таратыгыз. Тагын төпчек атуга күчегез. Шулай иткәндә, исемегез халык теленнән төшеп тормас, сезгә гел кызыгып яшәрләр...

Менә, ирләр һәм егетләр, киңәшем шушы урында тәмам. Бүтән киңәш бирә алмыйм. Чөнки мин гомер буе үзем күргән, үзем белгән нәрсәләр турында гына язам. Белмәгән әйберләр хакында ничек итеп башкаларга акыл өйрәтмәк кирәк!..

Аннан соң, кызганычка каршы, менә хәзер генә тәмәкем бетеп китте. Бер олы язучының, тәмәке тартсаң, әйбәт языла, дигән киңәшен тотып тартырга өйрәнгән идем, хәзер шул хәтле гадәтләндем — авызымда папирос көйрәп тормаса, бер сүз дә яза алмыйм...

—✦—

Хөрмәтле редакция!

Журналның 9 санында басылган «Зөбәйдә — адәм баласы» — Шәриф Хәсәенов әсәре бик ошады миңа.

Безнеңчә, әсәр бик гыйбрәтле. Беренчедән, ул ата-аналар алдында бала тәрбияләү мәсьәләсен күтәрә: адәм баласын ашату-киендерү генә тәрбия була алмый әле, димәк. Икенчедән, яшьләр өчен мәхәббәтне аңларга ярдәме зур: тышкы матурлык кына түгел, рухи дөньяның да тормышта зур роль уйнавын аңлармар алар.

Шундый әсәрләрне журнал күбрәк бастырып чыгарса икән.

ТӘЗКИРӘ ГОМӘРОВА,
Балтач районы, Түбән Кенә авылы.

●

Мин журналның «яшь» укучысы әле. Мин рус мәктәбендә укыдым, шуңа күрә, моннан 6—7 ел элек үз әдәбиятыбыз турында бик аз белә идем, яшермим.

Берничә ел элек журналны укый башладым мин, хәзер исә аның даими укучысына әверелдем инде: бик ошый ул миңа!

Журналдан алган тәэсирләрне башкалар белән бүлешмәү бик кыен булыр иде! Шуңа да мин журналны — инде үземнең журналны — пропагандалаучыларның берсенә әверелдем бугай. Журналны үземә мин «ачкан» кебек, яңа гына ала башлаган танышларым да аны яратып укый хәзер.

Журналда басылган әсәрләр арасында үзеңә ошаганнарны саный китсәң, алар бик күп: Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»е, Аяз Гыйләҗевнең «Берәү» повесте, Р. Мостафин мәкаләләре, яшь, кызыклы шагыйрь Равил Фәйзуллин шигырьләре...

Әдәбият һәм сәнгать тарихына караган материалларның күплеге сөенечле хәл.

Берничә тәкъдимем:

Артистлар, спортсменнар турындагы очерклар булу белән бергә, милли галимнәребез: физиклар, химиклар, математиклар турында да материаллар булса икән.

Ноталары белән бирелгән яңа җырларны күбрәк күрәсе килә.

«Сүзләр биографиясе» бүлеге дә кирәктер журналыбызга.

Һәм, аннары, төп теләгем: редакция елга 1—2 мәртәбә булса да, үзенең укучылары белән очрашу, фикер уртаклашу, журнал турында сөйләшү оештырса, ул аның тагын да матуррак балкуына, һичшиксез, ярдәм итәр иде.

РӘШИТ СӘЙФУЛЛИН,
инженер.
Казан.

«Казан утлары» журналын түземсезлек белән көтеп алам мин.

Мин язучы яки тәнкыйтьче түгел, меңәрләгән әдәбият сөючеләрдән берсе генә. Шунлыктан журналда басылган барлык әсәрләргә анализ ясауны максат итеп куймыйм. Бары тик үземнең дөньяга карашыма, хыялыма җавап биргән Фаик һәм Җәмил Мостафиннарның «Бәхетле кеше», «Кечкенә булса да» исемле очеркларына, Фаяз Дунайның «Экранда күрсәк икән» исемле публицистик мәкаләсенә карата беркем сүз әйтеп китмәкче булам.

«Замандашларыбыз» рубрикасын ачуга, тормышны бөтен нечкәлеге белән белергә омтылучы, җиңүгә ышаныч белән караучы замандашыбызның фоторәсеме үзенә җәлеп итә. Ул — «Эзләнү бетмәде, киресенчә, башлана гына»... дигән тирән философик фикернең авторы — «киләчәктә салыначак мәгърур бинаның нигез ташларын» салучы, кешенең сәламәтлеге өчен фидакарь көрәшче, медицина өлкәсендә эшләүче бөтен Җир шары галимнәрен, кешелекне тәк калдыручы медицина фәннәре докторы, татар егете Диләвер Зөбәеров икән.

Ә менә икенче замандашыбыз — Галимҗан Хөсәенов.

Лондонда барган дөнья чемпионатын телевизордан карағанда, бу турыда үзәк һәм өлкә газеталарында басылган отчетларны укыганда, ничек күбрәк беләсе килгән иде ул Галимҗан турында!

«Кечкенә булса да...» дигән очеркны укыгач, туган илебезнең даны өчен көрәшүче, олы ихтыярлы егетнең Татарстаннан, Октябрь районы, Яңа Игълай авылыннан булуына чын-чынлап горурландым.

Киләчәктә шундый замандашларыбыз турында күбрәк язылсын һәм күбрәк материаллар басылсын иде «Казан утлары»нда.

«Экранда күрсәк иде» исемле мәкалә дә мине беренче юлларыннан үк үз эченә алып кереп китте. Бу гади мәкалә генә түгел, ә бәлки заманыбызның таләбе.

Татар кино сәнгатенең киләчәге турында чын йөрәгеннән белән әрнеп әйткән фикере өчен Фаяз Дунайга бөтен күңелем белән рәхмәт әйтәм һәм журналны укучылар минем фикерем белән кушылырлар дип ышанам.

ӘНВӘР МӘҮЛИХАНОВ,
Башкортстан АССР,
Нефтекамск шәһәре.

Мин журналны беренче ел алдырам. Әмма анда басылган әсәрләрнең күбесе охшагангамы, әллә киләчәктә аннан кирәкле җимешләр алу өмете беләнме, быел подписка башлангач, «Казан утлары»на сентябрь туу белән үк барып язылдым.

Көндез Орско-Халиловский металлургия комбинатында электрик булып эшлим. Кичләрен металлурглар культура сараенда татар үзешчән сәнгать түгәрәгенә җитәкчелек итәм. Соңгы вакытларда журналда сатирик һәм юмористик шигырьләр, интермедияләр яки бер һәм күп пәрдәле комедияләр басу бик нык кимеде. Бәлки шуңа күрәдер, сәнгать өлкәсендә эшләве дә бик авыр. Ә менә журналның 9 санында басылган «Зөбәйдә — адәм баласы» исемле сәхнә әсәре басылуын без хуплап каршы алдык. Ике занятиедә без аны укып бетердек. Өченче занятиедә рольләрне бүлеп, кышкы сезонны ачу йөзеннән, әзерли дә башладык. Бу яңа эшебез белән Новотроицк, Орск, Медногорск, Оренбург, Соль-Илецк һәм өлкәбезнең бүтән күп кенә шәһәрләре тамашачыларын шатландырырбыз дип уйлыйбыз.

Аннары журналның өч санында басылган Локман Айтовның «Артистның тормыш юлы» да сәнгать кешеләре өчен искиткеч зур яңалык. Без аны һәр репетиция алдыннан коллективта укыдык.

Менә шулай «Казан утлары» киләчәктә дә сәнгать сөючеләргә ярдәмгә килер, дип зур өмет белән илһамланып яшибез без.

МИДХӘТ МУЛЮКОВ,
Оренбург өлкәсе,
Новотроицк шәһәре.

ИҢ-ИҢ...

Дөньяда иң зур күләмле ризык — кыздырылган дөя. Бәдәвиләрнең иң ярата торган туй ашамлыгы ул. Аны менә болай әзерлиләр: башта йомыркалар пешерәләр; аннары ул йомыркаларны балык эченә тыгып пешерәләр; аннары балыкларны пешкән тавыклар эченә тыгып пешерәләр; аннары тавыкларны кыздырылган сарык түшкәсе эченә тыгып пешерәләр, һәм, ниһаять, сарыкны дөя түшкәсе эченә тыгып пешерәләр.

●

Бүгенгә кадәр сакланып калган иң борынгы уку йорты, ихтимал, Фец шәһәрендәге (Марокко) университеттыр. Безнең эраның 859 елында ачылган ул. Ә Европадагы университетларның иң борынгылары — Оксфорд (Англия) һәм Париж университетлары. Оксфорд университеты 1167 елда, Парижныкы — 1180 елда ачылган.

●

Дөньяда иң зур университет бинасы — 1953 елда Мәскәүдәге Ленин тауларында салынган Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетыныкы.

●

Дөньядагы картина галереяларының иң зурысы — Ленинградтагы Эрмитажда. Аның өч миллионлап сәнгать әсәре саклана торган барлык өч йөз егерме ике залын да карап чыгар өчен егерме биш километр чамасы җир үтәргә кирәк.

●

Укучылар арасында еш кына татар теле грамматикасының катлаулылыгыннан сукранучыларны очратырга туры килә. Әмма, башкалар белән чагыштырганда, ул һич тә алай сукранырлык ук катлаулы түгел икән. Төньяк Америкада яшәүче индеецларның чиппевей дип атала торган халкы теленда, мәсәлән, бары тик фигыль формалары гына да алты меңләп (!). Эскимослар теленда дә фигыль формалары алтмыш өч, ә исемнәрнең берлек санындагы флексиясе ике йөз илле ике чамасы.

●

Җир йөзендәге иң күп сүзле газета — «Нью-Йорк таймс»ның 1963 елның 7 апреле көнне чыккан якшәмбе саны. Бу сан барлыгы җиде йөз ике бит тәшкил итә. Аның авырлыгы өч килодан чак кына кимрәк.

●

Дөньяда иң кыйммәтле пунктуацион (тыныш билгесе) хата 1962 елның ноябрь аенда Америкада ясалган. Исәпләү машинасына бирелгән программада дефис (сызыкча) төшеп калу аркасында. Кеннеди борыныннан Венерага очыртылган унсигез миллион долларлык космик ракетаны шартлатырга туры килгән.

●

Иң кәрт милли гимн — Япония гимны. Аның тексты IX гасырда ук язылган инде. Ә иң озын милли гимн — йөз илле сигез строфадан торучы грек гимны. Япония гимны нибары дүрт кенә строфадан гыйбарат. Иордания һәм Сан-Марино гимннары да шулай ук кыска.

●

Дөньядагы оркестр барабаннары диаметрының иң зуры өч метрга якын. Ул гигантның иясе — Техас (АКШ) университеты оркестры.

Яңа Китаплар

Мирсәй Әмир

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Беренче том

Татарстан китап нәшрияты өлкән буын язучыларыбызның икешәр-өчәр томлык «Сайланма әсәрләр»ен чыгара башлады.



Алтмыш яше тулу унае белән, күренекле прозаик һәм драматург Мирсәй Әмирнең дә «Сайланма әсәрләр»енең беренче томы басылып чыгып, китап кибетләренә сатуга тапшырылды. Барлыгы өч томнан торачак ул «Сайланмалар»ның бу томына әдип иҗатының башлангыч чорында, төрле елларда язылган һәм әле бүген дә актуаль яңгырый торган иң яхшы әсәрләре тупланган. Атап әйткәндә, М. Әмирнең бу томына егерме бер хикәя, унөч фельетон һәм «Пар күгәрчен», «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре», «Карамалы егете», «Безнең авыл кешесе» исемле повестьлары урнаштырылган. Китапның бәясе 80 тиен.

Әмирхан Еники

САЛАВАТ КҮПЕРЕ

Әмирхан Еникинең бу җыентыгына «Бер генә сәгатькә», «Тауларга карап», «Кем жырлады», «Ялгызлык», «Туган туфрак», «Шаяру», «Яшьлек хатасы», «Матурлык», «Төнге тамчылар», «Узып барышлый», «Коръәнхафиз» һәм «Әйтелмәгән васыять» исемле иң әйбәт хикәяләре урнаштырылган. Художество ягыннан гажәеп оста эшләнгән һәм төрле темаларга язылган ул хикәяләрне укып чыкканнан соң, чыннан да, салават күперен

күргәндәй буласың: аларның барысының да үз төсе, үз аһәңе бар.

Китапның бәясе 50 тиен.

Фатих Хөсни

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Беренче том

Күп санлы хикәяләр, повестьлар һәм «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» исемле романнар авторы Фатих Хөснинең дә «Сайланма әсәрләр»енең беренче томы басылып чыкты. Әдипнең бу томына илле бер хикәя һәм «Зәңгәр жыр», «Гармоньчы» исемле ике повесте кергән. Хикәяләр, кайчан язылуларына карап, «Сугышка хәтле», «Сугыш чоры» һәм «Сугыштан соң» дип аталган бүлекләргә аерып бирелгән. Ф. Хөснинең бу томына кереш сүзне Ибраһим Гази язган.

Китапның бәясе 89 тиен.

Атилла Расих

МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬЛАР

Күп санлы китап сөючеләр тарафыннан яратып укыла торган «Язгы аваз-лар» һәм «Ике буйдак»

исемле романнар авторы Атилла Расих байтак кына мажаралы повестьлар да иҗат иткән язучы. Һәм аның ул повестьлары үз вакытларында басылып та чыкканнар иде. Хәзер А. Расих барлык мажаралы повестьларын бергә туплап, аерым китап итеп бастырып чыгарды. «Мажаралы повестьлар» исемле бу җыентыкка язучының «Бәхет орлыклары», «Хәвефле сынау», «Урланган хәзинә» һәм «Сәхи бабай мажаралары» исемле повестьлары урнаштырылган.

Җыентыкның бәясе 69 тиен.

Рафаэль Мостафин

ЛИТЕРАТУРНЫЕ ПОРТРЕТЫ

Хәзерге әдәбиятыбызның атаклы язучылары, Габдулла Тукай исемендәге республика премиясе лауреатлары Габдрахман Әпсәләмов, Хәсән Туфан һәм Сибгат Хәкимнең иҗади портретларын эченә алган бу китабында Р. Мостафин укучыларны әлеге әдипләрнең иҗат биографияләре һәм иҗат алымнары белән таныштыруны, аларның әсәрләрен тирәнрәк анларга ярдәмләшүне бурыч итеп куйган һәм шуна ирешкән дә. Һәр укучыга да аңлаешлы итеп язылган «Әдәби портретлар» Татарстан китап нәшриятында русча басылган. Әмма Г. Әпсәләмов, Х. Туфан һәм С. Хәкимнең иҗади портретларын туплаган моңдый китапның татарчасы булмавын искә алганда, аның татар укучысы өчен дә файдасы зур булыр дияргә кирәк. Китапта Г. Әпсәләмов, Х. Туфан һәм С. Хәкимнең монографик беркайда да басылмаган рәсемнәре дә бирелгән.

Җыентыкның бәясе 21 тиен.

Равил Фәйзуллин

АҖАГАН

Чын дуслар очратып
танышсам,
кемгәдер дөрес юл
табышсам,
кемдәдер шат очкын
кабызсам, —
яктырып,
нурланып,
очынып,
шигырьләр язарга
ябышам.

Равил Фәйзуллинның әле күптән түгел генә дөньяга чыккан «Ажаган» исемле яңа шигъри китабы мәна шушындый юллар белән башланып китә. Җыентыкка авторның соңгы елларда иҗат ителгән һәм төрле темага багышланган, төрле шигъри формаларда язылган әсәрләре тупланган.

Китапның бәясе 9 тиен.

Бу китапларны түбәндәге адрес белән хат язып, почта аша алдырырга мөмкин:

г. Казань, ул. Баумана, 19,
Таткниготорг,
отдел «Книга-почтой».

Редакция китап жибәрү белән шөгыльләнми.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

ДИСКУССИЯ йомгаклары

1966 елда «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә «Г. Тукай, М. Җәлил традицияләре һәм бүгенге татар поэзиясе» дигән темага дискуссия барган иде.

27 декабрьда Г. Тукай исемендәге клубта язучылар, тәнкыйтьчеләр, журналистлар, әдәбият сөючеләр катнашы белән бу дискуссияне йомгаклау җыелышы булды. Җыелышны газета редакторы Ш. Хаммат о в ачты. Филология фәннәре кандидаты, тәнкыйтьче Н. Ю з и е в дискуссиянең ничек барганлыгы турында доклад ясады.

Докладтан соң жанлы фикер алышулар башланып китте. Беренче булып сүз алган Ж. Т ә р җ е м а н о в үзенең чыгышын балалар поэзиясе һәм аның үзенчәлекләренә багышлады.

«Безнең язучылар арасында, — диде ул, — тормышларын, иҗатларын балаларга багышлаган язучылар елдан-ел кими бара. Әйтьләр исә балалар әдәбиятын зурлар әдәбиятына күчү өчен трамплин итеп кенә карыйлар...»

Аннары ул Ш. Галиевнең, Р. Фәйзуллинның һәм М. Фәйзуллинаның балалар өчен язылган әсәрләрендәге кайбер кимчелекләрне күрсәтеп үтте.

Шагыйрь Н. Д ә ү л и поэзиядә форма һәм эчтәлек мәсьәләсенә караган фикерләре белән уртаклашты. «Фикерләр, сүзләр музыкаль формада булсалар гына, ул фикерләрнең ахырында рифма булса гына мин шигырьне әсәр дип таныйм. Ләкин беренче планда фикер торырга тиеш», — диде ул.

Филология фәннәре докторы, профессор Х. Г о с м а н исә поэзиянең теле һәм шигырьнең төзелеше турында эчтәлекле чыгыш ясады.

«Шигырьнең рифмик төзелеше халыкның күңел музыкасы ул, — дип, оратор форманың халыкчан булуын яклады. — С. Хәким, Х. Туфан, Ф. Кәрим, Ш. Мөдәррис иҗатларында шигырьнең яңа төрләре күп очрый. Моның сәбәбе — аларның халык телен, хасиятен тирәнтен белүләрендә, жентекләп, фәнни яктан өйрәнүләрендә. Димәк, бу яңа төрләр, шагыйрьләрнең яңа ачышлары халыкның үзеннән алынганнар».

Шагыйрь С. Х ә к и м, Х. Госман фикерләрен дәвам итеп, яшь шагыйрьләр иҗатындагы халыкчанлык күренешләренә, халыкчанлыкка нигезләнгән яңа үзенчәлекләргә туктальды. «Халыкның үзеннән алынган ачышлар Р. Гатауллин, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Б. Хәлимов шигырьләренә дә хас, — дип раслады ул. — Сүтыштан соң поэзиягә килгән Ш. Галиев, Й. Юзиев, Х. Камалов, Г. Афзал, С. Сөләйманова һәм башкаларның иҗатлары да һәрберсенең үзләренә генә хас үзенчәлекле үсеш белән бараллар. Татар поэзиясе яңа эзләнүләр, яңа ачышлар юлыннан бара. Газета битләрендә алып барылган дискуссия моны ачык күрсәтте.»

«Форма шагыйрьнең осталыгына бәйләнгән әйбер, — дип башлады сүзен Н. И с ә н б ә т. — Эчтәлеккә формасыз килеп булмый... Интонацион шигырь белән Тукай калыбы арасындагы бәхәсне шагыйрьләр үзләренең шигырь көче белән хәл итәргә тиешләр.

Хәзерге шагыйрьләр Тукайча, Такташча, турыдан-туры халык белән эш итеп, аларны хисләндерергә омтылырга тиешләр. Турыдан-туры халык белән сөйләшә, аңлаша алмыйсың икән, моңа форма белән генә ирешеп булмый».

Н. Исәнбәт үзенең фикерләрен раслау өчен татар һәм Көнчыгыш поэзиясе тарихына караган күп кенә ышандырырлык дәлилләр китерде.

Шагыйрь Ш. М а н н у р шигырь тарихы һәм Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан иҗатлары мисалында татар поэзиясенә хас үзенчәлекләр, сыйфатлар турында сөйләде. «Поэзия тарихы, — диде ул аннары, — иске, катып калган формаларга каршы көрәш тарихы ул. Ләкин әзләнү коры формага гына кайтып калырга тиеш түгел... Форманы махсус рәвештә ясап булмый. Әйтәсе килгән олы хис форманы үзе алып килә, эчтәлек аны үзе сорый».

Шагыйрь Хәсән Туфан һәм Татарстан Язучылары союзы идарәсе председателе М. Әмир дә поэзия һәм гомуми әдәбият турында моңдый сөйләшүләрнең әһәмиятенә тукталдылар. Матбугат битләрендә дә, җыелышларда да шундый эшлекле сөйләшүләрне, фикер алышуларны киләчәктә дә дәвам иттерүне якладылар.

«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНЫҢ ЧИРАТТАГЫ САННАРЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУ

Татарстан Язучылары союзы идарәсенең 21 декабрьда үткәрелгән киңәйтелгән утырышы «Казан утлары» журналының 7, 8, 9 саннарын тикшерүгә багышланды. Идарә члены Илдар Юзиев бу саннарда басылган әсәрләр, журналның тематикасы һәм оформленнесе турында доклад ясады.

Докладчы журналның яшь авторларның әсәрләренә зур урын бирүен уңай якта билгеләп үтте.

«Соңгы еллар прозасы, — диде ул, прозаиклар әсәрләренә бәя биреп, — тормышны идеаллаштырып, бизәп күрсәтүдән арына бара. Прозаиклар тормышның катлаулырак якларына мөрәҗәгать итәләр, чынбарлыктагы авырлыкларны җиңеп чыгучы авыр язмышлы кешене үзләренең төп геройлары итеп алалар. Моңдый тенденция Х. Сарьянның «Өткәм һөнәре» повесте, Г. Мөхәммәтшинның «Хәсәен абзый», Р. Фәезовның «Әнием куллары», М. Маликованың «Кыр ягы» хикәяләре өчен характерлы».

Бу саннарда басылып чыккан зур күләмле әсәрләрнең берсе — яшь язучы Х. Сарьянның «Өткәм һөнәре» повестендәге кимчелекле як итеп, докладчы хикәяләүдәге динамиканың сүлпәнләгән күрсәтеп үтте. «Әсәрнең герое көнкүреш ыгы-зыгысы арасында бөтенләй күмелеп кала, — диде ул. — Вакыт-вакыт әһәмиятсез хәрәкәтләрне сурәтләү белән артык мавыгып китеп, автор сюжет жебен күлдан ычкындырып жибәрә. Әсәрдә авырулар, үлүләр артык күбәеп киткән, бу нәрсә укучыны әсәрдән этәрә. Геройларның портретларын сурәтләү мәсьәләсенә дә автор зур игътибар юнәлтергә тиеш».

Докладчы шулай ук Г. Мөхәммәтшин, М. Маликова, А. Хәсәнов һәм башка авторларның хикәяләренә дә кыю тукталды, алар иҗатындагы уңышлы һәм кимчелекле якларны ышандырырлык итеп күрсәтте.

«И. Салаховның казакъ тормышын бик яхшы белеп язган «Колагир» хикәясе, — диде И. Юзиев, — романтик стиле, композицион бөтенлеге, сюжетның киренкелеге белән жәлеп итә. Әсәрдән татар теленең төрле бай оттенокларын, казакъ халык иҗаты белән баетылган образлы жөмләләрне кабат-кабат укыйсың».

Соңгы вакытта прозаикларыбызның сатира-юмор жанрыннан читләшүләрен докладчы бик дөрес билгеләп үтте. Журналда бу жанрга караган проза әсәрләре бик аз басыла. Басылганнары да укучының югары таләпләренә жавап бирерлек түгел. (Мәсәлән, К. Хәмзиннең «Проблемалы дәрес» хикәясе.)

Гомумән хикәя жанрының хәле мактанырлык түгел. Тәҗрибәле язучылар хикәя жанрына бик сирәк мөрәҗәгать итәләр, яшьләр арасында да иҗатларын бу жанрга багышлаучылар бик аз.

Журналда басылып чыккан шигырьләр бер-берсен кабатламыйлар. Г. Афзалның «Ышаныгыз», «Шәрип урманы», Ә. Маликовның «Яндырылган хатлар», Н. Дәүлинең «Онытма», Г. Зәйнашеваның «Китмә, сандугач», Р. Фәйзуллинның «Сине күптән күргәнем юк», «Вулканнар бар диңгез төбендә»; Р. Гатауллинның «Вьетнам турында уйлыйм», «Малайлар», Ф. Яруллинның «Сабый чак», Р. Гәрәйнең «Ферма буйларында эзләр бар», Г. Рәхимнең «Рас», Б. Хәлимовның «Таң букеты» шигырьләре һәрберсе үзенчә язылулары белән истә калалар.

«Совет властеның 50 еллыгына», «Әдәби мирас», «Әдәбият тарихына материаллар», «Сәнгать кешеләре» һәм башка бүлекчәрдә дә кин катлау укучылар өчен мавыгып укырлык материаллар даими басылып килә. Л. Аитовның татар театры тарихына багышланган «Артистның тормыш юлы» исемле язмалары бик файдалы һәм кызыксынып укырлык. Мемуар жанрына карата игътибарны киләчәктә тагы да үстерү — журналның бурычы.

Соңгы санларда очеркларның тематикасы төрләнүе уңай күренеш. Ф. Мостафинның «Бәхетле кеше», Ж. Мостафинның «Кечкенә булса да», Г. Сабитовның «Һәр нигезнең тарихы бар» очеркларын төрле характердагы һәм төрле һөнәр кешеләре турында мавыктыргыч итеп язылганнар.

«Казан утлары» журналының укучылар арасында абруе һәм аның тиражы елдан-ел арта бара, — диде И. Юзиев, докладының ахырында. — Шуңа күрә, укучыларның үсәннән үсә барган зәвыкларына жавап итеп, басылачак әсәрләрнең идея-художество сыйфатын көчәйтү өлкәсендә журнал редакциясе үзенең эшчәнлеген арттырыр дип ышанабыз».

Докладтан соң беренче сүзне журналның редакторы Р. Мостафин алды. Ул үзенең чыгышында киләчәктә журналда нинди әсәрләр урнаштырылачагы турында әйтте, редакциянең тормыштагы төрле проблемаларны журнал битләрендә чагылдыру буенча эшчәнлеге турында сөйләде. «Ләкин тормышта житлеккән проблемаларга язучыларыбыз битараф карыйлар, — диде ул. — Журналда язучының ялкынлы публицистик сүзе аз яңгырый...»

Филология фәннәре кандидаты Г. Хисмәтуллин журналда басылып чыккан кайбер тәнкыйть әсәрләре турында сөйләде, А. Әхмәдуллинның «Революцион аскетизм» һәм И. Нуруллинның Ф. Әмирхан турындагы мәкаләләрендә әйтелгән фикерләр белән бәхәскә керде.

Шагыйрь Х. Туфан журналда басылган шигырьләргә төпле анализ ясады, кайбер проза әсәрләренә карата үзенең фикерләре белән уртаклашты.

«Журналның 7 санында басылган Э. Маликов шигырьләре — диде ул, — халыкчанлыклары белән аерылып торалар, замана таләпләренә тулысынча җавап бирәләр. Формалары белән дә бу шигырьләр үзенчәлекле. Р. Гәрәй шигырьләре дә халыкчан, җырлап торалар, ләкин аларда шагыйрьнең яңуы сизелми».

Шулай ук ул Г. Афзал, Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин шигырьләрен дә уңай яктан бәяләде.

Г. Бакир, Х. Госман, А. Расих, З. Нури һәм башка чыгып сөйләүчеләр дә файдалы фикерләр әйттеләр, журналда басылган әсәрләрнең идея-художество сыйфатларына да, аларның тематикасына да кыек туктальдылар, журналның эчтәлеген һәм сыйфатын яхшырту буенча үзләренең тәкъдимнәрен белдерделәр.

ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Шагыйрьләр секциясенең чираттагы утырышы Питрәч районының Яңцевар авылында үткәрелде. Анда Ильич исемендәге колхоз председателе, «Тормыш атомнары» һәм «Сабан тургае» исемле шигырь җыентыкларының авторы Р. Рәхимовның яңа әсәрләре тикшерелде. Яшь авторның әсәрләре буенча фикер алышуга шагыйрьләрдән Ш. Галиев, Х. Камалов, И. Юзиев һәм Р. Гәрәй катнашты.

Шул ук көнне Яңцевар урта мәктәбе укучылары Казаннан килгән шагыйрьләр белән очраштылар, аларның яңа әсәрләрен тыңладылар.

* * *

Балалар әдәбияты секциясенең чираттагы утырышы «Яшь ленинчы» газетасында басылган хикәяләргә багышланды. Яшь тәнкыйтьче Ф. Миннуллин газетада басылган хикәяләр турында доклад ясады. Докладтан соң чыгып сөйләүчеләрдән А. Гыйләжев, Г. Бакиров, Р. Хафизова, В. Ихсанова, М. Мазунов һ. б. лар балалар өчен язылган хикәяләрнең уңышлы һәм кимчелекле якларына тукталдылар.

Балалар әдәбияты секциясенең декабрь аенда үткәрелгән икенче бер утырышында яшь язучы Г. Рәхимнең хикәяләре укып тикшерелде. Утырыш яшь авторның әсәрләрен Татарстан китап нәшриятына аерым җыентык итеп бастырып чыгарырга тәкъдим итте.

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәт язучыларының чираттагы утырышы Бариев Шәехнең «Йолдызлар елмайганда» исемле повестен һәм Карабаш поселогында яшәүче нефтьче-оператор Имам Шәрәфетдиновның «Айсылу» дигән поэмасын тикшерүгә багышланды. Чыгып сөйләүчеләрдән Г. Ахунов, Э. Маликов, Һ. Сафина һ. б. лар повестьның уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтеп үттеләр. «Айсылу» поэмасы яшь авторның беренче уңышы дип билгеләнде, шәһәр газетасына тәкъдим ителде.

13 декабрьда нефтьчеләрнең М. Горький исемендәге клубында Эдуард Касыймовның «Гомер ике килми» дигән романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Э. Маликов язучының иҗат һәм тормыш юлы белән кыскача таныштырганнан соң, нефтьчеләр, төзүчеләр, китапханәчеләр, укытучылар сүз алдылар. Алар романның халыкчан тел белән, реаль чынбарлыктан алып язылган булуын билгеләп үттеләр. Э. Касыймовка бик күп сораулар бирделәр. Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Камалиев язучы белән нәшриятның элемтәсе турында сөйләде.

* * *

Алабуга дәүләт педагогия институтында 10 декабрьда татар поэзиясенә багышланган зур кичә уздырылды. Кичәне кыскача кереш сүз белән язучы Э. Касыймов ачты. Аннары «Татар поэзиясенең илле ел эчендә үсеш баскычлары» дигән күзәтү белән доцент Маһинур Фәйзуллина чыкты.

Кичәнең икенче өлешендә институтның үзешчән сәнгать коллективы членнары язучыларыбызның әсәрләрен укыдылар, татар композиторларының җырларын башкардылар.

* * *

26 декабрьда язучы Э. Касыймов Алабугада сукырлар җәмгыяте клубында укучылар белән очрашты һәм алар белән «Октябрь революциясеннән соң беренче елларда татар әдәбияты» дигән темага әңгәмә уздырды. Очрашу жанлы үтте һәм укучылар киләчәктә язучылар белән үзара элемтәне тагын да ныгытуны үтенделәр.

* * *

Азнакай районы Чалпы авылы «Коммунизмга» колхозы китапханәсенең укучылар конференциясе булып үтте. Колхоз партоешма секретаре Сәлах Шәрипов конференцияне ачып, журнал һәм анда басылып килгән әсәрләр турында эчтәлекле доклад ясады.

Журналда басылган әсәрләр буенча фикер алышуларга урта мәктәп укытучыларыннан Г. Шәрипова, Р. Галиева, Г. Нуретдинова, Г. Сафин, Н. Нугайбекова, китапханә хезмәткәре Г. Вәлиева, почта бүлеге начальнигы А. Мөхитова катнаштылар, журналның эчтәлеген камилләштерү буенча үзләренең теләкләрен һәм тәкъдимнәрен әйттеләр. Г. Шәрипова бүгенге замандашларыбыз турындагы очеркларга зуррак урын бирү кирәклегенә басым ясады, язучылар турында һәм әдәбият тарихына караган материалларны даими урнаштырып баруны сорады. Ә Г. Сафин яшь язучылар белән укучыларны таныштырып, аларның рәсемнәрен һәм кыскача биографияләрен урнаш-

тырып баруны журналның уңай сыйфатларыннан берсе итеп бәяләде. Г. Шәрипова исә, журналның быелгы саннарында басылып чыккан әсәрләргә күзәтү ясап, соңгы вакытларда авыл тормышын тасвирлаган хикәя һәм повестьлар сирәгәйде, дип нәтиҗә ясады. Аның фикеренә Н. Нугайбекова да кушылды. «Хәзер, — диде ул, — авыл яшьләре электәге кебек шәһәргә омтылмыйлар, ә киресенчә, шәһәрдән авылга кайтырга тырышалар. Яшьләрдә авыл тормышына мәхәббәт тәрбияләүдә әдәбиятның роле гаять зур. Шуңа күрә язучыларыбыз авыл яшьләре тормышына игътибарны киметмәсеннәр иде».

Китапханә мөдире Г. Вәлиева журнал үзешчән сәнгать түгәрәкләренә ярдәмне арттырсын иде, дигән теләк белдерде.

Бик җанлы үткән фикер алышулардан соң, журналның актив авторы язучы Р. Төхфәтуллин «Казан утлары»нда киләсе елда басылачак әсәрләр турында сөйләде, бүгенге татар әдәбияты, язучыларның иҗатларына карата бирелгән бик күп сорауларга карата җаваплар бирде.

* * *

Язучы Р. Төхфәтуллин шул ук районның Таштуган сигезьеллык мәктәбе укучылары белән очрашты, укучыларга үз әсәрләре өстендә ничек эшләве турында сөйләде, яңа хикәясен укыды.

СУГЫШЧАН ДАН КУБРИГЫ

Күптән түгел Татарстан Язучылары союзы идарәсенә Владивосток шәһәреннән бер хат килеп төште. Бу хатта «Александр Суворов» крейсеры командиры урынбасары икенче ранг капитаны Я. Ибраһимов үзләренең корабльләрендә «Сугышчан дан кубригы» оештырылуы турында яза. Кубрикта совет кешеләренең гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында күрсәткән батырлыгы яктыртылган. Бөек Ватан сугышының легендар герое, татар совет шагыйре Муса Җәлил турындагы материалларга да анда зур урын бирелгән.

Дингезчеләр татар шагыйренең ялкынлы патриотизм, ватанга чиксез мәхәббәт символы булып яңгырый торган әсәрләрен яратып укыйлар.

МИРСӘЙ ӘМИРГӘ 60 ЯШЬ

Январь аенда республикабыз җәмәгатьчелеге күренекле прозаик һәм драматург, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСР Верховный Советы депутаты, Татарстан Язучылары союзы идарәсе председателе Мирсәй Әмиргә 60 яшь тулу юбилеен билгеләп үтте.

11 январьда каләмдәш иптәшләре, партия һәм совет хезмәткәрләре, күп санлы әдәбият сөючеләр Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасына юбилярны котлау тантанасына җыелдылар. Юбилярга бик күп оешмалардан, партия-совет учреждениеләреннән килгән телеграммалар укылды, котлау адреслары, бүләкләр тапшырылды.

Язучының тормышы, иҗаты һәм иҗтимагый эшчәнлеге турындагы докладны филология фәннәре кандидаты, тәнкыйтьче Бәян Гыйззәт ясады.

Кичәнең икенче бүлегендә республикабызның сәнгать осталары зур концерт бирделәр.

ДРАМАТУРГЛАР СЕМИНАРЫ

Декабрь аенда РСФСР һәм Татарстан Язучылары союзлары, ТАССР Культура министрлыгы Октябрьның 50 еллыгы уңае белән театрлар репертуары өчен яңа пьесалар буенча семинар үткәрделәр. Драматурглардан Ш. Шаһгалиев, Э. Касыймов, Н. Дәүли, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, Ю. Әминов, М. Елизарова, Г. Зәйнашева, Т. Миңнуллин, М. Хөснимәрданов, Т. Закиров, Г. Мөхәммәтшин, Р. Төхфәтуллин әсәрләрен тикшерүгә РСФСР Язучылары союзыннан Н. Сотников, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Мәскәү бүлегеннән Л. Еремеев, А. Боряков, РСФСР Культура министрлыгыннан А. Беляев, шулай ук республикабызның театр белгечләре, тәнкыйтьчеләр катнаштылар.

—●●—

Җаваплы редактор **Рафаэль Мостафин**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 19/XII-1966 ел. Басарга кул куелды 27/I-1967 ел. ПФ 09004. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 57 900 экз. Заказ Н-1815. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан. Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

ИҢ ЯХШЫ ҖЫРЛАРГА КОНКУРС

Профсоюзларның Татарстан өлкә советы Президиумы һәм ТАССРның Культура министрлыгы Бөек Октябрь социалистик революциясенә багышланган иң яхшы җырларга конкурс игълан итте. Конкурсның жюри составына профсоюзларның өлкә советы секретаре Ахметов К. Г. (жюри председателе), Татарстан АССРның Культура министры Гыйззәтуллин Б. М., Татарстан композиторлар союзы председателе Жиһанов Н. Г., композиторлардан — Фәйзи Ж. Х., Леман А. С., шагыйрьләрдән — Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Казан дәүләт консерваториясенең хор белән дирижерлык итү кафедрасы мөдире Казачков С. А., Татар дәүләт филармониясенең художество җитәкчесе Низаметдинов Ш. Г., музыка белгече Нигъмәтҗанов М. Н., ТАССР Министрлар Советы янындагы радиотапшырулар һәм телевидение комитеты председателе Надиров Ф. Г., ТАССРның хор җәмгыяте җаваплы секретаре Хәйлиев С. Б. кертелде.

Конкурс Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгына багышланган бөтен Союз үзешчән сәнгать фестиваленең бер өлеше булып тора.

Конкурс солистлар, ансамбльләр һәм хор репертуары өчен революцион үткәнебез, бүгенге хезмәт кешеләре турында халык иҗатының иң яхшы традицияләренә нигезләнгән җырлар тудыру; композиторларны һәм шагыйрьләрне совет халкы тормышының героикасын чагылдырган яңа җырлар тудыруга тарту; музыкаль һәм әдәби иҗат союзларының, аерым шагыйрьләрнең һәм композиторларның милли репертуар тудыру буенча эшчәнлеген активлаштыру максаты белән, «Совет кешесе — гүзәллекне иҗат итүче» дигән девиз астында үткәрелә.

Җырларның тематикасы Бөек Октябрь социалистик революциясен, СССРда социалистик һәм коммунистик төзелеш героикасын, КПСС һәм Совет дәүләте үткәреп килгән ленинчыл милли политиканың тантана итүен чагылдырырга тиеш.

Конкурска Партия, Ватан, В. И. Ленин идеяләренең тантана итүе, татар халкының Бөек Октябрь социалистик революциясенә, гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларына катнашкан данлыклы уллары, фидакарь хезмәт батырлары — бүгенге көнебезнең геройлары турындагы җырлар кабул ителә.

Конкурс 1967 елның 1 январеннан 1 июненә кадәр дәвам итә.

Конкурска моңа кадәр беркайда да басылмаган һәм башкарылмаган җырлар кабул ителә.

Әсәрләрнең төп нөсхәсендә авторларның исем-фамилияләре әйтелми, девизлары гына күрсәтелә. Әсәрләр белән бергә аерым конвертта авторларның исеме, атасының исеме, фамилиясе, адресы һәм эшләгән урыны язылган белешмә җибәрелә.

КОНКУРСКА КАТНАШУЧЫЛАРГА БҮЛӘКЛӘР

Конкурска кабул ителгән иң яхшы җырларга түбәндәге премияләр билгеләнде:

Беренче премия (бер) — җырның музыкасы һәм тексты авторларына — 200 әр сум;

Икенче премия (икә) — җырның музыкасы һәм тексты авторларына — 125 әр сум;

Өченче премия (өч) — җырның музыкасы һәм тексты авторларына — 100 әр сум.

Жюри тарафыннан яхшы дип бәяләнгән җырлар радио һәм телевидение аша тапшырылачак, газета һәм журналларда басылачак һәм ТАССРның Культура министрлыгы тарафыннан сатып алыначак.

ИСКӘРМӘ: 1. Конкурска җибәрелгән әсәрләр авторларга кире кайтарылмый.

2. Музыкасыз җибәрелгән җыр текстлары кабул ителми.

Әсәрләрне түбәндәге адрес белән җибәрергә кирәк:
Казан шәһәре, Бауман урамы, йорт № 60, ТАССР хор җәмгыяте.

Баясе 40 тиен
Цена 40 коп.

●

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

КАЗАН УТЛАРЫ

(Огни Казани)

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

●

Индекс 73210